
PRESSA.RU

1926–1991 елларда АЗАТ ХАТЫН



2016 СЕНТЯБРЬ № 9

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ӨЙДӘН ЕРАКТАГЫ ӨЙ
игелекнең чиге юк

ТУЙЛАР ЧОРЫ
хыял һәм чынбарлык

АЗАТ АБИТОВ СЫЙЛЫЙ:
Кавказ ашы

Лилия ТАИШЕВА:

— ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ ИТСӘҢ ГЕНӘ КИЛӘ АБРУЙ.



PRESSA.RU







Алик һәм Дилбәр ГЫЙЛЬМИләр гаиләсе

Прага

БЕРГӘ ЧАКТА... Бу мизгелләр күп тә түгелдер, бәлки — атналарны тыгызлаган бетмәс-төкәнмәс эш, мәшәкать ыгы-зыгысында гаилә белән үткәргән бәхетле минутлар һаман сирәгәя, кыскара барадыр. Әмма аларның һәрберсе кадерле, һәркайсы безгә тормышның ямен-тәмен тоеп яшәрлек көч, җан җылысы бирәдер. Бу тансык вакытны һәркем үзенчә үткәрә – алар мәгънәле, күңелле, онытылмас якты булсын өчен әллә ни кирәкми дә кебек...

АВСТРИЯ МӘТРҮШКӘЛӘРЕ

Гаиләбез белән сәяхәт итәргә яратабыз. Бу юлы Австрия күлләрен күрергә чыгып киттек. Без тукталган Санкт Гильген авылы — атаклы композитор Моцартның әнисе туган җир. Вольфганг күле дә каршыда гына: яшел чирәм, таулар, ап-ак болытлар, җилкәнле кораблар, төзек һәм матур авыл сурәтендә зәп-зәңгәр булып күренә. Австриядә күлләр бихисап, сулары үтә күренмәле, балыклар, аккошлар, үрдәкләр йөзә. Тауларда да күп йөрдек — берсеннән төштек, икенчесенә мендек! Хәтта болытларга тиеп карадык… Өстән караганда бар матурлык уч төбендәге кебек — көннәр буе сокланып, фәлсәфәгә биреләсе килә. «Тешле трамвай» белән Бәрән тавына менгәч, җәяү төшәргә булдык. 10 чакрым төшәсене уйламадык та…
Ә таудан төшү — җиңел дә, авыр да икән: тау чишмәләренә тукталып сусауны басасың, агач эскәмияләргә утырып ял итеп аласың, биек агачларга сокланасың, кычкырып җырлыйсың. Ташлы, бормалы юллар аякны арытса да, беркем зарланмый, бишенче яшькә барган Тимурыбызга тикле түзде! Ә иң гаҗәбе һәм рәхәте минем өчен шул булды: мәтрүшкәләр җыя-җыя төштем! Тау мәтрүшкәләре миңа Сөн буенда һәр ел кайткач җыя торган мәтрүшкәләрдән үзгәрәк тоелды: сабаклары юанрак, яфраклары куе, ә чәчәкләре эре. Төсләре дә — шәмәхә төснең төрле төсмерләре.
Тагын киләбез сиңа, мәтрүшкәләр иле, без бит әле таудан парашют белән сикерергә өлгермәдек!











Ә сез БЕРГӘ ЧАКТА ниләр эшлисез, сезнең гаиләне нинди эш-гамәлләр, үзенчәлекле бәйрәмнәр, берәүдә дә кабатланмый торган, әмма башкаларга да үрнәк булырдай матур йолалар берләштерә? Яңа фотопроектыбыз шундый мизгелләрне яктыртуга багышланган.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Тәхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Лилия Таишева
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225x290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 8.09.2016 ел.
Заказ М-2349.
Тираж 6383.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в ПАО «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА

Әбиләр чуагы

Әбиләр чуагы... Күзнең дә
Алдашып алуы, җәй булып.
Өзелеп нур тама кояштан,
Күкләрдә күренми бер болыт.


Ялкындай уйнаклап, яфраклар
Юлыма яталар сибелеп.
Әбиләр чуагы... Әбкәйләр
Ак шәлен ябына иң элек.

Ак шәлләр ябылган иңнәргә
Таянган шикелле күз үзе.
Ялкындай яфраклар җыйды да,
Хәтерем мең учак тергезде.

Ил үзе таянган иңнәр шул,
Ак шәлгә лаеклы бу иңнәр.
Яшьлектә югалту ачысын
Таратып, кояш та бер иңәр...

Иңәрме? Шулай да күз матур!
Әбиләр төбәлгән офыкка.
Ак мамык тибрәнә җилләрдә,
Әрнүләр һәммәсе ышыкта.

Ялкынлы бу дөнья!
Күзе дә
Җәй булып кыланган бер мәлдә,
Ялкындай яфраклар уйнаклый,
Яфраклар сыена ак шәлгә...





«Авылда көз». Мәдияр Хаҗиев эше.

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

Күзләремнән язлар көнләшә

Күзләремнән язлар көнләшә,
Яфрак белән яфрак серләшә.
Бакчаларда алма тулыша,
Күзге көндә – язлар сулышы
Чәчләремнән сыйпый иркәләп.
«Очрашмадык нигә иртәрәк?
Күрешәсе иде яз», – дисең,
Сизмисеңме, җирдә – яз исе?
Күзләремдә – язлар балкышы,
Яфракларның чуар алкышы
Көлтә-көлтә шатлык өләшә,
Без атлыйбыз юлдан янәшә.
Сусыл алмаларны өзәбез,
Татлы хыялларда йөзәбез.
Кояш нуры сыйпый яңактан –
Ходай безне бигрәк яраткан,
Бүләк иткән яздай күзләрен.
Мин ул күзне күпме эзләдем!
Ике гашыйк күңел серләшә,
Күзләремнән язлар көнләшә.

PRESSA.RU







БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА

8

ЯТЫП КАЛГАНЧЫ...

М. Авзалова



ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



12

ӨЙДӘН ЕРАКТАГЫ ӨЙ

Г. Сафиуллина



КЫТАЙГА БАРАСЫ ТҮГЕЛ...

И. Шәкүров

20

16



САҖИДӘ РУСИНОВА: «МӘКТӘПТӘ БАЛАГА НАЧАР!»

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ



28



ҖӘЛИЛ ХӘЗРӘТ

Ф. Хуҗахмәт

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



36

СОҢАРЫП ЧЫККАН КОЯШ
С. Сәүбанова

ЯШӘЕШ 



44

АВЫЛ МАҖАРАЛАРЫ
А. Закиров

48



КИЛЕН ТӨШӘ...
Г. Нур

ШУЛАЙ УК: 

24

АКТАНЫШ ДИГӘН ИЛ БАР...
Э. Закирова, Ф. Мостафина

52

ВИСБАДЕН
Г. Хәсәншина

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

60



ҖӨЙСЕЗ КАРДИГАН

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

ЯСАЛМА КИРТӘЛӘР.
ОПЕКУН КӨНДӘЛЕГЕ

УЛЫБЫЗ ӨЙЛӘНӘ,
БЕЗ АЕРЫЛЫШАБЫЗ

ЭЗЛӘМӘ МИНЕ...
ТЕТРӘНДЕРГЕЧ ЯЗМЫШЛАР

ЗӨЛФИЯ ВӘЛИЕВАДАН
МАСТЕР-КЛАСС



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Язмамны мәзәк белән башлыйм әле. Гарәп малае әтисеннән: «Әти, син ник яулык ябынып йөрисең?» – дип сорый. «Чәчемә, колагыма ком тулмасын өчен», – ди тегесе. «Ә ник озын чапан кидең?» «Кояш тәнемне пешермәсен өчен». «Әти, без бит Нью-Йоркта яшибез...»

Мин бу хакта язарга күптән ниятләгән идем. Башта журнал укучылар дөрес аңламас, дип, уңайсызланыбрак тордым. Әмма татар басмаларында үземнекенә охшаш фикерләр укыгач, күп танышларымның да минемчә уйлаганнарын белгәч, кулыма каләм алырга булдым.

Әни ягыннан әбием (әнкәй дип йөртә идек) – мулла кызы. Әле дә хәтеремдә – әнкәй йоклар алдыннан догалар укый: «Дога укысаң, йокы тыныч була, начар төшләр дә керми», – ди торган иде. «Аятел көрси»не дә беренче тапкыр аңардан ишеттем. Икенче әбием дә намаз укый, гарәп хәрефләре белән язылып, кадерләп саклаңган китаплардан пәйгамбәрләр хакында сөйли иде. Әбиләремнең бу эшләре өлкән кешеләр өчен гадәти хәл итеп кабул ителә иде. Сер түгел, һәр кеше тормышта ныклы бер таянычка мохтаҗ. Халкыбызның гасырлар буе йөрәк түрендә булган гореф-гадәтләренең кабат яңаруына мин бер дә каршы түгел. Чын күңелдән Аллага ышанучылар, Коръән өйрәткәнчә, изгелеккә омтылган, яхшы күңелле булырга тырышкан кешеләр диннең асылын дөрес итеп аңлый. Алар динне күңелдәге мәхәббәт яки башка тирән хис кебек кабул итеп, аның хакында кычкырып та, башкаларның динлеметүгелме икәнен «үлчәп» тә йөрми. Әмма, «һәр заманның үз фанатлары» дигән кебек, диннән дә шоу ясарга тырышучылар пәйда була башлады. Мондый кылану дингә әйдәү түгел, киресенчә, аңа омтылган кешеләрне дә биздерә кайвакыт. Ә инде кайбер замандашларның ике-өч тапкыр мәчеткә барып, бер-ике кыска дога да ятлап алса, үзен шунда ук Аллаһы Тәгаләнең урынбасары итеп хис итә башлап, башкаларга өстән генә карап акыл өйрәтә, йә күршесенең гөнаһларын саный башлавын әйтәсе дә юк. Шулхәтле «изгеләнеп» беттек, бер таныш түти әйткәнчә, «гомер буе гуләйт иткән хатыннар да хәзер хаҗия булып бетте, ак яулык бәйләп, суфиланып, аштан ашка йөриләр...» Яулык, дигәннән, арабызда гарәпчә баштан-аяк уранган хатыннар бар. «Безнеңчә түгел бит бу! Безнең әби-бабаларыбыз да укыганнар Коръәнне, ураза да тотканнар, ислам кануннары буенча да яшәгәннәр. Берсе дә хиҗап киеп йөрмәгән, корсакка җитә язган кара сакал үстермәгән», – дип язган «Татарстан яшьләренә» Рәзинә исемле ханым. Кайберәүләр, хиҗапны яклап, «ыштансыз йөрергәмени?» – ди. Әйтерсең, кибеттә йә хиҗап, йә шортик кына, башка кием сатылмый. Заманча озын, ябык костюмнар, күлмәкләр дә бихисап бит. Күптән түгел генә гарәпчә киенгән бер төркем татар кызлары, «Кызлар, ник алай киенәсез, безнеңчә түгел бит ул?» дигәнгә, «Һы, татарча дип, бөрмә итәкле күлмәк белән калфак киеп йөрмәбез инде», – дип көлешеп киттеләр. Аңламыйм, дин дип, үз милләтеңне, аның әдәпләрен санга сукмау яхшымы? Гомумән, соңгы вакытта милләтне диннән аерып, аны арткарак куярга тырышу күренә. «Мин мөселман» дигәндә, кеше үзенең татар икәнен дә онытмасын иде, бу төшенчәләр бербереен кире какмый бит. Аннары, гарәп халыкларының ничек киенүе андагы климат үзенчәлекләре белән бәйләнгән. Озын кием кимәс иде – кызу кояшта тәне пешә. Чәчен-күзен капламас иде – чүл җиле күзгә-башка ком тутыра. Ә бездә климат шартлары да, табигать үзенчәлекләре дә бөтенләй башка төрле, үзебез дә икенче милләт вәкилләре. Кайвакыт, киемгә карап, мәчеткә бөтенләй кертмәү очракларын да мин дөрес дип санамыйм. Кеше бит Алла йортына килә, бәлки, ниндидер бәлагә юлыккандыр яки каяндыр кайтып киләдер, мәчеткә керү теләге кинәт кенә күңеленә кергәндер, ник аны кире борырга? Иманга килү – беренче чиратта түгелмени? Мәчеткә барганда теләсә ничек киенергә, дип өндәмим, әлбәттә, дини кагыйдәләрне үтәү кыен түгел, әмма аерым очракларда ташлама ясау яки кайбер якларны яхшыга таба үзгәртү ысулларын табарга тырышу начар булмас иде. Зур мәчетләр хакында әйтә алмыйм, үзем белгән бер кечкенәсендә бик әйбәт гадәт бар: теләгән кеше анда кергәндә кияр өчен бушлай яулык яки түбәтәй алып тора ала (шуның өчен махсус берничә баш киеме тотыла). Бик уңай бу, минемчә.

Диннән бизнес ясарга тырышучылар да кәефне кыра. Кемдер «хәләл» сүзенең халыкка тәэсир итүен белеп, тиз генә шуны өстәргә ашыга. Ите ярый инде, ә башкалары? Ярый әле, юморга бай халкыбыз: бер татар форумында «хәләл сөт» дигән төшенчәдән «Намаз укый белә торган сыерныкыдыр ул!» дип егылып көләләр. Ислам дине тәгълиматын халыкка җиткергәндә һаман да элеккеге заманнан мисал-

лар китерелә. Мәсәлән, оҗмах турында – анда сине хур кызлары көтеп торганы, искиткеч матур җиләк-җимешле бакчалар, саф, салкын сулы чишмәләр – болар барысы да, гомеренә хатын-кыз заты күрә алмыйча, үзләренең хуҗаларының хәрәмнәренә кызыгып яшәгән, туйганчы ашарына булмаган, салкын чишмә суына тилмергән гарәп бәдәвиләре – көтүчеләре өчен мәңгелек хыял булгандыр, аларны мөселманлыкка китерүдә зур роль уйнагандыр. Ләкин XXI гасырда һаман шуларны сөйләү дөрес булырмы? Бигрәк тә хур кызлары турында. Бу бит ир белән хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәтне хайваннар түбәнлегенә төшерә. Нигә соң оҗмахта без яраткан хатыннарыбыз, ирләребез, сөйгән ярларыбыз, туганнарыбыз, дусларыбыз белән бергә булырга тиеш түгел? Бу очракта ул изге динебезнең асылына туры килер иде.

Кыскасы, изге китапларда язылганны дөрес аңласак, дин кебек саф хисне уенчыкка күреп шалтыратып йөрмичә, рухи якка күбрәк әһәмият бирү мөһим икәненә төшенсәк иде.

Гүзәл ХӨСНЕТДИНОВА.

Минем тормышымда гел яхшы укытучылар, яхшы дуслар очрады. Кечкенәдән китапка гашыйк идем, шуны белгәнгәме, мөгаллимнәрем миңа: «Зәлифә, син үзең дә укытучы булачаксың», – диләр иде.

Әйткәннәре рас килде: үз хыялыма ирешеп, озак еллар балалар укыттым; байтактан лаеклы ялда булсам да, укучыларымны һаман сагынам, үз укытучыларымны юксынып искә төшерәм.

Туган авылымда мәктәп тыкрыгыннан узган саен, чәчәкле күлмәк өстеннән алъяпкыч япкан балачагым йөгереп чыгар төсле тоела миңа. И бу гомер дигәнең, ник болай тиз үтә икән соң? Әле кайчан гына өр-яңа мәктәп күлмәге киеп, «Котлагыз үземне дә, яңа күлмәгемне дә», – дип, күршеләргә йөгереп кергән чакларым... Гөнаһ шомлыгына, яңгыр яуган, аяк асты пычрак көн иде. Күлмәк котлап бирелгән бер бәләкәй шакмак шикәрне кесәгә шудырып, сөенеп чыгып килгәндә, таеп егылдым. Тик еламадым. Иртәгәсен, аннан-моннан капкалап, мәктәпкә – беренче сыйныфка укырга киттем. Укый беләм, каләмне дә ярыйсы гына оста тота идем инде. Тик мәктәптә сул кул белән язарга ярамый икән бит! Укытучым Фәһимә апа Фәрвазованы ничекләр юксынып искә төшермисең: чиләнде, җәфаланды мин сулагай белән, барыбер максатына иреште – мине уң кул белән язарга өйрәтте. Укырга йөри башлаган беренче көннәрне мин бер нәрсәне кабул итә алмадым: мәктәптә 4-5 сәгать буе чәй эчмиләр икән бит! Беркөнне «тышка чыгып керим әле» дип, рөхсәт сорадым да, өйгә сыздым. Тәмләп чәй эчеп килгәндә инде бөтен мәктәп купкан, дөнья бетереп мине эзлиләр иде. Фәһимә апага нинди авырлык китерүемне бүген бик аңлыйм да соң...

Физкультура дәресен укыткан Шамил абый Бәдретдиновны да аерым бер хөрмәт белән искә төшерәм. Бөек Ватан сугышында сыңар кулын югалтып кайткан иде ул. Язын-көзен аның дәресләрен, әй, ярата идем, ә менә кышын күрәсе дә килми, чөнки чанам юк. Дәрес ахырында чаналыларга «бишле», чанасызларга «дүртле» әләгә...

Китапка булган олы мәхәббәтне дә укытучыларым уятты. Башлангычта ук Тукай шигырьләрен, М. Фәйзи, Г. Әпсәләмов әсәрләрен укырга өлгердем. Гариф Гобәйнең «Без үскәндә» дигән китабы кибеттә генә сатыла иде, ничек итсәм иттем, шунлык акча җыйдым. Кибеткә барсам, чират – тары ярмасы саталар икән. Чиратым җитеп, сатучы: «Үскәнем, сиңа ничә кило?» – дип сорагач: «Миңа ярма кирәкми, Гариф Гобәй китабы кирәк», – дигәне тирә-юньдәгеләр рәхәтләнеп көлгән иде.

Бишенче класста күрше Киров сигезьеллык мәктәбенә йөри башлагач, класс җитәкчебез Зөфәр абый Абуяров тарих фәненә мәхәббәт уятса, татар теле укытучыбыз Фәйрүзә апа Кыямова, әдәбиятны яратуымны белеп, һәрчак таяныч булды. Урта мәктәпне Пучыда тәмамлап, аннан соң Алабуга культура-агарту училищесында китапханәчеләр хәзерләү бүлегендә укыганда, утыз кыздан торган татар группасына якташым, Ямалы авылы кызы Дибәҗә апа Каюмова җитәкчелек итте. Әниләрчә биргән киңәшләре безгә зур ярдәм, үзе терәк булды. Үзе дә әдәбиятка гашыйк Дибәҗә апабыз белән гомер буе аралашып яшәдек, инде ул да мәңгелеккә күчте...

Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты факультетына мине гаиләм озатты, укытты. Түзделәр, ирем Габдуллага, өч кызыма, туганнарыма рәхмәт. Андагы остазлар белән кем генә горурланмас! Мөхәммәт Мәһдиев җитәкчелегендә диплом яклавым үзе бер олы мәктәп булды. Ул биргән исемлектән бер генә китапны да укымый калдырмадым – дөнья әдәбияты җәүһәрләре иде алар. Мәрхүм якташым Зәет Мәҗитов та искиткеч яхшы күңелле кеше иде, аның яхшылыгыннан кайчакларда үзебезчә файдаланган чаклар да булмый калмагандыр...

Югарыда исемнәре аталган остазларым барысы да бакыйлыкта инде, урыннары җәннәттә булсын, истәлекләр дога булып барып ирешсен! Университетта безгә тирән белем биргән укытучыларым Флера Ганиева, Хатип Миңнегулов, Резеда Ганиева, Фәһимә Хисамова, Азат Әхмәдуллин һәм башкалар, Аллага шөкер – исән-саулар. Кулыма диплом алгандагы сүземә тугры булып, мәктәптә бик яратып балалар укытканмын икән, монда сезнең дә зур өлешегез бар, хөрмәтле укытучыларым!

Гөлзәлифә ӘХМӘТГАЛИЕВА.
Актаныш районы,
Качкын авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSI.RU

ЯТЫП КАЛГАНЧЫ...

ЛИЛИЯ ТАИШЕВА: «МОҢАРЧЫ БЕРӘҮ ДӘ ЭШЛИ АЛМАГАН КОЛАЧЛЫ, МАСШТАБЛЫ ЭШЛӘР ГЕНӘ КЫЗЫКТЫРА МИНЕ. БӘЛКЕМ, ШУҢАДЫР ДА БАШКАРГАН ЭШЛӘРЕБЕЗ ТУРЫНДА ДӨНЬЯ БЕЛӘ БҮГЕН».

Мәдинә АВЗАЛОВА

Без аның белән әңгәмәбезне планшетындагы фотолар караудан башладык. Әнә ул – «Яңа гасыр» коммерциячел булмаган автономияле хәйрия оешмасы җитәкчесе Лилия Әхәт кызы ТАИШЕВА – Мәскәүдә, сәламәтлек саклау мәсьәләләре буенча уздырылган Хөкүмәт комиссиясе утырышында. Аның белән янәшә – Россия Федерациясе хөкүмәте башлыгы Дмитрий Медведев. Әнә кызыбыз – Нью-Йорк шәһәрендә ВИЧ/СПИД йогышлы авырулар проблемаларына багышланган Генераль ассамблея утырышында. Су спорты төрләре буенча Казанда узган XVI Дөнья чемпионатында Россия Олимпия комитеты президенты Александр Жуков һәм ФИНА президенты Хулио Маглионе янәшәсендә...
Республикада коммерциячел булмаган хәйрия оешмалары җитәрлек. Әмма бу оешманың эшләре инде күптән Татарстан чикләрен үтеп, дәүләт күләмендәге мөһим чарага – тарихка кереп калырдай үзенә бер кабатланмас вакыйгага әверелде. Әгәр ул: «Кеше эшләмәгәнне, башкалар булдыра алмаганны», – дип әйтә икән, бу – шулай. Төп максаты шул аның. Беркайчан да тапталган эздән генә бармас ул. Ике сүзнең берендә: «Без – инновацияләргә әзер!» дип торган кеше, әлбәттә инде, кемнедер кабатламас. Аның, һичшиксез, үз сукмагы булыр. Үзе генә белгән, башкаларны да шунда өндәгән...
Ул юлга каерылсаңмы?! Ниләр генә ишетмәссең дә, ниләр генә күрмәссең?!
Казан дәүләт медицина институтында «медик-кисәтү эшләре» белгечлеге буенча белем алып, Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте институтын тәмамлап, медицина фәннәре докторы дәрәҗәсенә ирешкән, туксанлап фәнни хезмәт һәм ике монография авторы, үзенең фикерен Канада, Мексика, Австрия, Германия, АКШ илләрендә уздырылган халыкара конференцияләрдә ишеттергән булдыклы ханымның безгә дә әйтер сүзләре бар.

Үзе турында

– Чиләбе якларыннан мин. Анда татарлар бик күп яши. Унынчыны тәмамлагач, Казанга медицина институтына киттем. Бер бардым, ике бардым... Язмышымны башка сынамыйм, булдыра алмыйм, дип кул селтәр иде, бәлкем, кемдер – әмма мин бирешүчеләрдән түгел. Әбием Хәмдениса да әйтте шул чагында: «Кызым, барасың! Ятып калганчы, атып кал!» Бу сүзләр минем тормыш шигаремә әйләнде. Ә гаиләм миңа һәрчак ышанып, көч биреп торды – бүген дә шулай. Тәки кердем өченче баруда. Аның каруы, институтны кызыл дипломга тәмамладым. Өченче баруда гына керүемнең үчен кайтардым... (Ул елмаеп куя, ә мин аның буй-сынына, һәр пианист кызыгырлык озын бармакларына сокланып: «Сәнгатькә чакыручы булмадымы?» дип сорап куям. Булган икән – музыка мәктәбе дә, балет та – ләкин ул нәфис куллары белән реаль проблемаларны хәл итәргә тели!)

Институтны тәмамладым да уйлана калдым. Инде нишләргә? Дөресен әйткәндә, минем глобаль әйберләр майтарасы килде. Көн тудымы, СПИД, ВИЧ-инфекция, наркоманнар, авыр хәлгә калган бәхетсезләр, мохтаҗлар турында сөйлиләр. Мин булышмасам, кем булышыр, дидем. Әкренләп шушы коммерциячел булмаган хәйрия оешмасын оештырып җибәрдем. Эшне өч-дүрт кеше белән башладык. Бу – 1999 елның март ахырлары иде. Дөрес, хәзер дә күп түгел без. Әмма безнең бәләкәй команда зур эшләр башкара, чөнки һәрберебез бу гамәлләрне башкарып чыгуга күңеле белән бирелгән, һәркем биш кеше өчен эшләргә, ун төрле эшкә алынырга әзер. Кайчак: «Бу – Таишеваның кабул итү бүлмәсеме?» – дип шалтыраталар. Кабул итү бүлмәләребез юк безнең, әмма офисыбыз кайнап тора. Ә ярдәмгә мохтаҗларны Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының тире-венерология диспансерында – шул җирлектә үзебез булдырган үзәктә (низкопороговый центр) – аноним, документларсыз кабул итәбез. Бушлай эшлибез. Бөтен анализларны да бушлай бирдерәбез. Диагноз куябыз, дәвалыйбыз, социаль һәм юридик ярдәм күрсәтәбез. Кирәк икән, дәүләт ярдәме алып бирергә дә булышабыз. Билгеле, үзебезнең белгечләр генә җитми. Бездә психологлар, социаль хезмәткәрләр эшли. Диспансердагы табиблар белән сөйләшәбез. Акчага, әлбәттә. Акчасыз, үзегез беләсез, берни эшләп булмый. Бу – без башкарганның бик азы гына, диңгездәге тамчы гына. Минемчә, коммерциячел булмаган оешмалар, коммерция оешмалары белән кулга-кул тотынып эшләргә тиеш. Ни дисәң дә, аларның икесенең дә максатлары уртак бит: оешманы үстерү, таныту, абруйлы итү. Ә моны бары халыкка, гади халыкка хезмәт итеп кенә эшләп була.

Мондый үзәк быел Чаллыда да ачылды. Шушы чорда гына да үзәктә 9 мең мигрант, наркотик куллланучылар, ВИЧ-инфекцияле кешеләр булып китте.

Мигрантларга ярдәмгә

Әңгәмәдәшем «Яңа гасыр» коммерциячел булмаган хәйрия оешмасы башкарган эшләрне ничек кенә атамасын, инновацион проект дипме яисә мигрантларны социаль адаптацияләү һәм интеграцияләү дипме, хикмәт анда түгел. Моңарчы мигрантлар белән болай җитди эшләгән оешма булмаган да әле ул. Фтизиатр, наркологларны мәҗбүри рәвештә Сәламәтлек министрлыгының гражданнарны медицина ягыннан тикшерү үзәгендә узган пациентларга икенче бинага чабып йөрисе дә юк – «Яңа гасыр»ның шунда ук урнашкан социаль үзәгендә алар хокукый һәм яңа җирдә тормыш башлап җибәрер өчен кирәкле башка төрле киңәш-белем ала алалар. Чит регионнардан килүчеләрне ачык йөз белән кабул иткән җәмгыятьтә үзләрен ничек тотарга кирәклегенә өйрәтәләр. Гражданнарның хокуклары һәм бурычлары, хезмәт базары турында мәгълүмат бирәләр.

– Шул рәвешле, без мең ярым кешене өйрәтеп чыгардык, – дип дәвам итә Лилия Әхәтовна. – Бүген











PRESSA.RU


Фото: Ксения Богданова

– Кеше үзе белән һәрвакыт гармониядә булырга тиеш. Югыйсә ул, шәхес буларак, әкренләп бетә, таркала, – ди ул. – Хатын-кыз үзен карап йөртергә тиеш, дип саныйм. «Вакыт юк, эшем күп», дигән сүзләр сылтау гына ул. Эшлисе килгән – юлын табар, эшлисе килмәгән – сәбәбен, диләрме әле?
Лилия ханым спорт залларына йөрергә яратмый. Аның көне иртәнге күнегүләрдән башлана. Шуңа да һәрчак яхшы формада ул. Илле яшеңдә дә утыз яшьлек булып күренәсе килә икән, көн саен үзеңне кара – вакыт тап!



мигрантлар өчен социаль өлкәдә мобиль технология кулланыла башлады. Болар барысы да Россия Президентының мигрантлар өчен биргән грант акчасына эшләнә. Кесә телефонына өстәмә мәгълүмат урнаштырыла: анда аларның хокуклары, медицина һәм социаль ярдәмне каян алырга була – шул хакта языла. Ул өч телдә: рус, үзбәк һәм таҗик телләрендә алып барыла.

Безнең тәкъдим белән Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мигрантлар өчен программаны үзгәртүгә кадәр барып җитте. Мигрантларга үз телләрендә дүртәр сәгать аңлату эшләре алып барыла. Алар бүген хезмәт биржасының кайдалыгын, Татарстанның кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең кайда утыруын, нәрсә ярый, ә нәрсә ярамаганлыгын беләләр.

Спортка ВИЧның ни катнашы бар?

– Казанда су спорты төрләре буенча Дөнья чемпионаты барышында безнең оешма шушы кысаларда ВИЧны кисәтү буенча махсус проект үткәрү инициативасы белән чыкты. Татарстан җитәкчелеге моны бер тавыштан хуплады. «Җиңел су!» проекты сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, спортчылар, волонтерлар һәм тамашачылар арасында йогышлы чирләрне кисәтүгә юнәлтелгән иде. Бу чараларда 3 миллион кеше катнашты. Без үзебез дә бу хәлне көтмәгән, болай ук уңышлы килеп чыгар дип өметләнмәгән идек. Аны ачу тантанасында Россия Олимпия комитеты президенты Александр Жуков һәм FINA президенты Хулио Маглионе катнашты.

Беренче мәртәбә мондый чараны уздырганда (аны бөтен илгә беренчеләр булып Универсиада вакытында үткәрүчеләр дә алар – «Яңа гасыр» булган икән!) – «Спортка ВИЧның ни катнашы бар инде?» – дип гаҗәпләнүчеләр дә булмады түгел. Әмма нәтиҗәсе без көткәннән дә шәбрәк килеп чыкты.

Тагын бер зур проект – Лилия Таишева җитәкчелегендәге «Яңа гасыр» оешмасы 2016 елда уздырылган Казан марафонының социаль өлеше. «Үзеңне сына!» дип аталган әлеге чарада дөньяның 38 иленнән 7,5 мең кеше көч сынашты. Һәм, тарихта беренче мәртәбә, ярышларда ВИЧ-инфекцияле 50 кеше катнашты. «3 чакрымга йөгерештә, – ди Лилия Таишева, – Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия Федерациясенең хөкүмәт башлыгы ярдәмчесе Геннадий Онищенко, спорт һәм шоу-бизнес йолдызлары да катнашты».

Бу инновацион проектлар, социаль проблемаларны җиңүгә юнәлтелгән яңа ысуллар Россия Олимпия комитеты җитәкчелеге, Татарстан һәм Россия Федерациясе Башкарма хакимияте, FINA Халык-



«Яңа гасыр» коммерцияле булмаган автономияле хәйрия оешмасы хөкүмәтебез, Иҗтимагый палата, Татарстанда кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, төрле министрлыклар белән даими хезмәттәшлектә. Бәлкем, шуңадыр да аның эше һәрчак уң килеп тора, һәркайда теләктәшлек таба. Ә бит, бер уйласаң, дәүләт органнары вәкилләре белән уртак тел табу һич тә җиңел эш түгел. Шуңа да оешмага төрле дәрәҗәдәге Мактау кәгазьләре һәм Рәхмәт хатлары агылып кына тора. Җитәкченең үзенең дә Дәүләт бүләкләре җитәрлек. Ул – «Татарстанның атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре», Россия Президенты Владимир Путинның Мактау кәгазенә лаек кеше. Универсиада уңаеннан бирелгән медаль турында әйтеп тә тормыйм. Шушы көннәрдә генә тагын бер шатлыклы хәбәр килеп иреште: Лилия Таишева җитәкләгән оешма, Татарстан Президенты Указы нигезендә, 2016 елда Татарстан Республикасында гражданлык җәмгыяте институтын үстерүгә керткән өлеше өчен премия белән бүләкләнгән.

ара Федерациясе тарафыннан югары бәяләнә. «Яңа гасыр» башлангычлары алга таба дөнья күләмендә үткәреләчәк ярышларда иң яхшы тәҗрибә буларак кулланыш табачак!

Җәмәгать эшлеклесе

«Ничек өлгерәсез?» дигән сорауны бирмичә булдыра алмыйм. Ул әлеге оешманың генераль директоры гына түгел бит, ә бәлки Татарстан Республикасының Иҗтимагый палата әгъзасы, Татарстанда кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе, коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Президенты каршындагы республика эксперт төркеме әгъзасы да, җитешмәгән җире юк, кыскасы. Өстәвенә, иҗтимагый-дәүләт хезмәттәшлеген үстерүгә булышлык итүче утыздан артык уникаль проектлар авторы, һәм шуларны гамәлгә ашыручы да – ул үзе. Һәм... хатын-кыз да, ир хатыны, балаларының әнисе дә... «Ничек өлгерәсез?» – дим, янә кабатлап.

Бөтен нәрсәгә өлгерер, теләгәнеңә ирешер өчен эшеңне яратырга кирәк. Ә ул ярата, көндәлек туып торган шул борчу-мәшәкатьләреннән башка яши дә алмас сыман. Гәрчә аның өчен беренче урында гаилә торса да. Ул шулай ди дә, һәрдаим аның турында кайгыртып торган ире, кечкенәдән күпне белергә, бар нәрсә белән кызыксынырга омтылган уллары турында горурланып сөйли: «Аларны иң авыр хәлдән дә чыгу юллары бар», – дип өйрәтәм. Эшлекле ханымның һәрнәрсәгә үз карашы, үз фикере. Гомумән, ул төрле: әле елмая, әле җитдиләнеп китә. Читтән күзәтеп торган кешегә ул бик кырыс сыман тоелыр. Юкка. Күңеле игелеккә тартылган, «зур эшләр майтару»ны мохтаҗларга ярдәм итүдә күргән кешенең эчке дөньясы күпләрне көнләштерерлек.

– Матурлык – ул тышкы кыяфәтеңдә генә чагылмый. Ул – синең эчке дөньяң, яшәү рәвешең, – дип сөйли Лилия Әхәтовна.

Әйе, ул матур һәм зәвыклы итеп киенә, бизәнеп йөрергә ярата. Аңа башкача ярамый да. Кемнәр белән генә очрашмый да, кайларда гына булмый ул көн дәвамында.

– Социаль өлкә, нигездә, хатын-кызлар җилкәсендә. Әбиемнең сүзләре искә төшә, – ди ул, – эшкә китүчеләрнең ике кулларына – бер эш, өйдә калучыларның – ун эш. Шуның кебек – бетмәс-төкәнмәс эш...

Лилия Таишева инициативасы белән узган ел социаль мәгънәгә ия булган йогышлы чирләрне кисәтү өлкәсендә эшләүче оешмаларның Консорциумы оештырылды. Шушы юнәлештә эшләп, олы тәҗрибә туплаган Лилия Әхәт кызы Таишева янә аның җитәкчесе итеп сайланды. 2015 елның октябрендә Мәскәүдә Сәламәтлек саклау буенча узган хөкүмәт комиссиясендә аның эшчәнлеге хөкүмәт башлыгы тарафыннан югары бәяләнде.

«СЕЗНЕҢ КОМАНДА – АРАДА ИҢ ЯХШЫСЫ»

Узган айда Казанда булып үткән омбудсманнарның Азия ассоциациясе Директорлар Советы утырышы анда катнашучыларны югары дәрәҗәдә оештырылуы белән хәйран итте. Азия регионында омбудсманнарның Халыкара институты Президенты Сәлмән Фарукиның Татарстан Республикасында кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурскаяга җибәргән телеграммасында: «Мин бу чаралардан тәэсирләнеп кайттым. Сезнең команда – арада иң яхшысы!» диелгән иде.

– Безнең эшебезгә зур бәя бу, – ди Сәрия Сабурская. – Чыннан да, дөнья күләмендәге әлеге форумда омбудсманнарның Азия ассоциациясе әгъзалары, кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләре һәм омбудсманнарның Халыкара институтыннан килгән кунаклар белән беррәттән, Татарстан Президентыбыз, хөкүмәт башлыгы, Конституция Суды Рәисе, Дәүләт Советы депутатлары, Иҗтимагый палата вәкилләре һәм халык хокукларын саклауда безнең белән бер адымда атлаучы башка күп кенә оешмалар катнашты. Утырышка Россия Федерациясендә кеше хокуклары яклау буенча вәкаләтле вәкил Татьяна Москалькова да килде.

Мин чыгышымны Татарстан хөкүмәте тарафыннан Кеше хокуклары буенча 2014–2018 елларга расланган стратегиянең асылы нидән гыйбарәт икәнлеген бәян итүдән башладым. Иң мөһиме: бу мәсьәләдә бердәм дәүләт системасын булдыру; аны нәтиҗәле итү; хакимият һәм гражданлык институтларын, хокук саклау өлкәсендә эшләүче коммерциячел булмаган иҗтимагый оешмаларны берләштерү. Безгә җәмәгатьчелек ярдәменнән башка булмый да, ярамый да. Президентыбыз Указы белән барлыкка килгән «Халык контроле» мәгълүмати системасы белән эшлекле бәйләнештә булулар, «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» белән төзелгән килешүләр, гражданнарга юридик ярдәм күрсәтү өчен оештырылган «Кайнар линия»ләр, «Россия пенсионерлар берлеге» белән һәрдаим элемтәдә торулар, иректән мәхрүм ителгәннәр янында – колонияләрдә хокукый ярдәм көннәре оештырулар, социаль яклаучысыз мигрантларга ярдәм күрсәтүләр – берсе дә эзсез югалмый. Халык күрә, белә, рәхмәт әйтә...

Мигрантлар дигәннән... Алар белән элемтәне без бары мигрантларга хокукый ярдәм күрсәтүче «Юридик клиника» үзәге һәм «Яңа гасыр» коммерциячел булмаган автономияле хәйрия оешмасы ярдәмендә генә тиешенчә урнаштыра алдык. Мигрантларга ярдәм итүдә мобиль технология куллану уңай нәтиҗәләр бирә. Ярдәмгә мохтаҗ кеше безгә йә интернет аша чыга, йә үзе килә. Һәр очракта да без аларга ярдәм итәргә әзер.

PRESSA.RU



















Фото: Ксения Богданова

ӨЙДӘН ЕРАКТАГЫ ӨЙ



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

ЯШЬТӘШЛӘРЕННӘН ҮЗГӘ АЛАР, ЧӨНКИ ЯШИ ГЕНӘ БАШЛАГАН КИЛЕШ ЯЗМЫШ СЫНАУЛАРЫ КИЧЕРЕРГӘ МӘҖБҮР...

Безнең алга куелган бурыч исә бик катлаулы һәм бик мөһим: шушы балалар йөзендә якты елмаю тудырырга тиешбез. Алар тирә-юньдәгеләрнең кайгыртуын, җылысын тойсын, дөньяның матурлыгына, әйбәтлегенә ышансын!

Бөтен дөньяга билгеле «Макдоналдс» компаниясе шулай ди. Авырту аркасында бик озак вакытлар хастаханәдә яткан, өйләреннән, якыннарыннан аерылып торырга мәҗбүр булган балалар бар. Шундый сабыйларга, аларның гаиләләренә ярдәм итү йөзеннән компания 1984 елда «Роналд Макдоналд йорты» Хәйрия фондын булдыра. Америка Кушма Штатларында, «Макдоналдс» компаниясенә нигез салган Рэй Крок хөрмәтенә оеша ул. Дәваланган чорда «Роналд Макдоналд йорты»нда балалар әтиәниләре, туганнары белән бергә яши ала. Бушлай! «Макдоналдс» корпорациясенең дөньяның 57 илендә шундый 324 Йорты бар: һәр көнне 7200 йокы бүлмәсе моңа мохтаҗ гаиләләрне кабул итә ала. Тормышларында болай да катлаулы чор кичергән бу гаиләләрнең 257 миллион доллар акчасы янга кала дигән сүз бу!

Казанда «Роналд Макдоналд йорты» 2013 елда ачылды. Россиядә берданбер ул! Моңарчы безнең илдә «Макдоналдның гаилә бүлмәләре» генә бар иде әле: «Балалар онкологиясе институты»нда (Мәскәү), Санкт-Петербург, Самара, Саратов, Воронеж, Түбән Новгород, Чабаксар шәһәрләрендә.

Казанда «Роналд Макдоналд йорты» гаилә кунакханәсен төзү 110 миллион сумга төшкән. Йортны тоту өчен ел саен 12 миллион сум акча кирәк. Чыгымнарның барысын фонд күтәрә, йортта эшләүчеләр дә тырыша.

Якын кешеләре янәшәдә булганда кечкенә пациентлар тизрәк терелә, диләр...

– Кичә бездә зур вакыйга булды: бер баланы бөтен Йортыбыз белән өенә озаттык. Терелеп кайтып китте! Наиләнеке кебек диагноз белән... Инде без дә ул көнне көтәбез! Күз алдына китереп-китереп карыйбыз... Тагын бер-ике айдан, бәлки, бераз күбрәктән... Мондый чир белән күзгә-күз очрашкач, үзеңне тизрәк кулга алырга кирәк икән. Аннан – сабыр булырга... Мин башта югалып калдым шул. Хәтта үзем белән исәнләшкән кешеләргә ул көннәрдә җавап та кайтара алмадым... «Исәнмесез», – диләр, тагын: «Хәерле көн!» – дип өстиләр. «Ничек шулай дип әйтә алалар?!» – дип шакката идем. Моннан соң иртәләрнең берсе дә хәерле булмас төсле иде инде...

> *Палатада сөйләшү өчен гел бер тема гына бар, ә йортта алар төрледән-төрлегә әйләнә, киңәя.*

Аның ул чакта ниләр кичергәннәрен күз алдыма китерәм дә, тамагыма төер тыгыла. Ничек тә сиздермисе, күз яшемне аңа күрсәтмисе иде! Тавышы вакытвакыт калтырап китсә дә, Гөлнара үзе еламый әнә. Йорттагы язылмаган кагыйдәләрнең берсе бугай бу: анда яшәүчеләрнең йөзендә гел елмаю булырга тиеш. Күз яше аша дөньяга елмаеп карый аласың икән – сынауны җиңәсең! Шуңа күрә дә күңелсез нәрсәләр турында сөйләшмиләр биредә. Югыйсә була, андый хәлләр дә була аларда... Гөлнара белән без дә, бүлмәгә кереп-чыгып йөрүчеләр, сүзнең ни хакында барганын ишетмәслек, аңламаслык итеп, әкрен генә сөйләшәбез.

...Гөлнара Мөбарәкшинаның кызы Наилә унбишенче февральдән уналтысына каршы төндә чирләп китә. «Аркам авырта», – дигән баланы, таң атканын да көтмичә, хастаханәгә алып китәләр. «Бөерләр түгел... Аркасының кайсыдыр җире авыртканга да охшамаган», – ди табиблар. Анализлар алалар. Һәм...

– Кан анализлары бластлар артуын күрсәтте. Гемоглобины түбән, диделәр. Анысына башта борчылмадым да, үземнең дә гомер буе түбән... Иртән иртүк «Ашыгыч ярдәм» машинасы безне Казанга, Республика балалар клиник хастаханәсенә алып китте. Барысын да

PRESSA.RU

пункция ачыкларга тиеш иде... Бөгелмәдән Казанга кадәр 4,5-5 сәгатьлек юл. Ул араның миңа никадәр озак, ерак кебек тоелганын ничек аңлатыйм икән?! Бер ай килдек кебек... Бала сызлана, хәле авыр... Әмма өметем никадәр зур булса да, акланмады: пункция Бөгелмәдә куелган диагнозның дөреслеген раслады.

Безнең белән мондый хәл булыр дип гомеремдә дә уйламаган идем. Хәсрәт гел көтмәгәндә килә икән... Балада бернинди үзгәреш сизмәдек бит: ябыкмады, борыннан кан китүләр булмады. Хәлем юк, ди иде, тик анысына кем игътибар иткән? Соңгы вакыт урамга чыкмас булды, түгәрәкләргә йөрүен ташлады. «Барасым килми», – ди иде. Укудан кайта – ятып тора, дәресләрен әзерли – тагын ята. Яшүсмерләрдә андый гына хәлсезлек була инде ул дип уйладым.

Өйдә ничек, монда да үзеңне шулай хис итәсең, диләр.

Хастаханәдә узган беренче ике атнаны бөтенләй хәтерләмим. Наиләнең кан басымы ике йөзгә кадәр күтәрелде, һәм аны берничек төшерә алмадылар. Кызым яныннан бер минутка да китмәдем: көндез дә, төнлә дә. Икәү бер караватка ятабыз, әмма бик читен, сыймыйбыз – аңа бит инде 13 яшь. Ярый «раскладушка» куярга рөхсәт иттеләр. Ике ай шулай яшәдек... Аннан табиблар: «Анализларыгыз азрак көйләнде. Йортка күчәргә теләмисезме?» – дип тәкъдим иттеләр. «Роналд Макдоналд йорты» турында нидер сөйләгәннәре колагыма кергән иде, тик: «Кемгә, ничек бирәләр?» – дип, бер дә кызыксынмадым. Әни кеше мондый чакта үзенә җайлы, уңайлы булу турында уйлыймыни? Курка да калдым әле: «Хәлебез үзгәреп китсә?» – дим. «Без бит янәшәдә генә, кирәк булса, керерсез», – диделәр.

...Йортка шулай аяк бастык. Иң башта мондагы чисталыкка шаккаттым. Бөтен нәрсә өр-яңа. Хезмәткәрләр елмаеп кына тора, ягымлылар. Безне бүлмәбезгә озаттылар: чиста урын-җир, ап-ак сөлгеләр. Открытка куйганнар: «Рәхим итегез!» – дип язганнар, шундый матур теләкләр теләгәннәр. Җиңел булып китте... Диагнозны ишеткән көннән соң беренче тапкыр. Монда шулай әйбәт булыр дип күз алдыма да китермәдем. Хастаханәдә дә әйбәт анысы, табиблар да шулкадәр игътибарлы. Әмма анда капельница, уколлар, пункцияләр... Безгә ясамасалар – башкаларга... Янында ятучыларга ясаганны күрү дә авыр, үзеңә кагылганда – әйтмим дә. Ә Йортта онытылып торасың. «Химия» алып чыгабыз да ял итәбез. Тынычта, иркендә... Инде ничә химия терапиясе алуыбызны да белмим. Бик күп! Шактый авырлары – тоташ биш тәүлеккә сузылганнары бар, җиңелрәкләре... Көнгә утызар төймә дару эчәбез хәзер – аны безгә бушлай бирәләр. Янибызга туганнар да килеп тора ала бит. Әтисе килеп китте, ике әбисе, кечкенә улымны да алып килделәр: ул быел өченче сыйныфка бара, аңа да игътибар кирәк.

«На-на» төркеменең элеккеге солисты Владимир Левкин килгән иде безнең белән очрашуга, «Бу чир килеп чыккач, тирә-юнемдәге даирә үзгәрде», – дип сөйләде ул. Ә мин, киресенчә, дусларымның, эштәге хезмәттәшләремнең якынлыгын бу авыр чорда тагын да ныграк тойдым. Ялгыз түгеллегеңне аңлау бик мөһим.

Укытучылар килеп йөри. Кайчак алар килгәндә Наиләнең химия терапиясе алып кына чыккан чагы була. Дәрес кайгысымыни? Тормышта беренче урында сәламәтлек икән – бөтен кешегә шуны телим хәзер.

...Гүзәл Галләмовага да улы Нияз белән өч ай саен хастаханәдә ятарга туры килә: 8 яшьлек чагында малайга шактый катлаулы диагноз куйганнар. Бөерләренең берсен булса да саклап калу өчен көн саен кыйммәтле дарулар эчәргә, әледән-әле капельница астында ятарга кирәк аңа. «Донор кирәк булуы мөмкин», дигән сүзне дә әйтә табиблар, әмма әлегә ул хакта сөйләшергә иртәрәк.

«Ярый»га караганда, «ярамый»лар күбрәк Ниязның тормышында: яшьтәшләре кебек арганчы урамда уйнарга, йөгерергә, су коенырга, авыр күтәрергә ярамый аңа. Бөерләренә көч килмәсен дип, суны да күп эчәргә ярамый, тозлы ризык ашарга да. Салкын тидерергә, грипп белән авырырга... Өченче баласына – төпчек улына шушы диагноз куелган көннән бирле әниләре эшләми. Гаиләнең бар тапканы күбрәк Нияз өчен даруга китеп бара хәзер. Ә аның бер кабы дүрт меңгә якын тора. Бер айга өчәр кап алган чаклары бар. Авыр, әлбәттә, тик зарланмыйлар, даруларны бушлай бирә башлаячакларын көтәләр менә.

– Бу юлы хастаханәгә килгәч: «Бәлки Йортта гына яшәрсез?» – дип тәкъдим иттеләр. Ни дип җавап бирергә дә белми аптырап калдым, үзем күңелемнән уйлыйм: «Түләүледер инде ул... Булмас...» – дим. Әкияткә эләккән кебек булдык менә... Сырхауханә түгел инде: җир белән күк аермасы. Үз өеңдәге кебек рәхәт монда... Ниязга бүлмәбез бик ошады! Чаллыдан кадәр янибызга килеп йөри алмыйлар, ә Йортта, үзебез ни телибез шуны пешереп ашыйбыз. Безгә әле озак торасы – анализлар әйбәтләнгәнче...

Өйдән еректагы өй. «Роналд Макдоналд йорты»нда яшәүчеләр аны шулай дип атый. Ике катлы Йорттагы 24 бүлмәне дә алар өйдәгечә «йокы бүлмәләре» дип йөртә. Һәр гаиләгә – бер бүлмә. Хәер, йокы бүлмәсенә менеп җиткәнче, Йортның бусагасын атлап кергән бала башта «могҗизалар бүлмәсе»нә эләгә әле. Күз алдына гына китерегез: уенчыклар тулы бүлмә. Кибет кебек! Баланы шунда җитәкләп алып керәләр дә: «Җаның кайсын тели – шунысын сайлап ал. Сиңа бездән бүләк!» – диләр... (Бу бүлмәгә иң беренче бүләкуенчыкларны Казан шәһәре мэры Илсур Метшин гаиләсе тапшырган. Теләге барлар – уенчыкларны һәрвакыт китерә, өсти ала!)

Йортта кемнәр яшәячәген Республика балалар клиник хастаханәсенең махсус экспертлар комиссиясе хәл итә. Күбрәк онкогематология бүлеге пациентларын,

беренче чиратта ерактан килгән балаларны урнаштыралар. Барысы да исәпкә алына: гаиләнең матди мөмкинлекләре, баланың хәле. Дәвалану күпме дәвам итә – әни белән бала Йортта шуның кадәр тора ала: бер ел яшәүчеләр дә бар, ярты ел да, ике-өч ай да...

Кайбер балалар авыз-борыннарын маска белән каплап йөрмәсә, җыйнак кына бер кунакханә дип тә уйлап булыр иде бу Йортны. Балалар өчен уен почмагы, әниләр өчен ял итү зонасы, китап киштәсе (үзенең тыңлаучылары арасында акция уздырып, «Миллениум» радиосы дүрт йөздән артык китап җыеп китергән аларга), телевизор, компьютерлар, вай-фай, кер юу машиналары... Зур гына ашханә, суыткычлар: һәрбер әнинең үз урыны, үз почмагы бар монда – савыт-сабасына кадәр бирәләр. «Безнең Йортның иң рәхәт урыны – шушы, – ди «Роналд Макдоналд йорты» менеджеры Аделина Кузина. – Кичләрен монда нинди тәмле исләр чыкканын белсәгез! Әниләр шушында җыела, бергәләп пешерәләр, бергәләп ашыйлар. Җәйге террасабыз бар: иртәләрен чәйне шунда – патиода эчәләр, кичләрен чыгып утыралар. Әниләр – сөйләшә, балалар уйный... Кайбер спонсорлар әниләргә ярма, токмачлар китерә. Хәер, спонсорлар гына да түгел... Әле менә узган атнада бер ханым керде: «Патио ягыннан ишекне ачмассызмы?» – ди. Ачтым. Икәү килгәннәр икән: улы өч зур савыт белән чия кертте. «Боларын күршеләр җибәрде», – дип, кыяр белән помидор, ташкабаклар, слива... Токмач белән тавык та алып килгәннәр. «Гафу итегез, ә сез кем?» – дим. «Сездә узган ел мастер-класс үткәргән идек», – диде дә, ашыгып китеп тә барды. Исемен әйтеп тормады. Әниләр чиядән компот кайнаттылар, тавыкларын кыздырдылар – бөтен йортка көтмәгәндә бер бәйрәм булды...»

Йортта яшәүчеләрне зур бер гаилә дип тә әйтергә буладыр. Әле менә һәммәсенең телендә бер сүз: «Марьяна тәпи китте!» Кемне очратсаң да – сөенеп шуны сөйли. Нәни генә булса да, Марьяна Тодорович инде икенче кабат дәваланырга килгән. Үсеп килгән! Йорттагыларның күз алдында йөреп киткән менә.

– Ачылган көннән башлап, дүрт мең гаилә яшәп китте инде бездә, – ди «Роналд Макдоналд йорты» директоры Юлия Маркова. – Күбесе белән хәбәрләшеп, хәлләрен белешеп торабыз. Табибларга күренергә килгәч, безгә кунакка керәләр. Алар барысы да монда кунакка гына килү турында хыяллана...

«Иң мөһиме: Йорттагы эмоциональ атмосфера, – ди директор. – Әниләр – хәсрәтләрен, балалар авыртуларын онытып торсын дип тырышабыз». Тырышалар дип кенә әйтү аз булыр! Алты хезмәткәр ай саен утызар чара оештыра! Һәр көнне – берне! Бүген аларда кунакта «Прогульщики» рок-группасы, иртәгә – «Ямьле» төркеме, берсекөнгә – «Рубин» командасы, аннары – «Ак барс»лар, язучылар... Бер көнне әниләр янына стилист килә, икенче көнне – визажист, өченче көнне – этикет студиясе... Бүген сабын куыклары очыралар, иртәгә – «Крутые виражи» клубы беговелларда йөрергә өйрәтә, берсекөнгә батутта сикерергә баралар... Әниләр өчен психология мәктәбе эшли. Ә мастер-класслар! Пушкинның Казанда яшәүче оныгы барон Александр фон Гревениц бөтен гаиләсе белән инде аларда ике тапкыр булып киткән. Хатыны Дорсаф биредә яшәүче әниләргә үз милли ризыкларын пешерергә өйрәткән. Тел белмәсә дә, аңлашканнар: ул да дүрт бала әнисе бит.

Авырып китү белән дөнья чикләнә: күпләр аны тәрәзә аша гына күзәтә башлый. Шуңа күрә Йортта яшәүчеләр өчен шәһәргә чыгулар бер бәйрәм! «Казан – бала күзе белән» дигән проект шуңа туган. Гидлар ролен шәһәрнең билгеле кешеләре башкара. Универсиада корылмаларын, университетларны, парк һәм скверларны караганнар, Зәңгәр күлгә җыеналар, Казанның театрлары белән танышырга телиләр. Автобус бирүчесе дә табыла, хөкүмәт эшен читкә куеп торып, экскурсия үткәрүчесе дә. Әйе, дөньяны игелек коткарырга тиеш! Мәрхәмәтлелек, киң күңеллелек...

Йортны тәртиптә тоту – әниләр өстендә. Монда бирәү дә кушканны көтми.

Йортта яшәүче малайлар һәм кызлар автограф җыя: Венера Ганиева, Эльмира Кәлимуллина, Мөнир Рахмаев... Ул исемлек шундый озын! «Роналд Макдоналд йорты»нда бер тапкыр булган кеше аны яшәтү өчен, кечкенә генә булса да, үз өлешен кертергә тырыша бугай. «La Primavera» оркестры (җитәкчесе Рөстәм Абязов), мәсәлән, 4 октябрь көнне Казанда хәйрия концерты үткәрергә җыена. Билет сатудан кергән акча шушы гаилә кунакханәсен тотуга тапшырылачак. Шундый ук хәйрия концертын Венера Ганиева да әзерләп ята. Йортның дуслары – аларга булышучы компанияләр, волонтерлар бихисап! Бик теләсәм дә, мин аларны санап чыга алмам: кулы, йөрәге җылылар – мәрхәмәтле җаннар арабызда бар һәм, иң сөенечлесе – бик күп!

– Тагын бер мөһим әйбер бар, – ди Юлия Маркова. – Гадәттә, мондый чорда гаилә икегә бүленә. Күп вакыт әти кеше читтә кала, йә, сынауларны күтәрә алмыйча, бөтенләй китә. «Роналд Макдоналд йорты»нда гаилә бергә яши ала: әтиләр дә килә, әби-бабайлар да... Йорт гаиләләрне саклап калырга да булыша.

...Директорның читләргә күренми торган бер эше бар: азрак буш вакыты булдымы... Яңа ел алды ярминкәсендә сату өчен чыршыга эләргә уенчыклар тегәргә утыра ул. «Быел 16 гыйнварда ук башладым», – ди. Дөрес, әниләр дә булышкалый. Йортны тоту өчен бер елга унике миллион акча кирәк дидем, шуның ике миллионын биредә эшләүче хезмәткәрләр үзләре таба. Диңгез – тамчылардан җыела...



Ярминкәләрдә сату өчен йомшак уенчыкларны аларга сез дә тегеп җибәрә аласыз. Мастер-классны «Хатын-кыз галәме» сәхифәсеннән карагыз.

ЗАМАН һӘМ БЕЗ

PRESSA.RU



ШАТЛЫКЛАРЫ, МӘШӘКАТЬЛӘРЕ БЕЛӘН ТАГЫН БЕР УКУ ЕЛЫ БАШЛАНДЫ.

Кемнәр өчендер ул әле беренче генә уку елы, ә кемнәргәдер унберенчедер... Ничәнче генә булса да, гамьсез үткән җәйдән соң бала парта арасына кереп утыру игътибарын укуга юнәлтү җиңел эш түгел. Җайлашу өч төрле була: физик, эмоциональ һәм социаль. Алар, әлбәттә, бер-берсенә бәйле. Тәнгә уңай булса гына күңелгә рәхәт. Күңелгә рәхәт булса гына башкалар арасында үзеңне рәхәт хис итәсең.

Фото интернеттан алынды

«МӘКТӘПТӘ БАЛАГА НАЧАР!»

Биология фәннәре кандидаты, доцент Сәҗидә ханым РУСИНОВА балаларның мәктәпкә яраклашуы, заманча итеп әйтсәк, адаптациясе белән утыз елдан артык шөгыльләнә.

– Аның белән бездә 1980 елдан кызыксына башладылар, – ди ул. – Минем диссертациям дә нәкъ шушы мәсьәләгә багышланган иде. «Балага мәктәптә начар» дигән сүзне беренче булып без әйттек. Безгә ышанмадылар, балалар үсәме – үсә, белемне үзләштерәме – үзләштерә! Шулай булгач, әллә нәрсәләр уйлап чыгармагыз, диделәр. Хәтта диссертациямне яклауны кичектерергә туры килде. Нәкъ менә шул каршылык әлеге мәсьәләгә башкаларның да игътибарын юнәлтте.

1990 нчы еллар башында Казанның өч мәктәбендә – 18 нче инглиз телле мәктәптә, 12 нче яһүд мәктәбендә һәм татар кызлар гимназиясендә (хәзер 12 нче татар кызлар гимназиясе) беренчеләрдән булып адаптив каникул кертелде. Министрлыкта моңа каршы чыктылар, өстәмә каникулга рөхсәт алу өчен мәктәп директорларына бик нык көрәшергә туры килде. Әмма тиздән югарыда утыручылар да бу каникулның мөһимлеген күрделәр – балалар авырмый, укулары яхшы бара. «Ник өч кенә мәктәптә, башка мәктәпләргә дә кертергә кирәк!» – диде ул чактагы мәгариф министры.



Биология фәннәре кандидаты, доцент, психолог Сәҗидә РУСИНОВА

Дөресен әйтәм – мәктәптә балага авыр. Җәйге каникуллардан соң беренче өч атнада ул бөтенләй укырлык хәлдә түгел. Өч ай бала ял итте. Шөкер, бала җәй буена үсте, ныгыды. Һәм, күз алдына китерегез, ул 1 сентябрь көнне мәктәпкә бара, шул көннән үк аның укыйсы килергә тиеш. Укытучылар да, әти-әниләр дә аннан яхшы билгеләр таләп итә. Бер төймәгә басу белән икенче режимга күчә торган робот түгел бит ул! Өч ай буена аның бөтен әгъзасы ял итте. Ул шәхси ирек режимында яшәде. Инде шушы рәхәтлеккә тәмам ияләшкән бала мәктәптә укулар башлану белән коточкыч стресс кичерә. Бу – физик та, эмоциональ дә, интеллектуаль дә стресс. «5»ләгә генә укучы бала да, «3»ләгә көчкә баручысы да бердәй кичерә аны. Нәкъ менә шушы урында бер нәрсәне искә төшерик әле. Сәламәтлек ул – физик, психик һәм социаль рәхәтлек. Ә балага мәктәптә 45 минут шыпырт кына утырасы. Аңа физик яктан рәхәт түгел. Аның әле чабасы килә. Дәрестә тик тор, тәнәфестә тагын йөгермә! Өйгә кайт та дәрес хәзерләргә утыр! Бу – аны, чабып барган җирдән тотып алып, бер мизгел эчендә катырып куюга тиң. Күңеленнән ул һаман йөгерә, ягъни фантом эшчәнлеге дәвам итә, ә физик яктан ул инде тик утырырга тиеш. Медицина тарихында бер ир-атның үкчәсен кашый алмаганнан гына вафат булу очрагы билгеле. Кашыр иде, аның ул аягы юк – киселгән. Нәрсә соң ул фантом, дисәгез, фантом ул – озак вакыт дәвамында баш миендә барлыкка килгән модель.

Уку елының беренче өч атнасында мәктәптә балага билге куелырга тиеш түгел – бу минем катгый фикер. Билге куелган очракта да, ул «4»ле яки «5»ле генә булырга мөмкин. Әгәр дә балагызга шушы вакыт эчендә «4»ледән ким билге куялар икән, сез аның конституция тарафыннан яклананган хокуклары бозылуын күтәреп чыга аласыз. Конституциядә нәрсә диелгән: беренче урында баланың сәламәтлеге, диелгәнме? Иң әүвәле – физик сәламәтлек! Стресс исә сәламәтлекнең беренче дошманы. Шулай булгач, бернинди дә «3»ле, «2»ле! Әгәр дә син үзеңне яхшы укытучы дип саныйсың икән, баланың холкын белергә тиешсең!

Өч атнадан соң кризис башлана. Медицинада күптәннән билгеле: кризис ул – яшәргәме, яшәмәскәме дигән сүз. Кризис – организмга алга таба нишләргә дигән сорау? Организм адаптация, ягъни вазгыять белән килешү, аңа ияләшү, күнегү юлыннан китәме, әллә карыша, ягъни күнегергә теләмиме (бигрәк тә малайларда)? Балага роботка караган кебек караучы укытучының укучылары карышу (десадаптация) юлыннан китәчәк. Ә сәламәтлеге какшау баланың организмы гомумән дә дисадаптация халәтенә кадәр килеп җитәчәк. Ә бүген сәпсәламәт бала юк, ул инде туганда ук имгәнеп туа. Бу – чынбарлык. Рафинадланган хатыннар, рафинадланган дөнья. Кеше тормышы хәзер күбрәк утырып уза. Балалар мәктәпкә хроник чир белән килә. Ә инде мәктәпне тәмамлап чыкканда, аларның чирләреннән букет хасил була. Моңа стресс та гаепле. Елның елында, 1 сентябрьдән башлап, без балаларны мәктәптә коточкыч стресска дучар итәбез. Кыска вакытлы гына булганда, стресс хәтта файдалы нәрсә ул. Кыска вакытлы стресс, прививка кебек, организмны зуррак стресслардан сакланырга өйрәтә. Әмма инде стресс озакка китсә, эшләр харап. Бу очракта организм үзен саклау өчен бөтен булган ресурсларын файдалана башлый. Хәтта тияргә ярамый торган «алтын запасына» үрелә. Ә аңа берничек тә тияргә ярамый. Тормышта әллә нинди авыр вакытлар булырга мөмкин, чыдамлык кирәк булыр көннәр алда әле. Стресс нәтиҗәсендә балалар октябрьдән үк авырый башлый. Кайсында – грипп, кайсына салкын тигән. Ата-аналар, табиблар балаларны тиз генә дәваларга керешә. Чирне ашык-пошык дәвалау организмга үзе үк зур зыян сала. Тулысынча дәваланмаган чир, организмның аулак бер почмагына кереп оялый да, тагын берәр җай чыкканын көтеп ята.

РЕЖИМ

Баланы режимга күнектереп, без аның организмын мөмкинлекләреннән файдаланырга өйрәтәбез. Йокларга төнге уникенче яртыдан да соңга калмый ятарга кирәк. Чөнки төнге 12 дән 2 гә кадәр баш мие, көндез сарыф ителгән энергияне генетик ресурслар хисабына тулыландырып, организмны мөмкин булган кадәр савыктыра. Шушы ике сәгать аралыгында Җир шарының электромагнит дулкыннары безнең баш миендәге дулкыннар белән тәңгәл була икән. Иртән көн дә бер вакытта уяныргa күнеккән баш мие безгә иртәгәсе көн өчен кулай модель төзеп бирә – аның буенча организм алдагы көнне артык көч түкми генә уңышлы тәмамлаячак.

ТУКЛАНУ

Бездә сигез төрле режим бар. Кышкы, язгы, җәйге, көзге туклану режимнарыннан тыш, дүртесе ел фасыллары алмашынгандагы режим. Организм өчен иң авыр чор – фасыллар арасы. Аңа үзен яшәтү белән бергә температура, көн яктысы, вакыт күчеше кебек нәрсәләргә дә җайлашырга кирәк. Бу өстәмә көч сорый. Малайлар рационында аксым һәм углеводның тиешле микъдарда булуы мөһим булса, кызлар өчен аксым һәм минераллар беренче урында. Минералларның бернинди дә туклыклы әһәмияте юк, алар матдәләр алмашын көйләүчеләр. Аксым белән углевод тиешле күләмдә булса, ир баланың организмы минераль фонны үзе кайгырта, кызларныкы минераллар даими кереп торуга мохтаҗ.

АРАЛАШУ

Яшермим, хәзерге балалар үзара аралаша белми. Бүген бу беренче урында тора торган мәсьәлә. Бөтенесен үз тирәсендә «биетүче» эгоист үстерәбез. Ә бу 5 яшькә кадәр генә дөрес. 5 яшенә кадәр бала үз даирәсенә кемне кертәсен, кемне кертмәсен «телим-теләмим» принцибы белән хәл итә. Мәктәп яшендә инде ул телим-теләмим принцибыннан чыгып түгел, ә аралашырга ихтыяҗ булганга кертергә тиеш. Әмма мәктәпкә килгәндә балалар һаман да эгоист булып килә. Бишенче сыйныфларга кадәр бара әле бу нәрсә. Димәк: «Мин синең белән дус түгел, син минемчә эшләмисең!» – дигән балада толерантлык тәрбияләнмәгән. Толерантлык ул кемгәдер түзү дигән сүз түгел. Түзү – агрессив халәт, ә толерантлык – башка кешене аңларга тырышу. Андый хисне тәрбияләү көч сорый. Укучы балага исә шуларны белү кирәк:

PRESSA.RU

БЕЛМӘСӘҢ БЕЛ

Бөтен дөньяда 1897 елга кадәр бала организмы олы кешенекеннән берничек тә аерылмый дип уйлаганнар. Болай уйлауның нәрсәгә китергәнен беләбез: XX гасыр башында яңа туган һәр өченче бала үлә барган. 1897 елда рус галиме Николай Гундобин бала организмының өлкәннәрнекеннән бик нык аерылуын язып чыга. Ә инде совет мәктәпләре ачыла башлагач, Надежда Крупская: «Балаларның табигатен белми торып, аларны ничек укытырга һәм ничек тәрбияләргә мөмкин?» дигән сорау куя. Шушы вакыттан балаларның физиологиясе, анатомиясе өйрәнелә башлый. Узган гасырның 50 нче елларында Мета Антропова бала гигиенасына багышланган беренче китапларын бастыра. Россиядә балаларны өйрәнү шуннан башлана.

Балалар дип, малай һәм кызларны бергә атасак та, мәктәп тормышына ияләшү процессы ике җенестә төрлечә бара. Ниһаять, моны аңладылар.

Ят мохиткә тиз җайлаша алган бала мөстәкыйль фикер йөртергә дә тиз өйрәнә.

Гомеремдә беренче тапкыр мәгариф системасындагы гендер бүленеше искә алынган экспериментка шатланам. Күптәннән кирәк иде бу. Ир һәм кыз балалар төрлечә уйлый, мәгълүматны төрлечә кабул итә. Без генетик яктан да төрле. Теләсә нинди яңалыкка ияләшү, алга таба нишләргә кирәген чамалау өчен ир балаларга ун көн вакыт җитә. Шушы вакыт эчендә ул үзеннән бер ел эчендә нәрсәләр таләп ителәсен абайлап ала. Бу аның физиологиясе. Табигать аннан тиз карар кабул итүне, аны тиз тормышка ашыруны таләп итә. Физиология – психосоматикага, анысы, үз чиратында – психофизиологиягә, ягъни белем үзләштерергә әзерлеккә әверелә.

Кызлар әле өч атналап уку турында уйламый да. Алар әле җәйге эмоцияләр белән яши. Каникулда күргәннәрен, кигән киемнәрен тикшерәләр. Хатын-кыз һәрнәрсәгә озак ияләшә. Укытучылар да, әти-әниләр дә моны аңларга тиеш. Шушы өч атна эчендә аларны кызыксындырган нәрсәләр аркылы акрынлап аларның уйларын уку тирәсенә тартып кертү мөһим. Кием-салым белән кызыксыналармы? Бик яхшы! Бәйлә син үзеңнең химияңне әнә шул күлмәкләр белән. Яки математиканы, тарихны... Хатын-кызның акылы – гамәли акыл. Ул үзенә кирәк дип санаганны яхшы үзләштерә. Гомумән, белемнең үзе генә берни бирмәвен инде барыбыз да аңлый. Белем гамәли кимәлдә булырга тиеш. Аны тормышта куллана белү мөһимрәк. Кызлар озак ияләшә дигәннән курыкмагыз. Уку процессына озак керешүләре аларга укырга һич тә комачауламый. Кызлар әле чынлап торып өченче чирек ахырына гына ияләшеп бетә. Аңынчы ул өй эшләрен дә карусыз башкарачак, кагыйдәләрне дә ятлаячак. Чөнки кыз бала җаваплы, ул үзеннән таләп ител-гәнне башкарырга тиеш икәнен аңлый.

Совет чорында без ярыш даирәсендә яшәдек. Хәзерге буын балалары көндәшлек даирәсендә яшисе кешеләр. Көндәшлек даирәсен яхшы мәгънәдә аңларга кирәк. Бу – кешенекен яулап алу дигәнне аңлатмый. Безнең балаларга җәмгыятькә үзенең уникаль, башкаларны кабатламый, фәкать ул гына башкара ала торган сыйфатларын күрсәтергә туры киләчәк. Аның бу сәләте җәмгыять белән дә каршылыкка кермәскә тиеш. Кызганычка, моны бөтен педагоглар да, ата-аналар да аңлап бетерми әле. Алар баланың уникальлеген игътибарга алмый гына, аны үзләре ничек күрергә тели, шулай үстерергә омтыла. Әйтерсең лә, бала – тукыма, ә алар тегүче. Бу тукымадан нәрсә тегәселәре килсә, шуны текмәкчеләр. Бала – әти-әнинең кечкенә күчермәсе түгел. Аңарга әле тагын ике әби белән ике бабайның да гены күчкән. Хәзерге балалар башка. Мин аларны кроссовкалы-биштәрле буын дип атыйм. Тормышны кызыклырак итәргә, күбрәкне белергә омтылучы буын килә.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

УКУЧЫ БАЛАГА

- Әйбереңне сорап торсалар – саранланма, бир; талап алмакчылар икән – үзеңнекен якла.
- Сәбәпсез сугышма.
- Кешенекенә кагылма, үзеңнекен югалтма.
- Уйнарга чакыралар икән – бар; чакырмыйлар икән – уенга кушылырга рөхсәт сора.
- Уйнаганда гадел бул.
- Берәүне дә үртәмә.
- Әләкләмә.
- Горур бул, сәбәпсез күз яше түкмә.

УКУЧЫ БАЛАНЫҢ ӘТИ-ӘНИСЕНӘ

- Иртән баланы иркәләп уятыгыз. Ул сезнең ягымлы йөзегезне күрергә, назлы тавышыгызны ишетергә тиеш.
- Мөмкинлегегез булса, баланы ишектән үзегез озатып калыгыз. Аңа уңыш теләргә онытмагыз.
- Мәктәптән кайтучы балагызны «Бүген ничәле алдың?» дип тә каршыламагыз. Аңа ял итәргә, уйлардан арынырга мөмкинлек бирегез.
- Балагыз мәктәптән күңелсезләнеп кайткан икән, сораулар белән бимазаламагыз. Бераздан ул сезгә үзе барысын да сөйләр.
- Укытучы зарлана дип, балагызны җәберләмәгез. Башта нәрсә булганын җентекләп сорашыгыз.
- Балагыз мәктәптән кайтуга дәрес хәзерләргә утыртмагыз. Кимендә ике сәгать ял итеп алсын.

ЯРАТУ

Бала яратуны сүздә генә түгел, гамәлдә тоярга тиеш. Кочаклап иркәләү, сөю, битләреннән үбү – бала әлегә шуларны ярату дип саный. Балагыздан: «Мине яратмыйсыз!» дигән сүзне ишетәсегез килмәсә, «7 секунд» кагыйдәсен истән чыгармагыз. Теләсә нинди эш-күренеш 7 секунд сорый. 7 секундтан азрак вакыт эчендә булган гамәл баланың исендә калмый. Кочаклыйсыз икән – 7 секунд. Башыннан сыйпыйсыз икән – тагын 7 секунд. Кулын юып килергә кушасыз икән – ванна ишегенә кадәр бергә барасыз, сөлгесен алып бирәсез. Балага үзен яратуларын тою өчен кирәк бу.

ҖӘМГЫЯТЬ



■ Кремльдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм аның тормыш иптәше Гөлсинә ханым исеменнән республиканың 51 иң яхшы гаиләсен кабул итү тантанасы булды. Президент Рөстәм Миңнеханов лаеклы парларны тәбрикләп, гаилә теләсә кайсы илнең нигезе булуын, аның телебез, гореф-гадәтләребез, динебез сагында торуын ассызыклады: «Без гаиләләребез белән горурланабыз, ныклы гаиләләр күбрәк булуын телибез», – диде ул.

■ Татарстан, аның казанышлары белән горурланучыларны берләштерүче «Татарстан командасы» активистлары төрле патриотик чараларны башлап йөриләр. Алар уздырган «Республика тасмасы» акциясе кысаларында Татарстан әләме республика районнарында халыкка таратылды. Ул квест, флешмоб, викторина, бәйге, спорт ярышлары, ишегалды бәйрәмнәре белән үрелеп барды. Бу көннәрдә исә «Республика открыткасы» дигән яңа акциягә старт бирелде. Иҗтимагый инициатива логотибы төшерелгән открытканы республиканың авыл-районнарына гына түгел, дөньядагы теләсә нинди шәһәргә һәркем җибәрергә мөмкин.

■ Татарстанның Казан Кремле һәм Казан федераль университеты бинасы 200 һәм 2000 сумлык яңа купюраларга символ сайлау конкурсының финалистлары дип табылды. Финалга 10 шәһәр чыкты. Аларның һәрберсендә икешәр тарихи урын сайлап алынган. Хәзер бәйгенең III этабы бара. Ул 7 октябрь көндезге сәгать 12 гә кадәр дәвам итәчәк. Җиңүгә дәгъва кылган 10 шәһәр арасыннан бары тик икесен генә сайлап алырга кирәк булачак. Казан җиңсен өчен твоя-россия.рф. сайтында мөмкин кадәр күбрәк тавыш җыярга кирәк.

КОТЛЫЙБЫЗ

■ Арча почта элемтәсе бүлекчәсенең абунә участогы инженеры Рәсүлә Гаффарова «Сөембикә» журналы 2016 елның икенче яртыеллыгында хат ташучылар арасында үткәргән конкурста җиңү яулады. Арча районында журналыбызны яздырып алдыручылар санын ике тапкырга арттырган өчен, аңа махсус бүләгебез – затлы бутикка сертификат тапшырылды. Мондый бәйгеләрне «Сөембикә» журналы киләчәктә дә үткәреп торачак.



МАТУРЛЫК

■ Киләсе елга «Татар кызы» матурлык һәм сәләт халыкара бәйгесе Башкортстанда узачак. Моңа кадәр 6 тапкыр рәттән Чиләбе өлкәсендә генә уздырылган конкурс быелдан төрле төбәкләргә күчеп йөриячәк. Быелгы конкурс финалында 18 яшьлек Эдельвейс Ихсанова Башкортстан данын яклый. «Татар телен үстерәсем, аны таратасым, телебезнең матурлыгын күрсәтәсем килгәнгә катнаштым бәйгедә», – диде ул.

МӘДӘНИЯТ

■ Казан Кремленең «Хәзинә» милли сәнгать галереясында ханбикә Сөембикәгә 500 ел тулуга багышланган күргәзмә оештырылды. Татарстан рәссамнарының ханбикә образын чагылдырган әсәрләре беренче тапкыр бер залда тупланып тәкъдим ителде. Анда Бакый Урманче, Канәфи Нәфыйков, Илдар Зарипов, Рифкать Вахитов кебек рәссамнарның Сөембикәгә багышлап иҗат ителгән төрле жанрлардагы картиналарын күрергә мөмкин.

■ Санкт-Петербургның Горький исемендәге Мәдәният сараенда «Хәзерге татар сәнгате» дип аталган күргәзмә ачылды. Татарстан осталарының рәсем сәнгате үрнәкләре, алтын-көмеш эшләнмәләре, чигүле калфак-түбәтәйләре урын алган әлеге күргәзмәне оештыручылар – Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәре һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллеге һәм «Сөембикә» журналы. Күргәзмә Татарстан Республикасы көне һәм вәкиллекнең 20 еллыгы уңаеннан уза.



МӘГАРИФ

■ «Казан» гаилә үзәге каршындагы мәйданга Татарстан башкаласы югары уку йортларының берничә мең беренче курс студенты Белем көне тантанасына җыелды. ТР Ректорлар советы һәм ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы оештырган бәйрәмдә студентлар, Татарстан һәм Россия флаглары хасил итеп, зур күләмле «төсле» флешмобка тезелде. Беренче курс студентларын котларга республика Президенты Рөстәм Миңнеханов килде. Ул университетларыбыз белән горурлануын, анда бирелгән белемнәрнең көндәшлекне күтәрәсенә ышануын җиткерде. «Без сезнең белемнәргә мохтаҗ, сез – безнең киләчәк», – диде ул.

■ 1 сентябрьдә Татарстанның 45 меңнән артык баласы беренче мәртәбә мәктәп бусагасын атлап керде. Республика мәктәпләрендә бүген барлыгы 380 меңләп бала белем ала. 38 меңнән артык сабый балалар бакчасына урнашты.

PRESSA.RU



■ 2005 елда Актанышта аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтә торган яңа мәктәп ачыла. 2011 елда аңа сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат статусы бирелә. Милләт киләчәге булырдай сәләтле балаларны туплаган уку йорты – Татарстанда беренче карлыгач ул.

■ Ул Татарстанның авыл мәктәпләре рейтингында – беренче урында. Узган уку елында фән олимпиадаларының республика этабында гимназия укучылары 21 (!) призлы урын яулаган.

■ Гимназиягә 5 нче сыйныфтан укучылар кабул итәләр. Аларны татар теле, рус теле, математика, инглиз теле буенча сынаулар һәм тест нәтиҗәләре буенча сайлыйлар. Быел бер урынга өч кеше туры килгән.

■ Әлегә рус телендә дә дөнья күрмәгән «Гарри Поттер и проклятое дитя» әсәрен гимназияне тәмамлаган Айдар Шәйхин татарчага тәрҗемә иткән. «Һарри Поттер һәм ләгънәтле бала»ны гимназия укучылары туган телләрендә – татарчага рәсми булмаган тәрҗемәсе китап булып чыкканчы – үзләренең «Ак җилкән» газетасыннан укып баралар.

■ Гимназия укучыларының чит илгә барып укып кайту мөмкинлеге дә бар. 2015 елда гимназиядән 14 укучы һәм 2 укытучы инглиз телен тирәнтен өйрәнү өчен Мальтага барган.

КЫТАЙГА БАРАСЫ ТҮГЕЛ...

БУ УКУ ЙОРТЫ БАШКАЛАРГА ОХШАМАГАН. АНДА ДӘРЕС-ТӘНӘФЕСЛӘРГӘ КУРАЙ ЧАКЫРА.



Илгиз ШӘКҮРОВ

Ризаэтдин Фәхретдиновның: «Кытайга барып булса да белем ал», – дигән мәгълүм гыйбарәсе бар. Ә мин: «Юк, Кытайга да барасы түгел. Актанышка гына килсеннәр», – дияр идем. Балалар дәресләрдә роботлар ясый, анда һәр кыз бала түбәтәй һәм калфак чигә... Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат бу.

«Без – гади мәктәп түгел»

«Без гади авыл мәктәбе түгел. Биредә белем алган һәр бала киләчәктә милләткә хезмәт итәчәк», – дип каршы ала гимназия директоры Рамил Гарипов. Һәр җиргә татар рухы сеңгән бу уку йортында барысы да тиешле дәрәҗәдә. Заманга ярашлы сыйныф бүлмәләре, өр-яңа техника, басудай футбол мәйданчыгы... Барлык уңайлыклары булган әлеге гимназиядә нибары 160 бала укый. Бер сыйныфта балалар санын 14 тән арттырмыйлар икән. Баштарак гимназиягә Актаныш балалары гына килә, аннары аның даны тирә-күрше районнарда яшәүчеләргә дә ишетелә. Ә берничә елдан уку йортының географиясе тагын да киңәя: Самара, Оренбург, Ульяновск өлкәләреннән, Пермь, Красноярск краеннан, Башкортстан, Удмуртия Республикаларыннан, Казакъстан, Таҗикстаннан, хәтта Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән дә укучылар бар хәзер анда. Бу көннәрдә гимназиядә өй туе. Уку йорты янәшәсендә генә 100 ба-

лага исәпләнгән өр-яңа интернат бинасы калкып чыкты. Анда шартлар иң шәп кунакханәләрдәге кебек. Гимназиядә уку, интернатта яшәү, көненә биш тапкыр туклану өчен бер тиен дә түләргә кирәкми.

«Шушы өстенлекләргә җавап итеп, балалардан тырышып укуны таләп итәбез. Һәр укучының үз максаты, үз юлы булырга тиеш», – ди Рамил Марат улы. Биредә сәләтен, мөмкинлекләрен исәпкә алып, һәр укучыга аерым программа төзиләр. 160 балага – 160 программа... Ничек төзеп бетермәк кирәк соң аларны?! Уйларымны сизгәндәй: «Бездә укытучылар да укучылар кебек үк сәләтле бит. Сәләтле балалар белән бары тик сәләтле укытучылар гына эшли ала», – дип, директор серне ача.

Гимназия КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты белән дә актив хезмәттәшлек алып бара. Атна саен институт галимнәре укучылар өчен онлайн дәресләр үткәрә. Директорның уку-укыту эшләре буенча урынбасары Рузилә Гарипова да гимназия укытучыларына таләпләр зуррак икәнен кат-кат искәртә. «Башка мәктәпләрдә укытучылар дәресләре тәмамлануга кайтып китә, ә безнең гимназиядә тормыш башлана гына әле. Барлык сыйныфларда да ким дигәндә ике фәннән өстәмә дәресләр укытыла. Журналистика, робототехника, гарәп каллиграфиясе, 3D модельләштерү...» – дип сөйләп китә ул. Шулайдыр шул. Гимназиянең укучылары гына түгел, укытучылары да төрле яклап камил шәхесләр ләбаса! «Ел укытучысы-2015» республика бәйгесендә «Иң яхшы химия укытучысы» исеменә лаек булган Рузилә ханым үзе гимназиядә «Түбәтәй кияр идем» түгәрәген дә җитәкли. Түгәрәкләрдә чигелгән түбәтәй һәм калфаклар күргәзмә экспонатлары гына түгел, аларны гимназиягә килгән кунакларга да бүләк итәләр икән. Бу калфакларны Актанышта сувенир итеп тә сатарга ниятлиләр.

Без – бер адымга алда

Гимназиянең мактанырлык укучылары шактый. Узган ел 10 нчы сыйныф укучысы Эльмира Вафина хокук белеме буенча Бөтенроссия олимпиадасының финал этабында призер булган. 2015 елда чыгарылыш сыйныф укучысы Айдар Шәйхин тарих фәне буенча Бөтенроссия олимпиадасының финал этабында абсолют җиңү яулаган иде. Татар теле һәм әдәбияты халыкара олимпиадасының Гран-при иясе дә ул, «Умники и умницы» тапшыруы финалисты. Уку йортының табышына әйләнгән «Гыйлем» проектын да шул ук Айдар уйлап таба. Фән, белемнәр һәм технологияләр турында татар телендә сөйли, мәгълүмат алуны җайлаштыру өчен мультимедиа ресурслары әзерли торган интернет-проект ул. Әлеге проект бүгенге көндә Казан (Идел буе) Федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты белән берлектә тормышка ашырыла. «Белемем, уңышларым, дусларым – барысы да моннан», – ди Айдар.

Данил Әхмәтшин дигән егет исә гимназиядә уку елларында компьютер, техника өлкәсендәге сәләте белән таң калдырган. Уку йортына аны Красноярск краеннан Айдар Шәйхин чакырып китергән. Данил туган телен аерым сүзләр һәм гыйбарәләр дәрәҗәсендә генә белгән. Егет, гимназиядә уку дәверендә, үз компаниясен булдырган! Ул «Избушка» дип атала икән. Компания төрле радиодетальләр: моторчыклар, резисторлар, үткәргечләр җитештерүгә нигезләнгән. Әлеге детальләрне теләсә нинди өлкәдә кулланып була. Мәсәлән, «акыллы өй» системалы йортлар төзегәндә. 2013 елдан эшләп килүче «Мирасыбыз» проектын да шул Данил башлап җибәргән. Проект кысаларында укучылар махсус интернет порталында иске татар язуларын урнаштырган. Бу проектка хәтта Иран һәм Кытай татарлары да кушылган.

Гимназия татарча сөйләшергә өйрәткән балаларның берсе – Элина Минниярова. Таҗикстаннан бирегә килгәндә шундый зур уңышларга ирешәсен белдеме икән ул? Татар телен өйрәнүен иң зур уңышы дип саный Элина. Укырга килгәндә татарча бер сүз дә белмәгән кыз бүген татар телен «су кебек эчә». Җитмәсә, ул әле Халыкара татар теле һәм әдәбияты олимпиадасы призеры! Балачагыннан татар мохитендә тәрбияләнгән балалар булдыра алмаганны булдырган бит ул! «Чит телләр белү – байлык, ә туган телеңне белү – бәхет. Гимназия миңа әлеге бәхетне бүләк итте», – ди Мәскәү Россия милли тикшеренү медицина университетына укырга кергән Элина. Үзе белән булган кызыклы хәлләрне дә искә төшерде: «Гимназиядә укыганда сыйныфташым Фәридә үз авылларына кунакка алып кайтып йөрде, – Тәкмәк һәм Югары Яхшый авыллары турында шулхәтле бирелеп һәм яратып сөйли Элина. – 1 Май көнне Зиннәтуллиннар гаиләсендә «карга боткасы» ясадык. Ишегалдында учак кабызып, зур казанда ботка пешердек. Чын татар кызына әйләнүемә Зиннәтуллиннарның өлеше әйтеп бетергесез зур. Алар миңа татар телен өйрәнергә ярдәм итте, татар халык ашларын пешерергә, халкымның гореф-гадәтләрен үтәргә өйрәтте», – дип, рәхмәтен белдерде ул.



Тулысынча сайтыбызда укыгыз.

Иннополиста робототехника буенча дөньякүләм олимпиаданың Бөтенроссия этабы узды. Бу – Россиянең 45 төбәгеннән килгән 800 укучы бала дигән сүз. Олимпиада нәтиҗәләре буенча, җиңүчеләр Һиндстанда узачак халыкара ярышларда катнашу өчен Россия җыелма командасына керә. Роботлар төзү дөньякүләм олимпиадасы тарихы 12 ел белән исәпләнә. Робототехниклар олимпиадасын Россия беренче тапкыр 2014 елда кабул итте. Олимпиада хәрәкәтенә 50 илдән 20 мең команда теркәлгән. Россия җыелма командасын Олимпиадага Иннополис университеты әзерли.

Бу уку йортында 7 мең югары сыйныф укучысы STEM-программа буенча белем ала. Әлеге программа робототехника, математика һәм физика, команда эшенә укыту кебек курсларны үз эченә ала. 13 мең укучыга вузга кадәрге белем бирелә.

PRESSA.RU



Фото: Алинә Галиәхмәтова

ЙӘ ДӨНЬЯНЫ ҮЗГӘРТӘМ МИН БҮГЕН...



Фәнзилә
МОСТАФИНА

«МОНДА ҮЗ ФИКЕРЕН КЫЧКЫРЫП ӘЙТЕРГӘ КУРКА ТОРГАН ЯШЬЛӘР ҖЫЕЛГАН МИКӘННИ СОҢ!» – VII БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ФОРУМЫНДА БАШЫМА КИЛГӘН БЕРЕНЧЕ УЙ ШУЛ БУЛДЫ...

Без, 900 гә якын делегат, Казансу буенда җыелышып, танышу уеннары уйныйбыз, шул рәвешле үз кешеләргә әйләнәбез дә, төшке ашны ашарга ашханәгә юнәләбез. Мин килеп җиткәнче хәйран гына чират сузылган. Койрыкка барып басам да, танышуны дәвам итәргә теләп, янәшәдә торган егеткә сүз катам. Үзебезнең Татарстанныкы икән. Чират озын – сүз күп. «Их, монда җыелган 900 кешегә агач утырттырырга иде. Төрле җирдә яшәүче татар яшьләре Казанга юлны онытмасын өчен тагын бер сәбәп булыр иде», – ди егет. Карале, яхшы фикер бит! Миннән хуплау ишеткәч, әңгәмәдәшем илһамланып китә. Милләтне саклап калу, татар телен популярлаштыру буенча идеяләре бар икән – бик тәмләп аңлата. Ул сөйли тора, ә минем башта бер уй бөреләнә: «Егет сөйләгәннәрне сүздә генә калдырмаска иде...» «Әйдә, болар хакында язып чыгабыз!» – дим, уйларымнан бүленеп. Яңа танышымның күзләре түгәрәкләнә: «Син нәрсә?! Аннары мине шул ук көнне эштән куалар бит!» Минем ач вакыт, ачулы вакыт. «Язып чыгарга да, эшләргә дә курыккач, боларны ник сөйлисең соң? Ашханәдә шыпырт кына сөйләшкәннән татар теленә ни файда?» – дип куям. Дәшми. Мин дә җавап көтмим. Шулай бетә – ниһаять, чиратыбыз килеп җитеп, егет белән юлларыбыз аерыла.

Шундый күңелсез нотадан башланды минем өчен быелгы форум. Тик икенче көнне үк кәефем яхшы якка үзгәрде. Фикерле яшьләр, үз сүзен әйтә ала торган яшьләр күп иде җыенда. Әстерхан өлкәсендә нәшер ителә торган «Идел» газетасының баш мөхәррире Динара Мәҗитова әнә проблемасын трибунадан ук яңгыратты: «Мин биш ел Казан университетында укыдым. Безне татарча укырга да, язарга да өйрәттеләр – сөйләшергә генә өйрәтмәделәр. Балаларым ана телен минем кебек утыздан узгач кына түгел, кечкенәдән үк өйрәнсеннәр иде. Ә моның өчен төбәкләрдә татар мәктәпләре кирәк...»

«Кирәк!»ләр күп... Төркиядәге татар яшьләренә, мәсәлән, латин әлифбасында язылган татарча китаплар кирәк. «Бездә яшьләрнең күбесе кириллицаны танымый. Ә латин хәрефле китаплар сирәк. Китап булмагач, телне дә өйрәнү читен. Төрекләшәләр», – ди Измир шәһәреннән килгән Баһадир Акташ. Ул үзе татарча бик яхшы сөйләшә. Гаиләләрендә электән килгән бер кагыйдә бар икән – үзара фәкать татарча гына аралашу. Хәер, егет моның белән генә чикләнмәгән. Үзлегеннән кирилл әлифбасын өйрәнгән, әдәби телне үзләштерү өчен китаплар укыган, Казан татарлары белән аралашкан. Хәзер рус телен өйрәнмәкче.

Татар авылларын саклап калу өчен анда яшьләргә эш булдырырга кирәк. Монысын Түбән Новгород өлкәсенең Уразавыл егете Рөстәм Билал әйтә. «Яшьләр өчен социаль объектлар да булдырылсын иде. Капка төбендәге эскәмиядә җыелышып, кич утырып кына телне саклап калып булмый бит», – ди егет. Алар да «тел» ди, алар да татар мәктәпләре булмавына борчыла. Ул укыган туксанынчы елларда Уразавыл мәктәбендә бер татар сыйныфы булган, ә хәзер татар теле – факультатив рәвешендә генә.

«Кирәк» дигән сүзне читкә куеп, үзләре эш күрсәтә башлаган яшьләр дә күп. Энҗе Бәйрәмова (язучы Нур Әхмәдиев оныгы ул!) өч ел элек Австриядәге Вена дәүләт университетында биология фәнен өйрәнә башлаганда, илдәге татарларны берләштерүче оешма кәгазьдә генә калган була. Яшьләр берләшеп, «Мирас» дигән яңа оешма булдыралар. Аларның тырышлыгы белән быел Австриядә Сабан туе үтте. Тарихта беренче тапкыр!

Киевтагы «Нур» яшьләр берлеге һәр якшәмбе саен татар теле дәресләре уздыра. «Муса Җәлил, Габдулла Тукайны искә алу кичәләре оештырабыз, Украинада татарлар белән бәйле булган тарихи урыннарга экскурсиягә барабыз. «Ана теле» программасына да кушылдык», – дип горурланып сөйли Донбасста туып-үскән Илдар Кантиев. Аларда Сабан туе гадәти күренеш инде.

«Кирәк» дип кенә утырмый актив татар яшьләре, ул «кирәк»не гамәлгә ашыру юлларын эзлиләр, табып та күрсәтәләр.

Быелгы форумда 50 яңа проект идеясе барлыкка килде. Егетләр һәм кызлар, төркемнәргә бүленеп, концепциясен уйлый-уйлый төзеде ул проектларны. Ни генә юк: «Татар йорты», «Мәтрүшкә-фест», «Татарча Казан буйлап», Бөтендөнья татарлары өчен коучсерфинг челтәре – «Кунакка»... Татар яшьләре форумы рәисе Тәбрис Яруллин әйтмешли, «кәгазьдә генә калмыйча, тормышка да ашырылсыннар иде инде».

Чараның ахыргы көнендә яшьләр адреслар алмаша, бер-берсенә әйтелми калган сүзләрен җиткерергә, Казанны фотоистәлек итеп саклап калырга тырыша. Ә мин беренче көнне үк тел очымда йөрткән соравымны делегатларга бирергә ашыгам: «Форум сезгә нәрсә бирде?» Яңа дуслар, илһам, үз проектымны тормышка ашырырга көч, диләр. Ә иң ихлас җавап – форумга кунак буларак килгән Әмрә Акташныкы: «Мин монда мәхәббәтемне таптым!» 2004 елда узган иң беренче форумда танышканнар Әмрә белән Сәрия. Ә ике елдан өр-яңа татар гаиләсе туган. Бүген әлеге гаиләдә Чулпан белән Айдан исемле ике бала үсеп килә.

...Яңа танышларның адреслары һәм телефон номерлары алынган, истәлеккә фотога төшелгән, сорауларга җаваплар табылган, инде форумга нәтиҗә ясасаң да була. Шул вакыт берәү исемем белән дәшә. Беренче көнне ашханәдә танышкан егет! «Сез миңа бик дөрес этәргеч бирдегез бит әле. Бер проектымны тормышка ашыру юнәлешендә эш башладым», – ди. «Ашханәдәге сөйләшүдән соңмыни?» – дим, гаҗәпләнүемне яшерә алмыйча. «Әйе!» Бик тиздән яңа милли проект турында ишетәчәгебезгә ышандыра торган итеп әйтә ул моны!

PRESSA.RU



Фото: Алмаз Закиров, Илгиз Шәкуров

АКТАНЫШ ДИГӘН ИЛ БАР...

(Ахыры. Башы 8 нче санныбызда.)

ИРТӘНГЕ СӘГАТЬ ДҮРТТӘ ДУСТЫМА СМС ОЧТЫ: «МИН АКШКА ЮЛ ТОТАМ, КАРШЫ АЛЫРГА ӘЗЕРЛӘНЕГЕЗ».



Эльмира ЗАКИРОВА,
Фәнзилә МОСТАФИНА

АКШ дигәне әллә кайдагы океан аръягы түгел, Татарстандагы Актаныш районы. Актаныш яшьләре үзләре, район атамасын кыскартып, шулай дип йөртә. Мин дә аларга иярдем әле: АКШка барам!













Такталачык та, Уразай да... АКШта!

Бу якларда берничә тапкыр булганым бар иде. Шуңа күрә бик белдекле кыяфәт чыгарган булып барам. Монысы Пучымы? Беләбез Пучыны! Байсарда да булган бар! Кадермәт, Сәфәр, Киров – алары да таныш. Актанышның үзендә дә аз йөрелмәде. Һи, дип уйлыйм эчемнән генә, ярты районыгызны беләм икән бит инде, йә, тагын нәрсә күрсәтерсез?! Күрсәттеләр. Шаклар катарлык, гаҗәпләнүдән телләр шартлатырлык булды!

Бер дә барганым булмагач, Такталачык–Уразай маршрутын сайладым. Такталачык – татарның беренче трагик артисты Мөхтәр Мутин, Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзал, татар галиме Альберт Фәтхи, шагыйрь Ленар Шәехне биргән як. Авылга керү юлында автобусыбыз туктый. Нәрсә булды икән, дип тәрәзәләргә үреләбез. Булмаган – Такталачык халкы безне каршы алырга авыл башына кадәр төшкән икән. Тарантаслы атларда! Милли киемнәрдән, гармуннар белән! Юл уртасында җилкенеп биеп алгач, кәефләребез тәмам күтәрелеп, авылга юл тотабыз.

«Уң якка карагыз әле: болар – Гамил Афзал өянкеләре», – безне шулай авыл белән таныштыралар. Халык шагыйре кайчандыр бу агачларны үзе утырткан булган, диләр. 1931 елның августында кулак гаиләсе дип сөргенгә сөрелгәндә ун яшь була аңа. Онытмый шагыйрь өянкеләрен, күп еллар үткәч, «Өянкеләр моңы» дигән җыр да иҗат итә. Гомумән, авылы турында күп яза, матур итеп яза ул.

Кайтты... хәтер булып кайтты Гамил Афзал. Аның исеме язылган элмә тактаны ачарга шагыйрьнең кызлары да килгән иде. «Әти туган авылы турында сөйләргә яратмады. Тик гомере буе аны сагынып яшәде», – дип искә алды алар.

Ял иткән арада җырлап-биеп алалар – печән өмәләре шулай узган лабаса.

Мөхтәр Мутинга да элмә такта куйдылар Такталачыкта. Туганнары, Мутин нәселе дәвамчылары җыелган иде. Истәлекләр барладылар: «Сәхнәдә бөтен җаны-тәне белән бирелеп уйный торган булган ул. Мөхтәр Мутин да сөрелгән, «халык дошманы» булып, Колыма җирләрендә иза чиккән, шунда эзе җуелган...

Уразай авылына кузгалабыз. Авыл башында – Кирәмәт тавы. Милли киемле егет һәм кызлар печән чабалар, эскерт куялар, шунда ук казан асылган.

Монда да бик әзерләнеп көткәннәр безне. Тауга күтәреләбез.

PRESSA.RU









Мондый җирдә яшәп, язучы булмый хәлең юк!

«Әнә генә Башкортстан!» – дип төртеп күрсәтәләр, күрше республика кул сузымында гына икән. «Безнең Уразай чәен эчеп карагыз әле!» – касәдәге сөтле чәйнең хуш исен әйтеп аңлатып бетерә торган түгел. Тәмле чәй белән телемне йотканчы, сорап калырга ашыгам: «Нинди үләннәр салдыгыз бу чәйгә?» Чәй кайнатып торучы егет балкып елмая: «Анысы сер! Чәебез сагындырса, тагын килегез», – дип күз кыса. Әллә кайнар чәйдән, әллә елмаюдан – эреп китәм.

Җигүле атларга утырып, авылга төшәбез. Безнең ат Кашка кушаматлы. Бу сиңа Казан урамындагы тынчу кызыл автобус түгел инде! Балитәкле күлмәкләрдән, чулпыларын чыңлатып, ат арбасында печәннән кайтып килүче әбиләребезнең яшьлегенә кызыгып куям.

Уразай тулы – риваять. «Әнә анда – Ана тавы. Тау башына менсәң, Агыйдел уч төбендәге кебек күренеп тора. Авыл хатыннары шунда менеп, сугышка киткән ирләрен, улларын көтә торган булган». «Ә Кирәмәт тавы, имеш, Алып батыр чабатасын каккан урында пәйда булган. Бик борынгы заманнарда безнең якларда шундый алыплар яшәгән, дип сөйли иде безнең әбекәй». Боларны тыңлыйсы да тыңлыйсы һәм ышанасы килә.

Драматург Риза Ишморатның әтисе туган нигезгә дә кердек. Риза ага бик күп әдипләрне сыйлаган бакчада чәй эчтек. Өй тәрәзәсеннән карыйсың – өскә ишелергә торган урман, тау, икенче якта – җәйрәп яткан күл.

Җамбай күле буена төшәбез. Олысы да, кечесе дә ду китереп бии, өздереп җырлый. Актанышта балалар тәпи киткәнче үк – биергә, теле ачылганчы ук җырларга өйрәнә диярсең, билләһи!

Өстәл янына чакыралар. Күлдән тоткан чуртан шулпасы белән сыйланабыз. Мондый балык ашы ашаганым юк иде әле. Ә күлдә яшьләр көймәдә йөри. Аптырап калмаганнар Уразайлар, көймәне үзләре ясаган. Берсенең борыны очлы түгел, шакмаклы, сал рәвешендә. «Утырыгыз, аккош күрсәтәм!» – ди көймәдәге егет. Утырасы килә, тик йөзә белмим бит, шуңа күрә куркыта. «Без булганда куркалармы инде?!» – ди Уразай егетләре. Тәвәккәллим – сал-көймәгә утырам.

Күлгә кергәч, курку онытыла икән. Ишкәкче белән сөйләшеп китәбез. Ранас Казанда укып кайткан да туган авылында төпләнгән, хатыны белән ике бала үстерәләр. Җирдән аерыла алмагандыр, дим. Уйларымны ишеткәндәй: «Җире генәме соң, урманы, суы, таулары – берсен дә калдырып китә алмадым», – дип куя. Минем Арчадан икәнлекне белгәч: «Сезнең якта бигрәк кызык инде, «ич», «әчкеч» дип сөйләшәләр», – дип елмая. Үзегезне генә белегезче! Бер көн эчендә өйрәнгән сүзләремне саныйм: «бәй», «апаем», «бармаем», «нәмә», «нәмәнди», «ярамыгыз» («ярыймы?» дигәнне шулай матур итеп җырлап әйтәләр монда)... Икәүләшеп көлешәбез.

Көймә ярга килеп туктый. Тагын бер тапкыр тузан туздырып биеп алганнан, Уразайның тәмле чәеннән авыз иткәннән соң гына кайтыр юлга кузгалабыз. Автобус тәрәзәсеннән Актанышның үзенә генә хас искиткеч табигате кул болгап озатып кала. Ә күңелдә якташым язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең «Актаныш басмалары» дигән истәлек язмасындагы сүзләр бөтерелә: «Безнең Татарстанда шушындый урын бармыни? Мин бит таусыз, таш басулы, урманлы, фәкыйрь, мескен елгачыклы Арча ягында туып үскән!..»

Сөн буенда кичке уенда...

Уфа губернасы Минзәлә өязе Байсар волосте... Актаныш районына кергән хәзерге авыллардан

дүрт мәхәлләле бердәнбер торак пункты булган ул. Ак, Сары, Яшел мәчетләре белән дан тоткан. Пугачев яулары, Гражданнар сугышы, сәнәкчеләр фетнәсе, ак чехлар, Колчак армиясенә каршы канлы бәрелешләр... Барысы да узган бредән. Хәзер менә «Ак калфак»ларның бер төркеме шунда бара. Юл өстендә Богады, Чишмә, Аккүз, Кадермәтләр кала. Һәркайсының үз йөзе, үз җыры. Узган гасырның 70 нче елларында Сара Садыйкова белән Мостафа Ногман Сөн буендагы бу гүзәл авыллар турында җырлар иҗат иттеләр. Ә шул җырлардан юллар басу капкасыннан ук каршылый иде:

«Бер гүзәлен сагынам Чишмәнең,
Оныталмасам аны нишләрмен».

Байсар турындагысы «Шәймәрдәнов комиссар» дип атала.

...Авыл башында безне театрлаштырылган тамаша көтә иде. Байсарлар «Кызыл Сөн» колхозын оештырып йөри. Волость рәисе – авылдашлары Шәйгәрдән Шәймәрдәнов. Соңрак ул ТАССРның Халык Комиссарлары Советы рәисе дәрәҗәсенә үк күтәрелә... Әнә ул, мәһабәт гәүдәле, мыеклы, кара тужуркадан, кепкадан (районның атаклы артисты Робсон Мусинга Шәймәрдәнов булу ничек килешә!) Авыл халкы – мәдәният йорты мөдире Әнвәр, җирлек җитәкчесе Рамис, укытучы Сәлимә апа, Фәнзилә, Рузалия, Маратлар, тагын әллә кемнәр ат, ашлык, амбарлар, дип гөж килә. Күмәк хуҗалыкка язылу бара. Ул арада кыңгыраулы җигүле атлар килеп туктады. Мөхтәрәм кунакларны тарантаска утыртып, авыл эченә алып кереп китте. Мурманскидан килгән 80 яшьлек Гөлҗиһан апа Садыйкова купшы калфагы, затлы камзул, бәбәй итәкле күлмәге, чигүле читекләре белән, әйтерсең, шул чорның бер бай хатыны! Авыл халкы гына түгел, үзебез дә театр тамашасына кереп киттек шулай. Чиратта – революциягә кадәр үк салынып, искиткеч биналары белән әле дә сокландырып торучы Байсар больницасы. Сугыш елларында ул госпиталь булган. Хәзер – Байсар табиблык амбулаториясе. Чәчәкләр, чәчәкләр... Ак халатлы табиблар, шәфкать туташлары бөтенләй бүтән вазыйфада бүген: үлән чәйләре, үзләре пешергән камыр ризыклары белән сыйлыйлар. Кечкенә янчыкларда сувенирлар да әзерләгәннәр. Киптерелгән ромашка, мәтрүшкә, бөтнек, исле үлән, гөлҗимеш...

100 еллык тарихы булган Байсар мәктәбе тукталышы – үзе бер вакыйга. Мәктәп тарихы әллә ничә томлык альбом-китап итеп язылган.

Шәймәрдәнов һәйкәленә чәчәкләр салып, «Мөсаллия» мәчетенә кереп чыкканнан соң, сәяхәтчеләрне кызык тамаша көтә иде. Авылның үзәк урамына урнашкан Андрей купец йортлары, тирә-якта дан тоткан Байсар базары безне узган гасырларга кайтарды да куйды! Шау-гөр килә базар! Шәрык базарымыни! Йомырка, кабак, бал, каймак, үрелгән кәрзиннәр, мамык шәлләр, капчыклап он, ат дагалары, тагын әллә ниләр саталар. Хәтта кәҗәләр дә бар! Мине кулдан ясалган агач таракны алырга кыстыйлар. Уфа кызы Гөлнаритага, килешә ди-ди, фирүзә төсендәге муенсалар тәкъдим итәләр. «Минекен ал!», «Минеке шәбрәк!» дип, товарларын мактыйлар. Коймаларга келәмнәр эленгән. Биредәге чуарлыктан күзләр камаша. Сатучылары – авыл халкы! Чын тамаша, чын театр!

Аннары кунакларга Сабантуйга бүләк җыю йоласын искә төшерделәр. Колгага сөлге, яулыклар элеп, урамнарны карый-карый, җәяүләп кенә Сөн буена кичке уенга юнәлделәр. Анда – җыр, бию, уеннар. Яшел мәйдан уртасындагы калай мичтә тары тәбикмәге пешә. Аны каз мае белән майлап, табынга китерәләр. Хатын-кызлар ничек пешерү серләре белән кызыксына. Монда да сувенирлар өләштеләр: каз каурыеннан ясалган май канатлары бәлеш-өчпочмакларны майларга менә дигән.

...Әлем үзенчә каршыларга, үзенчә шаккаттырырга тырышкан. Дилбәр Әнвәрова кебек бөтерчек кебек бөтерелеп, бөтен җанын, йөрәген салып эшли торган җирлек җитәкчесе булганда соң!.. Тугайларында Әлфия Афзалова җырлап үскән авыл бит! Балалар бакчасындагы «Әбием сандыгы» тамашасы да, Курчаклар парады да, Мәдәният йорты каршындагы авыл яшьләре концерты да, икмәк пешерү комбинаты да, фермерлары да һаман күз алдында тора. Тимеркулда менә – мунча себеркесен бәйләргә өйрәттеләр! Печән куышына кереп үлән чәйләре эчтек. Солтангол буасы янында инде композитор Илгиз Закиров, апасы Луиза Исламова (Сиринә, Артур Исламовларның әнисе!) җырлары белән сәламли иде.

Болай уйный белгән халыкны берәр режиссер, массовкада катнаштырып, рәхәтләнеп кинога төшерер иде!

...Без, гадәттә, чит илләргә барып кайткач, күргәннәребезне авыз суларын корытып, шаккатып, могҗиза итеп сөйлибез. Алып кайткан сувенирларыбызны талисман урынына йөртәбез. Актаныштан да шундыйрак халәттә кайттык. (Чигүле кульяулыклар, җырлар тулы кассеталар, дару үләннәре бик кадерле миңа.) Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең туган авылы Әнәктә, Минтимер Шәрип улы туган йортта ачылган музей-йортта булу, Шәрип абзыйның алма бакчасында чәй эчүләр...

Болар һәркайсы иркенләп аерым язарлык матур истәлекләр. «Ак калфак»лы ханымнар сокланып, әллә никадәр тәҗрибә, рухи байлык туплап китте Актаныштан. Актаныш турындагы җырлар исә сәфәребезнең аерылмас юлдашы булды.

Очып кына китәр идем
Актаныш якларына...

Польшадан килгән Фәридә, Австралиядән килгән Сафия ханымнар... күр, тагын киләбез әле Актанышка, дип саубуллашалар.

PRESSA.RU



ТӨШЕММЕ, ӨНЕММЕ ДИП ТОРАМ, КОЛАК ТӨБЕНДӘ ГЕНӘ ДҮРТ-БИШ ХАТЫН-КЫЗ КЫЗУ-КЫЗУ БӘХӘСЛӘШӘЛӘР. ТӨН УРТАСЫНДА ҖӘЛИЛ ХӘЗРӘТНЕ БҮЛЕШӘ БОЛАР. ҺӘРКАЙСЫ АНЫ ҮЗЕНЕҢ ЯКТАШЫ ИТӘРГӘ ТЕЛИ. БУ СӨЙЛӘШҮ КАЗАННАН 500 ЧАКРЫМ ЕРАКЛЫКТА – УФАДА БАРА.

Фәния ХУҖАХМӘТ

ҖӘЛИЛ ХӘЗРӘТ

Көннәрнең иң кыска вакыты, яктыра башларга өлгерми, караңгы төшә, салкын, буран. Рәсәйнең кышкы каникулда чагы. Кемнәрдер тауларда, кемнәрдер диңгез буйларында, кемнәрдер кунакта – һәрберсе үзенчә бәхетле. Бу хатыннар, апалар, туташлар, сеңелләр – Уфа шәһәренең элеккеге «Луч» кинотеатрының заман таләбенә ияреп, «Ихлас» мәчетенә әйләнеп киткән, караңгы төннәрдә ап-ак корабль кебек күренгән бинаның идәненә тәгәрәшкән элеккеге укытучылар, табиблар, тәрбиячеләр, бүгенге көннең әдәп-әхлак укытучылары – бәхетлеме? Аны күрер, аңлар өчен араларына керергә, алар белән янәшә ятып йок-ларга, бергә яшәп алырга кирәк. Безне монда «Ихлас»ның имам-хатыйбы Мөхәммәт хәзрәт Галләм, аның мөгаллимәләре тартып китерә. Телефон аша хәлләрен генә сөйлиләр, кызыктыралар. Без исә ел-ның теләсә кайсы вакытында китап-календарьларны, кучтәнәчләрне төйибез дә, юлга кузгалабыз. Кайбер чакта шәкертбикәләр йөзгә якын була, артып та китә. Бер атнага якын алар моннан чыкмый. Иман ныгыталар. Чып-чын мөслимә булып яшәп алалар, яшәргә өйрәнәләр. Коръән хәрефләре ятлаудан башлап, бәлеш пешерергә, тәмле корт ясауга кадәр. Гаҗәп үтемле вәгазьләр тыңлыйлар, кызыклы шәхесләр белән очрашалар, үзләре дә сөйлиләр, тәҗрибә уртаклашалар. Инде менә төн уртасында Җәлил хәзрәтне бүлешәләр. Йокыга оеган җиремнән торып утырырга мәҗбүрмен. Түзеп торып буламыни?

– Балтачныкы ул! – дим. – Татарстан Балтачыныкы.

Борбашныкы дип тормыйм. Җәлил хәзрәткә тыңларга халык кына булсын. Кулаткыга да, Башкортстанга да барырга әзер ул, көне-төне сөйләргә дә әзер. Сөйләүчеләр күп лә ул, тыңлаучысы кирәк. Тыңлаучылар да күп. Аңлаучылар кирәк. Анысы инде сөйләүчедән күбрәк тора.

Беркөнне август башларында бер мәчеттә җомга вәгазе фәхешләргә багышланган иде. Әй, тиргәп тә

карады инде шуларны хәзрәт, ләкин аларның берсе дә мәчеткә җомга намазына килмәгән иде. Ишетмәделәр, вәгазь алар өчен иде бит. Әлбәттә, фәхешлек тә, шәрәлек тә мөселманнар өчен генә түгел, бөтен дөнья өчен куркыныч. Шул ук теманы Җәлил хәзрәт ничек ачканын, ничек сөйләгәнен күз алдына китерәм. Кем өчен, кайда сөйләгәнеңне алдан ук чамалап куярга кирәк. Әйе, ул хатын-кыз яшәешенең башы, дөнья тоткасы икәнен бик белә. Шулар белән эшли ул. Әлбәттә, беренче эшнең башы – балаларда. Имансыз, динсез хатыннан иманлы бала туамы?! Туа икән шул. Барыбыз да иман белән туа. Аллаһы Тәгалә баланы хәтта бер ел буена төрле авыруларга каршы торырлык, көчле иммунитетлы итеп дөньяга тудыра. Балаларын башлап әниләре адаштыра. Ялгыш юлга кереп китсә, саташуын көт тә тор инде. Әниләре газиз, саф, иманлы баласын алдый. Дөнья белән танышканда бик күпләрнең беренче, авыр, фәлсәфи соравы: «Мине кайдан алдыгыз?!» Җаваплар еш кына гел бертөрле. Элегрәк әле табигать фасылларына бәйләп аңлаталар иде. «Сандугачлар китерде», «Чәчәкләр арасыннан таптым», «Бәкедән алдык, декабрь бит, чиләккә ияреп кайттың». 2-3 яшьтә бала бу сүзләргә ышана, ә инде 4-5 яшьтә ышанмый, алдыйсың, дип кәҗәләнә – әнисе алдаша бит.

Икенче берәүләр: «Аллаһ бирде, син безгә Аллаһ бүләге», – ди. Бала: «Кем ул Аллаһ?» – ди. Дөрес итеп җавап биреп кенә өлгер. «Аллаһ – дөнья хуҗасы», – ди әни. «Нәрсә ул дөнья?»» – ди бала. Менә шул чакта балага Аллаһ турында сөйлә дә сөйлә. Китаплар да, остазлар да җитәрлек, балаң белән үзең укы, үзең өйрән. Бер генә соравын да җавапсыз калдырма.

Әй сорыйбыз Аллаһыдан, әй ялварабыз, ялынабыз, әмма эш узган – бала юлдан язган, адашкан, саташкан... Йә Аллаһ, ярдәм ит, балам хараплар булды, нишлим, нишләргә, кая барып бәрелергә, кемнән ярдәм көтәргә? Балалар бозык, диләр. Юк, балалар бозык түгел, аналар бозык. Әгәр «Ихлас» мәчете хатын-кызларны, бигрәк тә яшьрәкләрне җыярга тырыша икән, максат бит, беренче чиратта, иманлы, Аллаһыны таныган ханымнарны чакыру. Дөньяда бала хәсрәтеннән дә ачырак хәсрәт юк. Ана йөрәге бәргәләнә, әрни, нишләр-гә, кая барып бәрелергә дә, кемнән ярдәм сорарга? Әй шалтыраталар Җәлил хәзрәткә, әй шалтыраталар: "Ярдәм ит, дога кыл, Аллаһыдан сора, булыш», – дип ялваралар.

– Иң кабул була торган дога – аналарның балаларына кыла торган, Аллаһыдан сорый, теләкләр тели торган догасы, – ди Җәлил хәзрәт. – Үзегез кылыгыз!

Ана. Бу аның иң авыр, иң хәсрәтле мизгеле, ул шапшәрә һәм ихлас: «Мин дога белмим», – ди. «Әниләр догасын кыл», – ди. «Нинди дога соң ул?»

Һәм Җәлил хәзрәт дога яза, әниләр догасын. Ул аның нинди икәнен үзе дә белми. Әни булганы юк бит аның. Ул бары тик догаларның бик зур көчкә ия булуын гына белә. Борын заманда бер сугышчы булган. Ул сугыш мәйданына бер дә әзерлексез, саклану чараларсыз чыга, ди. Әйтәләр, әйтәләр – ишетми. Ә беркөнне башына очлым киеп, калкан алып чыга. Иптәшләре: «Ник



■ Дога белән теле ачылган бала ата-анасына һәрвакыт хәерхаһлы, мәрхәмәтле, шәфкатьле була торгандыр. Догалар күп лә ул. Әнә бит, бик яшьли ятим калган Габдулла Тукай да: «И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам!» – дигән бит.

киендең?» – дип аптырыйлар. «Минем әни үлде, – ди ул. – Моңа кадәр мине әнинең догалары саклады. Инде догаларны әни өчен дә үзем кылам», – ди.

Никадәр генә арыган, алҗыган булсак та, «Ихлас» мәчетенең идәненә түшәлгән урын-җирләр йомшак булса да, йоклап китеп булмый. Бер абыстайны ишарә белән генә чакырып алам да, үзем белән алып килгән китаплар, календарьлар өеменә күрсәтәм:

– Әнә, зәңгәр төргәкне күрәсеңме, төргәк эчендә ал төргәк, Җәлил хәзрәт сезгә махсус күчтәнәч җибәрде, – дим. – Шуны тузды да, һәрберегезгә тарат, – дим. – Бердән артыкны бирмә, тарткалашсалар, туктат. Мин йоклыйм, иртән сөйләшербез, Аллаһ теләсә.

Җәлил хәзрәт: «Бала кечкенә чакта аңа Аллаһ турында сөйләмәсәң, бала үсеп җиткәч, аның турында Аллаһыга сөйлисе була».

Тарата башлаганны хәтерлим, йоклап киткәнемне юк. Шылт иткән тавышлары ишетелмәде. Төне буе дога ятлаганнар. Әниләр догасы, һәр очрак өчен унбиш дога. Ул аны махсус язды, һәм без аны, кая барсак та күчтәнәч итеп алып бара идек. Инде аны кем язганын берәү дә хәтерләми, Уфада йоклаган төнне дә ханым, абыстайлар төне буе дога ятладылар, әниләр догасын, үз догаларын. Доганы язып була аны... Ләкин бит хикмәт кирәк. Ә хикмәт бөтен кешегә дә бирелми ул.

Татарстан мөселманнарының 1998 елда булган Беренче корылтае тарихка Берләшү съезды булып кереп калды. Әллә ничә мөфтият, мөфтилеккә 15 ләп кандидат, шулар арасыннан бары берне сайлап алу тиеш иде. Иртәгә корылтай дигән көнне ул бездә кунды. Ирем Миншәех Харис улы белән төне буе йокламадылар, сөйләшеп чыктылар. Борчылганнардыр инде. Ә икенче көнне корылтай шулкадәр җиңел, матур, җайлы барды. Әйтерсең лә, кышкы юлдан җигүле ат бара, көн кояш-

PRESSA.RU

лы, салкын. Ә атлар җилдерә генә, чана аз гына да юлдан чыкмый, дилбегә – Җәлил хәзрәт кулында.

Бертавыштан Татарстан мөфтияте төзелде һәм аның беренче мөфтие сайланды. Корылтай тәмамлангач, Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев, мондый җыелышларны Мәскәү, Казаннарда күп күргән кеше буларак, Җәлил хәзрәткә соклануын белдерде, туп-туры бәреп: «Мондый осталыкка кайда өйрәндең?» «Ике ел эчендә 40 туй алып бардым, – диде дә хәзрәт, – хәмерсез, аракысыз», – дип тә өстәде.

Янәшәдән кемдер сүз кыстырды: «Аракысыз туй буламыни?» «Чакыр, күрсәтербез!» – диде хәзрәт.

Сорау биргән кеше аны ун елдан соң никах туена чакырды, кунакларның кәефе кырылыр дип курыккан хуҗа әй сөенде. Алардан бигрәк Җәлил хәзрәт сөенде. Әй сөйләп тә карады инде, сораулар бирә-бирә сөйләттеләр. Кайсы үзенең имансызлыгын таныды, кайсы хатынына мәһәр бирмәгәнен хәтерләде. Мәһәр бит никахның төп шартының берсе. Анысы, баш казый үзе дә хаҗда хатынын алтын кибетенә алып кереп, 25 ел гомер иткәч, мәһәрен тапшырды. Хәзрәтебез никах, мәҗлес, җыелыш, очрашуларны ярата. Ул анда терелеп китә. Болар барысы да безнең эш мәйданы, иген кыры ди. Орлыкны чәчкәч тә эш бетми, аны гел карап, сугарып, ашлап торырга кирәк. Бусы инде Җәлил хәзрәтнең һәр йортта булган китаплары, сөйләгән вәгазьләре, бик тә аралашып яшәргә тырышуы.

Җәлил хәзрәт белемне, гыйлемне бөртекләп җыйган галим ул. Аның Габделхак дигән хәзрәтләре, остазлары гына дүртәү иде. Ул алар турында матур, үтемле итеп сөйли, һәр иртәдә алар рухына «Йәсин» укып багышлый. Җәлил хәзрәтнең догалары, вәгазьләре турында гына түгел, җаена туры китереп әйтелгән тапкыр сүзләре турында да сөйләкләр телдән-телгә күчеп йөри.

Имеш, бервакыт берәү Җәлил хәзрәткә үпкәли: «Сез дә яңгыр боткасы үткәрдегез, без дә яңгыр боткасы үткәрдек. Сез дә яңгыр намазы укыдыгыз, без дә укыдык. Сездә уңыш котырып уңды, бездә булмады, – ди. – Безгә әйтми торган догаң бардыр синең», – ди. «Син Аллаһыдан нәрсә сорадың соң?» – ди баш казый. «Яңгыр инде». – «Без шул мул уңыш сорадык», – ди Җәлил хәзрәт.

Ул үзе җирне ярата. Бакчаларын, урманнарын, кырларын ярата. Мулла булып китсә дә, китмәсә дә, язмышын җир белән бәйләргә була. Авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. Аспирантурага кодалыйлар, шәһәрдә калдырмакчылар. Төп йортта гомер итәргә сүз бирә. Китәргә аны гомер буе кодалыйлар, гомере юлда, машиналарда уза. Йөртүчеләре арый, ул аларны алыштыра, ял иттерә, гел юлда. Юл вакытын да йоклап әрәм итми, телефоннан сөйләшә, һәр сөйләшү үзе бер вәгазь, һәр вәгазь үзе бер сабак.

Җәлил хәзрәтнең туган авылы безнекеннән бер дә зур түгел, кечерәктер дә әле. Мәктәпләре дә бер дигән, яңаны төзеделәр. Безнеке дә яңа, аларда унике бала беренчегә бара, бездә бер бала. Урта мәктәптә йөздән артык бала укый. Анысы инде директордан да тора. Безнең авылда читтән килгән, оештыруга сәләтсез директор. Җәлил хәзрәт күрше авылдагы авылдашын директорлыкка үзе чакырып кайтарды. Яңа мәктәп төзибез, әдәп-әхлак укытабыз, дип кызыктырып кодалады. Бурычлы, иске мәктәпкә Гүзәл Бариеваның кайтуы Җәлил хәзрәткә күктән төшкән бәхет булды. Бер җайдә нинди мәктәп төзеп куйдылар. Беркөнне Җәлил хәзрәт бездә, редакциядә утыра. Гүзәл: «40 мең акча кирәк, әгәр иртәгә кичкә кадәр бирмәсәм, мәктәпкә 200 мең штраф салалар», – ди, кычкырып еламый гына. «Ярар, булыр», – ди хәзрәт. Безгә: «Табып, биреп торырсыз», – ди. «Бирәбез, бирәбез», – дибез.

Икенче көнне кичке якта тирләп-пешеп Җәлил хәзрәт килеп керде. Гүзәл ханымга: «Акча булды, таң атканда Аллаһыга ялварган идем, ишетте, берәүләргә никахка барган идем», – ди.

Андый хәлләр гел булып тора. Бирим дигән колына чыгарып куя юлына, диләрме әле? Мәчетне ремонтлаганда да кызык хәл була. Мөфти хәзрәт: «Смета буенча мәчетеңә күпме акча кирәк, бухгалтериядә кул куеп ал», – ди. «Юк, – ди, – Аллаһ бирер әле». «Көтеп утыр инде», – дип көлделәр.

Өлкән хәзрәт Готыф абый вафат була. Оныгы зиратта хәер тарата. Җәлил хәзрәттән башлаган була, әйләнеп килә дә калган акчасын да аңа тоттыра: «Мәчеткә», – ди. Хәзрәтнең күңеле тула: «Готыф абый исән чагында да гел булышып тора идең, инде менә ул гүр иясе булгач та ярдәм итәсең, сәдакаи җария булып, мәңгелек йортыңны нурландырып торсын», – ди. Кайткач, кассир акчаны санап караса, нәкъ кирәкле сумма!

Соңгы арада хәзрәтебез Сабан туйлары үткәрү белән бик мавыгып китте, дип уйлый идем. Балалар Сабан туе да, ди ул аны, мөселман Сабан туе да. Кунакка чакыра баргач, бер түрә бөтенләй кәефен кырып кайтара. «Күптән туктаткан булыр идек тә ул Сабан туйларын. Сез булганга гына түзәбез», – ди. «Сез килегез, күрегез әле алдан, аннан әйтерсез», – ди хәзрәт.

Мондый гүзәл манзараны бары күреп, ләззәтләнеп, рухи азык алып, күңелеңне хушландырып була. Зифа буйлы, матур киенгән, һәр гаиләдә икешәр-өчәр бала, әйтерсең лә чәчәклектә күбәләкләр. Монда бер-берсенә елмаймыйча карамыйлар да. Кунаклар дип уйламагыз, боларның күбесе бу авылныкы. Кыска җиңле күлмәк кимиләр, чәчне-башны туздырмыйлар. Бу татар авылы, Самараның Галие, Мордовиянең Әлләзәне, Ульянның Кулаткысы гына түгел бу. Монда мөселманлык, монда ихласлык, монда иман, монда нур. Бу – татар-мөселман авылы, аларның бәйрәме. Җәлил хәзрәт бәйрәме. Алар бу бәйрәмгә чирек гасыр әзерләнделәр. Әдәп-әхлак

дәресләре һәм, барыннан да бигрәк, Җәлил хәзрәт дәресләрен өйрәнделәр.

Җәлил хәзрәткә белем җитми иде, ул белемен күтәрде, мәдрәсә тәмамлады. 3-4 көндә тулы программа белән имтихан тотты. Атна саен вәгазь сөйләде. Җәлил хәзрәт кунаклар ярата, дини, мөселман булса, бетте инде. Татар матбугатының иң талантлы, булдыклы, гадел, тырыш журналисты Шәех абый белән танышу Җәлил хәзрәткә зур бәхет булды. Шәех абый аңа караганда да бәхетлерәк иде. Ул Җәлил рухы белән яшәде. Бер корбан бәйрәмендә, хәтта бер көн алдан Җәлил хәзрәт Габделхак абый Каюмов, Миншәех абый Зәбиров, Рәшит Минһаҗны үзләренә алып китте. Ул чакта әле өйләр дә хәзерге кебек зур түгел иде. Өч көн кунак булып кайттылар. Шәех абый вәгазь кассеталарын күрә дә: «Боларны китап итеп чыгарырга кирәк иде», – ди. Хәзрәт исә: «Болардан китап ясау терлек абзарыннан Мәдәният сарае төзүгә тиң», – ди.

Бер елда сөйләгән 52 вәгазь «Җәлил хәзрәт вәгазьләре» дигән өч китап булып басылып чыкты. Һәм алар дөнья буйлап таралды. Миншәех Зәбировта бик күп журналистлар чыныгу алды. Шуларның иң булдыклысы Җәлил хәзрәт булды бугай. Ул аны кулына каләм алып, вәгазьләр язарга мәҗбүр итте. Язуы гына дулкынлы сызыкны хәтерләтә – шуны Шәех абый укый ала иде.

Җәлил хәзрәт белән Шәех абый еш очрашалар иде. Авырса да һәрвакыт янында булды, кунак булырга, бәлеш, сарык кабыргасы ашарга гына түгел, җиләк, гөмбә җыярга, мунча керергә дә өйрәтте. Шәех абыйга да, Җәлил хәзрәткә дә кызу мунча керергә ярамый, врачлар кушмый, ә болар берьюлы икешәр себерке белән чабыналар иде.

Шәех абый яшьлегендә коточкыч авырлыклар күрсә дә, Җәлил хәзрәт белән ул чиксез бәхетле булды. Дингә килде, намазга басты. Җәлил хәзрәт аны хаҗга алып барды. Шәех абыйның «Җәлил хәзрәт мәзәкләре» яки «Җәлил хәзрәт могҗизалары» дигән китап чыгарасы килә иде, ул аларны җыеп та барган иде. Әллә шуңа микән, Шәех абый Җәлил хәзрәт төшләренә ап-ак киемнән, нурланып, матурланып керә.

Яза-яза Җәлил хәзрәтнең җәмәгате Гөлфәния әллә кайда калды. Җәлил хәзрәтнең вәгазьләрен күчерә-күчерә үзе дә язучы булып беткән Гөлфәния бит инде ул. 33 ел балалар бакчасында эшләп, бик тә кирәкле китап язды ул. Балалар бакчалары өчен кулланма – «Әдәп орлыклары» дип атала. Һәр бакчада урысчасы, татарчасы булырга тиеш, дип беләм бу китапның. Хәзрәт хатыны нинди булырга тиеш дисәләр, иң башлап мин аны күрсәтер идем. Ачык йөз, киң күңел, хак хак-лый белү, ир хакы, кайнана-кайната һәм менә – киленнәр, кияү хакы. Аны үрнәк итеп куярга да, өйрәнергә дә өйрәнергә кирәк безгә.

Җәлил хәзрәт ул тәҗрибәне үз якыннары өстендә алып бара. Төпчек малай төп йортта яшәргә тиеш, дип вәгазь сөйли икән, аныкы бит шулай. Әллә Алмаз читкә китә, физик була алмас идеме? Яшьләрне авылда калдырырга кирәк, дип сөйли икән, аныкы да калды. Ике



улы да авылда яши. Яшьләрне күбрәк бәби алып кайтырга өнди икән, аныкылардан үрнәк алырга тиешләр. Сөйләүче күп лә ул, эшләп күрсәтергә кирәк. Ике килен дә берәр ул, берәр кыз алып кайттылар да, тукталыбрак калдылар кебек. Киленнәр кайниш туфрагыннан, куллары – корыч, телләре – борыч. Кечерәге хәзрәт кызы: «Мин килен булып төшкәндә этидән курка идем, ул иң яхшы эти икән», – ди. Ә бер кичтә аларда сөйләшеп утырабыз. Җәлил хәзрәт гел бер якка басым ясый, балалар күп булырга тиеш. Килен оста: «Әти, – ди, – сезнеке булса да, курыкмагыз, үзебез үстерешәбез», – ди. Телләләр, тапкырлар. Әле менә кайнаталары ярыш игълан итте: «Кем дә кем беренче булып өченче оныкны алып кайта, шуңа – чәшке тун», – ди.


Дөнья без уйлаганнан күпкә катлаулы, дуслар да, дошманнар да күп. Бата-чума йөзәбез.

Карап, күзәтеп торам да, болар барысы да артистлар кебек уйныйлар. Уйныйлар, ләкин чын итеп, ихластан. Җәлил хәзрәт ул зур бер нәселнең, бер авылның, җөмһүриятнең, бөтен татарның президенты кебек. Соңгы мөфти сайлаулар алдыннан Илбашыбыз үзенә чакыртып алды. Дустанә, хөрмәт белән: «Мөфти бул әле», – диде. Хәзрәт уйга калды, йөрәк тибеше бүлмәгә ишетелгәндәй булды. Каршы әйтү авыр иде.

«Булмыйм», – ди. Сөйләшүләр, аңлашырга тырышулар ике сәгать барды. Рөстәм Нургали улы: «Бергә эшлисе килгән иде», – диде. «Эшләрбез», – диде хәзрәт. Һәм тагын да тырышыбрак эшли башлады. Инде менә 25 елга якын баш казый вазыйфасын башкара икән, сөбханалла дияргә кирәктер. Вәгазьләр сөйләү, китаплар чыгару, никахлар уку – җан рәхәте.



Язманың тулы вариантын сайтыбызда укыгыз.









ҮЗ ЯГЫМЛА

ИЛ БУЕНЧА КЫЗЫКЛЫ МАРШРУТЛАРНЫ БАРЛАУ ХӘРӘКӘТЕ УЯНГАН БЕР ВАКЫТТА АВТОБУСЛАРГА УТЫРЫП ЮЛГА КУЗГАЛУДА ЯМЬ БАР.

Иделнең уңъяк ярындагы бу авылның тарихы кимендә ике йөз илле ел белән исәпләнә дисәләр дә, ул авылның бит әле, имеш, Екатерина Икенче шушы матур исемне кушканчы ук та Старое Зимовье дигән атамасы булган. Иске Кышлау, димәк. Кемнәр кышлаган анда? Безнең борынгы күчмән бабаларыбызмы, әллә Казанга яу чыгарга ниятләгән заманнарда шунда туктап ял иткән урыс яугирләреме? Анысын берәү дә белми торгандыр, чөнки белешмәлекләрдә ул хакта хәбәр юк. Әмма Красновидово чыннан да Идел кыясыннан гүзәл күренешләр, дәрья киңлекләре ачылып киткән «красный», ягъни «матур» урында. Мин үзем мәгърур кыяны күргә күңелемнән Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур» романындагы сәхифәләрне актардым. Кыя якасына басып кем тора ул – Койтымбикәме, әллә Ямгырчы би кызы Тамчымы?

Казан Милли музееның генераль директоры Гөлчәчәк ханым Нәҗипова, журналистлар белән очрашуга килгәч, Красновидово авылындагы Горький музее турында сөйләгәндә бу маршрут белән шактый нык кызыктырган иде. Юкка булмаган икән. Дөресрәге, журналистларны кузгатуы нәкъ вакытында! Красновидово туристларны, чыннан да, бәйрәм белән каршы алды – Алмалы спас! Быел алмалары ишелеп уңмаган икән үзе. Аның каруы, балны мул алганнар, слива агачлары җимештән сыгылып тора. Балык та ятьмәләргә керми тормый булыр. Бәләкәй генә булса да, ярминкә гөрли. Берничә урында муенына клиндерләр элеп куйган самоварлар кайнап тора. Бер читтәрәк казаннар да асылган. Анда уха пешә, ботка өлгергән. Әй, кем инде табигать хозурына чәй эчәр, тамак ялгар өчен генә килә! Күзгә кызык, җанга ризык кирәк безнең. Бу җәһәттән Казаннан ук килгән «Оберег» ансамбле кинәндерде. Әйлән-бәйлән (хоровод) җырларын дәртле биюләр алмаштырды. Гармунчы «Яблочко» биюен (Алмалы спаста ансыз була димени?) әйттерә башлауга бал сатучы агайлар дә түгәрәккә керде. Биеп аруга, янәдән күзләр самоварларны күзли башлады.

Инде Красновидовога килүнең төп максатын искә төшерергә вакыт. 1888 елның җәендә Алексей Пешков (Максим Горький) дусты Миша Ромась янында җан яраларын ялаштырып яткан. Егерме яшьлек бу таза егетне авыл кешеләре бик озак оныта алмаганнар, имеш. Беренчедән, алар аның, яңгырлардан качып, көймә астында китап укып ятканын кызык санаганнар. Аңа Көймә асты

Лешка дигән кушамат та такканнар. Икенчедән, ул китаплардан укып белгәннәренә студент дусларыннан ишеткәннәрен кушып сөйләп, крестьяннарның «күзен ачкан». «Күзләре ачылган» гади халык бер төнне Ромасьның лавкасына ут төрткән. Хәзер чын дөресен кем белә инде аның дияр идек тә бит. Бу хакта Максим Горький үзе «Минем университетларым» дигән бәянында язып калдырган.

Халык бәйрәме белән халык хәтере кушылган урынга туристлар сукмагы салу, һичшиксез, изге бурыч. Бу сукмакның пунктирлары байтактан карталарга төшерелгән икән инде. 1979 елда ук ачылган Масим Горький музеенда 500 меңнән артык турист булып китәргә өлгергән. «Булып китү» ул бөек пролетар язучының биографиясе, иҗат юлы белән генә танышу да түгел әле. Мондагы крайны өйрәнүгә мөнәсәбәтле экспонатлар, XIX гасырда хөкем сөргән күренешне чын булганынча күреп китү күп йөргән кешеләр өчен дә бик кызыклы. Әле кайчан гына һәр торак йортның патшасы булган зур морҗа, аның сәндерәсе хәтта XX гасыр кешеләрендә дә ностальгия хисен уята.

Бу экспонатларны беренче космонавт Юрий Гагарин да карап йөргән икән бит әле. Шушы музей тирәсендә рус халкының фольклор традицияләрен яңарту да кыйммәтле. Йола бәйрәмнәре кешеләрнең уйларын яктырта. Әле без дә бит юл буе алма сортларын санап килдек. Аңа әдипләр иҗатындагы алмага бәйле сюжетлар ялганды. Хәзер 19 августны ел саен Красновидовога сәфәр көне итәргә дип торабыз.

Гомумән, соңгы елларда ТР Милли музее һәм аның филиаллары Татарстанда яшәүче төрле милләт халыкларының тарихы, әдәбияты белән кызыксынган һәммә кешегә кызыклы, мавыктыргыч маршрутлар әзерләгән. Мәсәлән, Г. Тукай әдәби музее бөек шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган «Шагыйрь бишеге» экскурсион маршруты тәкъдим итә. Сәяхәт Г. Тукай әдәби музеенда һәм шагыйрь бишеге булган Арча, Әтнә яклары аша уза. Нәни Тукай яланаяк чабып йөргән болыннарны, «шатлык белән уйнап гомер сөргән» урамнарны, «сука белән ертып-ертып йөргән» кара җирләрне күрү, Су анасы чәчен тараган инешләр белән хозурлану көтә монда. Габдулла җылылык, наз эзләп узган юллардан үтү исә күңелдә ирексездән аның шигырь юлларын яңарта:

Бу сәбәптән аңладым мин,
и туган җирем, синең
Җанга ягымлы икәндер
ялкының да дулкының!
Җөмләтәдән изге икән ич,
инешең, чишмәң, кырың,
Юлларың, авыл, әвен,
кибәннәрең дә ындырың.

Г. Тукай әдәби музеенда шагыйребезнең кул җылысы тигән җиң каптырмаларын, түбәтәен, кара савытын, кәрәч тартмасын, сәяхәтләренең юлдашы булган юл кәрзинен күреп кем рухланмас?! Кушлавычта Тукаевлар музей-йортында әнисе Бибимәмдүдәнең шәхси әйберләре кемне уйга салмас?! Кырлайдагы Бакый Урманче проекты белән төзелгән Г. Тукай әдәби-мемориаль комплексы кемне генә сокландырмас икән?!

Кукмара муниципаль районына оештырылган «Халкымның алтын куллары: Кукмара төбәге халык һөнәрләре» сәнәгать туры исә татар милләтенең рухи байлыгы, һөнәри осталыгы белән сокландыра. Бай тарихы булган Кукмара борынгыдан терлекчелектән, игенчелектән тыш, һөнәрчеләре белән танылган. Кукмара туган як музее, Кукмара металл савыт-саба заводы, Тегү фабрикасы һәм Киез-итек комбинаты экскурсия кунакларын көнкүреш әйберләре ясау, күн эшкәртү, мехтан киемнәр тегү, шәл бәйләү, итек басу һөнәрләре белән таныштыра. Музей экспозициясендә урын алган борынгы бакыр комганнар, XIX чор киез итекләре, чигелгән сөлгеләр, намазлыклар үзенең тамашачысына татар халкының борынгы кәсепләрен бәян итә.

Һөнәрчеләргә бай Кукмара ягыннан, Тукайны тудырган җырлы, моңлы Казан артыннан алмалары кызарып пешеп утырган Красновидовога әйләнеп кайтыйк, дөресрәге, М. Горький музеена оештырылган сәяхәтне дәвам итик.

Шушы сәфәр аркылы Кама Тамагы төбәгендә туып-үскән татар әдипләренә дә игътибар көчәергә тора. Драматург Туфан Миңнуллин сукмагы да һаман киңәя бара. Олы әдип Ибраһ Гази исеме дә ешрак телгә алына башлады. Музей директоры Ольга Николаевна Гришакова монда яңа музей бинасы салыныр, тирә-юнь тагын да матурланыр дип өметләнеп тора. Татарстан Милли музееның генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова бу өметләрнең нигезе бар дип саный. Шәп бина корып кую, бер түбә астында әдәбиятта эз калдырган шәхесләргә дә урын бирү чынга ашмас хыял түгел ул, дип саный.

Татарстаныбызның һәр районында туристларга күрсәтерлек мирасыбыз бар безнең.

Элек булган, хәзер юкка чыккан дебаркадерны кабат кайтарганнан соң, Идел буйлап менеп-төшеп йөри торган сәяхәт суднолары монда тукталыш ясый башлар иде. Россия хөкүмәтендә дә елга пароходчылыгын үстерү, бу эшкә 13 миллиард сум акча табу турында сөйләшәләр. Димәк, барысы да уңайга бара кебек. Ил буенча яңа туристик маршрутлар эзләгән бер вакытта инде табылганын пропагандалау зарур дип уйлыйм. Мәктәпләрнең өлкән сыйныф укучылары «Давыл кошы» кебек горур да, романтик та әсәрне ятлап, дәрестә «бишле»ләрен алганнан соң, Красновидовога килеп, Давыл хәбәрчесенең үзе белән бәйле урынны күреп китәргә, һичшиксез, теләрләр иде.

Асия ЮНЫСОВА

Сәяхәтләргә заказны Милли музейның үзендә дә, Галактионов урамындагы Максим Горький музее аша да ясап була. Белешмәләр алу өчен музей белән түбәндәге телефон аша элемтәгә керергә мөмкин: 292-32-18.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

PRESSA.RU



Флера Гыйззәтуллина шигырьләре гади, тормышчан, халыкчан булуы белән җәлеп итә. Ятимлекне, сугыш елларын кичергән, Кемерово, Донбасс шахталарында эшләгән, тегү теккән, балалар үстергән, иҗат иткән хатын-кызның күңел кыллары поэмаларында, шигырьләрендә чыңлый. Шагыйрә җанына туган ил кайгысы моң булып урнашкан. Ул ил гаме белән яши. Иҗатында Ил, Ана образлары янәшә. Аның үз теле, үз стиле, үз бормалары, үз җыры. Флера апаны гомер бәйрәме белән котлыйбыз! Үзенчәлекле иҗаты белән укучыларын сөендереп яшәсен!

Флера
ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА

ГОМЕРНЕҢ ТӘҢКӘЛЕ ТОЛЫМЫ

Ара ерак...

Гомер талларымда – Язгы бөре!
Шигъри Ярларымда – Якты ташкын!
Тал-бөреле шигъриятем аша
Мин тормышның яктылыгын ачтым.

Күкләр биек, зәңгәр күкләр биек,
Хыял көймәсендә йөзәр өчен.
Туган якның хәтер кашагасын
Энҗе-мәрҗән белән бизәр өчен.

Ара ерак... Бик тә ерак инде...
Кайту көнен көтеп тәкать корый.
Үтә гомер, газиз туган якка
Бәрәкәтле тормыш юрый-юрый.

* * *

Җир тирәли йөреп кояш яна
Бездән алып яну чамасын.
Җирне кочып алыр колачым бар,
Күк киңлеген иңләр карашым.

Җирдән күккә,
күктән җиргә кадәр
Бик күп әле юллар ярасым.
Баштан алып азагына хәтле
Гомеремнең беләм чамасын.

Ак кәгазьгә язар хак сүзләрем
Күптән инде уйда өлгергән.
Башак чайкый бодай басуларым,
Арыш кырым туңга сөрелгән.
Баш түбәмдә балкып кояш яна.
Баш түбәмдә – антым – ирегем.
Бер йөгерим ызан-кырлар буйлап
Күзләре мул туган җиремнең!

Кадерлем, чамала!

Сөю – ул күңелнең
Былбыллы тирәге, –
Яшәрә йөрәкләр сагында.
Без дә бит йөрәктән
Былбыллар очыртып
Серләштек тирәкләр шавында.

Сөю – ул гомернең
Тәңкәле толымы, –
Сагышка чылдырап камала...
Кадерлем, чамала! –
Толымнар чалара,
Гомерләр минутлап санала.

Сөю – ул өметнең
Кояшлы кыйбласы?
Юл анда җыр аша ачыла.
Кояш та иртәрәк
Баерга ашыга
Моң төшсә кайгылы башына...

Игенче өчен...

...Басуда башаклар саргайтып,
Салмаклап сары җил агыла.
Уйнап көч сынашкан сабыйдай
Башаклар башакка сарыла.
Игенче шатлана: «Балама
Көч кергән!.. –
...Басуга төс кергән!..»
Игенче өчен бу мул уңыш –
Бала күк кадерләп үстергән.

Зөһрәгөл!..

Су буйлап ай йөзә...
Шул айга Зөһрәгөл
Сулардан кайтышлый калыккан.
Ай кызы да туа,
Су кызы да туа,
Җир кызы да туа халыктан.

Зөһрәнең иңендә
Пар чиләк тирбәлә:
Юк, ахры, су ташып бушары.
Суларым чайпалып
Бетмәсен! – дигәндәй,
Сак кына әйләнә Җир шары.

Сак кына, Сок кына
Ярларга кагыла.
Су юлы, тымызык ай юлы!..
...Йортка су ташучы
Кызлардан башлана
Дөньяның исәнлек-саулыгы.

Шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин бар булмышы белән авыл баласы. Шуңа күрә аның язганнарыннан, юкәләрдән бал тамган кебек, хис тамып тора. Аның ул хисләре садә, ихлас кына түгел, бәлки, чын халыкчан да. Гәрчә белеме буенча физик булса да, ул шигырьләрен башваткыч формулалар рәвешенә китереп язмый. Чөнки ул гадилекнең бөеклеген аңлый белә торган игенче, җир кешесе. Әмма ул Җиргә, күктә йөзгән болытларга, урманда үскән агачларга, игеннәргә теләктәш, фикердәш, хистәш итеп караучы олы шагыйрь! Аның моннан ике дистә ел элек язган «Керим әле урманнарга» дигән җырын халыкның шатлыкта да, моңлы чагында да үзеннән бер дә калдырмавы шагыйрьнең бай иҗатына чын бәя бит инде.
Олпат юбилее белән тәбрик итәбез аны.



Гарифҗан
МӨХӘММӘТШИН

АҖАГАННАР БАЛКЫШЫ

* * *

Җырлый-җырлый урак ура әнкәй,
Көлтә бәйли, куя сослымга,
Карап торсаң, һәрбер хәрәкәте
Гади түгел аның, тылсым ла!

Иген кыры аның каршысына
Үзе килә кебек иелеп...
Әнкәй кулы тигән һәр урында
Көлтә-көлтә кала игелек.

* * *

Мичтә чатнап чыбык, артыш яна,
Өйгә рәхәт җылы тарала,
Мич алдында әнкәй моңсу гына
Сый әзерли безгә табада.

Шул хатирә һаман истә минем,
Юкса хәтер күпне оныткан.
Ул елларда безне утлар түгел,
Әнкәйләрнең күңеле җылыткан.

* * *

Табынмый яшәми кеше –
Һәркемнең кәгъбәсе бар,
Кем беләндер бүлешергә
Саклаган алмасы бар.

Үз бәхетен таба кеше
Иманын тапламаса,
Шул алманы ятлар белән
Вакытсыз вакламаса.

* * *

Былбыл кебек зәңгәр күккә
Омтылган чагым була,
Ялгыз өянкеләр сыман,
Онытылган чагым була.

Омтылганда канатым син,
Онытылганда моңым син,
Гомергә күңелем күгендә
Талпыныр былбылым син.

* * *

Төнге аяз күккә карыйм
Сердәш эзләп җаныма,
Минут саен берәм-берәм
Яңа йолдыз кабына.

Кабына да җиргә бага –
Эзли үз сагынганын...
Һәрбер йолдыз үзе белә
Кем өчен кабынганын!

* * *

Синең күзләр һаман зәңгәр әле –
Зәңгәрлеген берүк җуймасын,
Минем күзләр күзләреңә карап,
Шул күзләрне күреп туймасын.

Җете бу зәңгәрлек күккә ашкан
Синең керфекләрең арасыннан,
Үсмер чакның керсез хыяллары
Чагыла күк синең карашыңнан.

* * *

Сокланып күзәтеп кенә
Аҗаганнар балкышын,
Тургайларның җырын тыңлап
Басу иңләп кайтышым.

Офыкта уйный аҗаган,
Серкә очыра арыш –
Табигатьнең туйда чагы,
Комачау итмим ялгыш!

* * *

Син минем өзмәгән алмам,
Чәчәк атмаган гөлем,
Алсу алмам, ал гөлем, дип
Мең кат кабатлый телем.

Яумаган ләйсән яңгырым,
Чыгып килгән кояшым,
Кояшлы яңгырда килә
Йөрәгемне юасым.

* * *

Араларда хатлар йөрми инде,
Чоры үтте бүген хатларның,
Ерак калган яшьлек хатирәсе –
Синең хатларыңны актардым.

Әллә нәрсә булды йөрәгемә –
Шул хатлардан күңел нечкәргән,
Еллар үткән, хатлар суынмаган
Яшьлектәге кайнар хисләрдән...

PRESSA.RU

Сәмига СӘҮБАНОВА – Актаныш якларыннан. Югары Яхшый авылында туган. Байсар урта мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Хискә, юморга бай каләме белән студент елларында ук таныла башлый. Алган белеме, туплаган тормыш тәҗрибәсе бөтерчек кебек кызга матур хикәяләр язарга канат куя. Балалар бакчасында – тәрбияче, мәктәптә – укытучы, район газеталарында – тәрҗемәче һәм әдәби хезмәткәр... Сәмига китапханәдә дә, заводта да, «Казан утлары» журналы редакциясендә дә, мәдәният министрлыгы каршындагы фәнни-методик үзәктә дә эшли. Һәм ул еллар иҗатына кызыклы сюжетлары, яңа геройлары белән кереп кала.



Сәмига СӘҮБАНОВА

СОҢАРЫП ЧЫККАН КОЯШ

(Хикәя)

Равилнең өе эшеннән ерак иде. Кирәк дигәндә транспорты да тиз генә булмый бит аның. Таш яуса да, эшкә соңга калырга ярамый, радиотапшырулар сәгате-минуты белән башлана.

Дус булган җирдә дошман да бар, диләр: бәйләнердәй сәбәп эзләп йөрүчеләре дә бар шул. Хәер, Рәшит аңа нинди дошман булсын? Ул – авылдашы, Сәриянең җизнәсе. Якташлар...

– Мин сине үз энем кебек күрәм, – дип, салпы ягына салам кыстырып, еш кына аны өенә кунакка чакырып, акыллы киңәшләрен бирә торган иде. – Татарның акылы төштән соң, диләрме әле? Яшь чагында кайнар буласың. Сөйгәнең белән куышта да оҗмах диган мәкаль безнең заман өчен түгел. Яшьлегемдә андый ялгышым булды... Әти-әни, туганнар сүзе колакка да кермәде, барыбер өйләнмәкче булдым. Чибәр иде. Усал. Үзсүзле... Мин дә төшеп калганнардан түгел. Дөрес, кырт кисеп каршы да килмәделәр. Укып бетергәнне көтәргә куштылар. Тик көтәр чамабыз юк иде. Әти-әниләргә үч итеп, урманга качып чатыр кордык. Җәннәтнең үзе инде менә! Бер-ике сәгатьтән күз ачыла башлады... Кая анда бүтән калу! Шуңа күрә мин дәртләренә чыдый алмаган яшьләргә бераз куышта торырга киңәш бирер идем. Аңардан да нәтиҗәле үгет-нәсыйхәт юк инде, һе-һе!

– Ул Камилә апа идеме? – дип сорады Равил.

– Юк! Камилә апаң белән без соңыннан очраштык. Дөресен әйткәндә, теге чатыр минем өчен зур сабак булды. Бу юлы инде йөрәкне түгел, акылны эшкә җиктем. Әгәр дә аңа өйләнмәсәм, радиотапшырулары директоры түгел, мәктәп директорыннан ары күтәрелә алмас идем. Куышта түгел, сарайда яшәргә тырышырга кирәк.

Әкренләп сүз Камиләнең сеңлесе Сәриягә күчә. Сүз дә юк, Сәрия чибәр. Әйе, ул үҗәт, таяныр кешеләре дә бар. Әти-әнисе фатир ачкычын туй көнне үк кулларына тоттырачак.

– Әйе, әйе, – дип, Равил алар белән килешә. «Кеше кешегә дус һәм туган», диган сүзгә чын-чынлап ышана.

Сәрия белән кичкә кадәр бәхәсләшеп утырулар да табигый кебек иде. Шулай утыра-утыра соңгарак калган чакларда, Камилә:

– Иртүк торасың бар, кунып кына кал, – дигәндә дә шикләнмәде. Шулай да кунарга яхшысынмады.

Бер килүендә өстәл янында озаграк утырдылар. Равилгә дөнья яктысы сүрелгән кебек көннәр иде. Кыстый-кыстый төрле эчемлекләр белән сыйладылар. Беренче чәркә әле яңа гына мәрхүм булган җырчы Чәчкә, икенче чәркә – хуҗабикә, өченче чәркә – Сәрия, дүртенчесе үзе өчен эчелде.

Кайтырга талпынды, урыныннан кузгала алмады. Рәшит аны теге киң караватка илтеп яткырды, анадан тума чишендерде һәм Сәриягә:

– Бу егетне көйләп торырга эшләрем муеннан! Әллә күзе сукыр, әллә башы томана – янында шундый кыз бөтерелеп йөргәнне күрмәмешкә салыша. Без аның күзен момент ачарбыз. Озакка китте аны бушка ашату, янына менеп ят, – диде.

Җизнәсенә бервакытта да каршы төшми торган Сәрия кып-кызыл булды:

– Юк, җизни. Мин оялам, – диде.

– Кемнән? Шушы мәми авызданмы?

– Минем алай кияүгә чыгасым килми. Иртәгә күзенә ничек күренермен? Мәҗбүри ярәттырып булмый.

Сәрия бер киреләнсә, сүзеннән кайтмаячагын Камилә белә иде.

– Рәшит, уеннан уймак чыгармыйк, – диде ул. – Ирексезләмә кыз баланы...

Рәшит бер минутка башын кашып уйланып торды һәм Камиләгә эндәште:

– Алайса син ят!

– Син нәрсә?

– Ахмак! Ул хәзер иртәнгә хәтле үлгән кебек йоклаячак бит! Аңа син ни, сеңлең ни, утын пүләне ни – барыбер! Тик ул янында хатын-кыз ятканын сизсен. Анысын сизәр... Курыкма, артыгын мин не позволю!

...Равил төне буе җеннәр белән саташып чыкты. Кемдер аны кочагындагы Чәчкәдән аерырга теләп читкә этә, нindидер хатын-кыз иде бугай... Ул, Чәчкәсеннән аерылмаска тырышып, аңардан читкәрәк тайпыла, тайпыла торгач, каршындагы биек дивар янына килеп җитә, аны тишеп чыгардай булып, җанфәрманга маңгае белән төя.

Ул, куркып, урыныннан сикереп торды. Үтереп башы сызлый. Кайда соң әле ул? Кирәк бит, гомер булмаганны, артыграк эчелгән. Нишләп шәп-шәрә әле ул? Ә сәгать алты да тулган, узып та киткән. Баш авыртуы, кул белән югандай, юкка чыкты.

Рәшит кухняда иде.

– Йокла, йокла, – диде ул.

– Тапшыру... соңга кал...дым, – диде Равил тотлыгып.

– Җир җимерелмәгән. Тапшыруны төгәлләделәр инде. Гөлсинә үзе генә ерып чыкты анда. Баҗайлар бит без хәзер, һе-һе-һе...

– Баҗайлар?

– Баҗайлар булмыйча?! Нәрсә, миндәр кочаклап йокладым, димәкче буласыңмы әллә? Ну кызның шәбен эләктердең!

Башына таш белән ордыларммыни? Кичтән берни дә булмавын яхшы хәтерли. Дөрес, күбрәк эчелде. Дөрес, куна калды. Дөрес, төнлә нindидер хатын-кыз этә-төртә куенына керергә тырышты. Тик ул моны саташу гына дип уйлаган иде. Димәк... Юк, ул ярамаган эш эшләмәгәнен яхшы хәтерли! Онытмас иде ул аны!

Күрәләтә бу ялганга ышанмыйча, ул Рәшиткә күтәрелеп карады. Тик ул шаяртмый иде. Базарда сыер саткан кебек, балдызын мактый, мәһәрен дә мулдан вәгъдә итә иде:

– Әби белән бабай фатир ачкычы тоттырса, миннән машина булыр!

Өйләнә алмый иде Равил! Дөрес, Сәриягә тел тидерерлек түгел, тик Чәчкәсе үлде бит, өйләнү кайгысымыни анда?

– Йокламадым мин Сәрия белән!

– Ә мин әйтәм – йокладың!

– Йокламадым!

– Ярар, хуш, йокламадың, ди. Шаһитларың бармы? Менә без Камилә белән шаһитлар! Балдыз да әйтер.

– Сәрия, дөресме?

Сәрия, оялып, күзләрен аска төшерде.

– Бергә йокладык бит, Равил, – диде ул.

Равил үз колакларына үзе ышанмады.

– Сәрия, ничек телең күтәрелә? – диде ул.

– Яраткач... күтәрелә инде.

Сәриягә карата булган дусларча ярату хисе шунда ук юкка чыкты.

– Юк, мин алай итеп өйләнә алмыйм! Төрмәгә киткәнем артык!

Рәшит көлемсерәде.

– Һе-һе-һе... Хәзер генә шулай дисең аны, баҗай... Ятьмәгә эләккәч, балык чәбәләнә бит әле... Сиңа да бу ятьмәдән исән-имин чыгу юк. Ятьмә затлы бит...

Ул атыла-бәрелә Гөлсинә янына чапты.

– Минем башны ашадылар, – диде ул. – Беттем...

Равилне тыңлагач, Гөлсинә дә уйчанланды.

– Төрмәгә үк утыртмас утыртуын... Балдызына кара тап төшерүдән шикләнер. Тик сиңа радио белән хушлашырга туры килмәгәе.

Шулай булып чыкты да.

Рәшитне дә эшендә озак куандырмадылар. Аны да очырдылар... Икенче көнне үк Равилне кире чакыра килделәр. Тик ул радиога бүтән әйләнеп кайтмады.

Хәзер төшенә тапшыруга соңга калганы гына түгел, шушы вакыйга да еш керә, шабыр тиргә батып уяна.

Бүген дә шулай булды.

– Казан сөйли, – дигән тавыш ишетелде.

Гөлсинә... Ул һаман да иртәнге тапшыруларны алып бара. Татарстан халкын йокыдан уята. Республика яңалыкларын халыкка ирештерүдән тәм таба. Бүтәннәргә сизелмидер дә, Равилне алдый алмассың. Бергә туры килгән ике тартыкның берсен йотып җибәрә. Әнә бит, «җанны» сүзе «җаны»га әйләнде. «Тырышма ул хәтле, Гөлсинә», – дип кулын тотып, тынычландырасы килде. Элеккеге гадәт... Хәбәрләрдән соң концерт башланды. Чәчкәне җырлаталар иде.

PRESSA.RU

Чәчкә... Инде бу фани дөньядан китүенә дә ни гомер. Үзе мәңгегә китсә китте, тавышы яши. Моңы, җыры аны элеккедән дә ныграк дулкынландыра.

Инде аның һәр сүзе, һәр аһәңе күңелгә яттан уелып калган. Аның дулкынлануы Гөлсинәгә дә күчте, ахры. Тартык авазларны гадәттәгедән ешрак йотуын дәвам итте. Яңгыраячак җырны игълан иткәндә «җырлый» сүзе «җылый» кебегрәк ишетелде. Җырчы җылый...

– Җыламый, җырлый, – дип төзәтте ул. Элеккечә, янәшә утыргандагы кебек, кулына кагыласы килде. – Җылый белми иде ул. Артык горур иде.

Үзе исән чагында да җырчы турындагы тапшыруларны алып барганда хәрефләрне йота иде Гөлсинә.

Равил аның студиягә яңа гына килгән чагын хәтерли. Оялып, кыяр-кыймас кына керсә дә, күзләрендәге тәвәккәллектән бу оялчанлыкның вакытлыча гына икәне сизелә иде. Укытучылары драма артисткасы итеп күрәселәре килсә дә, дикторлык һөнәренә тешетырнагы белән ябышты.

– Син бит тумышыңнан драма артисткасы, нигә ул микрофонга ябышып ятарга? – дигән иде Равил дә.

– Мин бик театрда эшләр идем дә, анда син юк шул, – дип сүзне уенга борды Гөлсинә.

Равил исә диктор да булмаган булыр иде. Әнисе үзенең бердәнбер улын табиб итеп күрәсе килә, алар беркайчан да югалып калмый, дияргә ярата иде. Чөнки ул үзе табибә. Равил дә табиб булырга дип әнисе белән сүз берләшеп куйган иде... Чыгарылыш кичәсенә кайчандыр шушы мәктәпне тәмамлаган танылган җырчы Чәчкәне чакырырга кемнең уена килгәндер? Бәлки, үзе болай гына туган авылына кайткандыр. Ул яшьләр алдында рәхәтләнеп җырлады. Мәктәп коллективына рәхмәт әйтеп, укучылар исеменнән Равил чыгыш ясады. Каушады, дулкынланды. Дулкынланырсың да, сәхнә йолдызы Чәчкә үзе килгән бит!

Чәчкә! Җырларын радио аша ничәмә тапкырлар ишетте! Моңы, үзәкләрне өзеп, әллә кайларга алып китә... Мондый моң иясе гүзәл алиһә булырга тиешлегенә ул һич шикләнми иде. Үзен күргәч, хыялдагы сурәт тоныкланды. Җырчы күпкә гүзәлрәк иде. Караган саен карыйсы, тыңлаган саен тыңлыйсы килде.

Концерттан соң әзерләнгән табында урыннары бергә туры килгәч, Равил Чәчкәнең нәрсә сөйләгәнен дә аңламады. Моң иясенең үзенә атап сөйләвен генә төшенде ул. Бу аны тагын да исертте, башы әйләнде...

Тукта әле, нишләп болай җебеп төште соң ул? Үзе дә төшеп калган егетләрдән түгел ләбаса. Равилгә кыюлык иңде, гәүдәсен киеребрәк куйды, болытлар өстеннән төшеп, бу дөньяга кайтты. Чәчкә аңа язмышын борып җибәрердәй сүзләр сөйли иде:

– ...Синең тавышың сәхнә өчен генә яратылган. Бәлки, син җырлыйсыңдыр? Менә дигән җырчыдыр әле син?

– Мин җырларга түгел, тыңларга гына яратам, – диде башы әйләнгән егет.

Равил ул көнне эчмичә исерде. Һәм бу кичә аның тормышын тамырдан үзгәртте.

Табиб булырга киткән җиреннән сәнгать академиясенә укырга кергәнен белгәч, әнисениләр уйлагандыр, Равил өчен сер булып калды, ә менә Гөлсинә уен яшереп тормады.

– Минем әти, ир-ат авыз күтәреп җырлап, адәм көлдереп акча эшләргә тиеш түгел, дип, бик шәп җырласа да, абыйны артистлыкка укытмады. Хәзер абый шуның өчен рәхмәт әйтеп бетерә алмый. Юкса аның тавышы янында Чәчкә апаныкы чикерткә чәрелдәгән шикелле генә булып кала. Чын ир ул ир-ат эше эшләргә тиеш.

– Ир-ат эше нәрсә соң ул? – диде Равил.

Бу сорауга Гөлсинә ачык җавап бирә алмады. Гөлсинәгә уку авыр бирелде. Шуңа күрә ул, вузга керә алмаудан куркып, медицина училищесын сайлады.

Әмма әлеге кичә Равилнең генә түгел, аның да тормышын үзгәрткән булып чыкты. Башта ул моны аңламаган иде әле. Кечкенәдән бергә уйнап үскән, аннан соң бер мәктәптә, бер парта артында утырып укыган Равилдән һәм сыйныфташларыннан аерылуына ул юкка сөенгән икән. Сагындыра, әй, сагындыра икән бергә булган чаклар!

Ул әле Равилне яратуын аңламый да иде. Таныш булмаган үзәк өзгеч моң җанын телеп үткәч, ул Равил белән очрашу җаен эзләргә тотынды.

Кыз сәнгатьне яратса да, үзен сәнгатькә багышларга һич тә уйламаган иде әле. Сирәк-мирәк очрашулар аңа җитми, ә Равил аңардан башка да бик шәп яшәп ята иде. Танылган артистка аны канат астына алсын да, яшәмә, имеш!

Кыз Равилгә кияүгә чыгу турында уена да кертми иде, ул аның якын дусты, бары шул гына Сыйныфташы. Ә ярату? Ярату ул кешене бер утка, бер суга сала. Яндырып та бетерми, батырмый да. Ярату – аның өчен әлегә ирешеп булмый торган зиннәт. Аңа хәзер укырга, тормышта үз юлын табарга кирәк.

Акылы белән шулай уйласа да, Равилне һич башыннан чыгара алмады. Юк, ул аның өчен утка керергә дә, суга төшәргә дә уйламады. Дус егетләре дә җитәрлек. Тик менә Равил белән очрашу, аны күрү, аның белән сөйләшү, хәтта әрепләшеп алу да аның көндәлек ихтыяҗына әйләнде.

Ә Равил, студент кына булуына карамастан, радиотапшырулар алып бара башлады. Тиз арада тавышын яратып та өлгерделәр, дөрес булса, яшь кызлардан күп кенә мәхәббәт хатлары да килә, диләр. Гөлсинәне уйларга вакыты да юк, баштанаяк укуга, эшкә чумган зур кеше булган Равил.

Их, бу гөлдерек тавышны ничек чарларга? Ул да Равил кебек диктор булыр иде, анда хатын-кыз диктор кирәк, диләр. Әллә бәхетне сынап карарга инде?

Равилне очратырга теләп, Горький урамында йөри торгач, радиокомитетка керергә батырчылык итте.

Постта торучы милиционер аны бик игътибар белән тыңлады, документын карады һәм, кем беләндер телефоннан сөйләшкәч кенә, тиешле бүлмәгә кертеп җибәрде.



Рәсем: Наталья Васильева

Кызны сөйләштерделәр, текст укыттылар, тавышын яздырып карадылар. Танылган кешеләрнең үзенә игътибары Гөлсинәгә батырлык өстәде. «Юк, синнән диктор чыкмый, сеңлем», – дип берсе дә әйтмәде.

– Сеңлем, сине коеп куйган диктор дип әйтеп булмый әле, шулай да тавышың бар. Аны шомартырга кирәк. Моның өчен сәхнә серләрен белү мәҗбүри. Сиңа укырга кирәк, – диделәр.

– Ә Равил? Ул да студент кына бит, – диде Гөлсинә.

– Әйтәм, бу арада диктор булырга теләүче кызлар күбәеп китте, – дип көлде Гөлсинәне тыңлаучыларның берсе. – Аның бәхет капкасы иртәрәк ачылды...

Бәхет капкасы... Гөлсинә дә шәфкать туташы булырга укырга кергәч, бәхет капкасы ачылган кебек булган иде. Их, Равил дә, әнисе кебек, табиб булса икән! Гөлсинә аның артыннан да калмас иде.

– Сеңлем, укый торган җирең бик әйбәт, бик кирәкле һөнәр иясе булырсың, – диде сөйләшүләргә катнашмый гына читтәрәк торган бер хатын-кыз. Гөлсинә аны тавышыннан таныды: Равил белән бергә тапшырулар алып баручы Кәүсәр Ялалова.

– Сез чынлап та миндә тавыш бар дип уйлыйсызмыни? – диде ул гаять дәрәҗәдә аптырап.

– Бар һәм ничек кенә әле!

Тик Гөлсинәнең башлаган эшен ташларга ниятендә юк иде. Ул медучилищеда укуын ташламады. Хастаханәгә урнашканнан соң гына сәнгать академиясенә укырга керде. Вакыт-вакыт аны да радиотапшыруларда катнаштыра башладылар.

Равил аның диктор булырга әзерләнүенә гаҗәпләнмәде. Үзенең дә хезмәт юлы бөтенләй бүтән якка үзгәреп китте бит. Тик ул Гөлсинә кебек үзен бернигә бүлә алмый. Ул бары тик бер генә эшне җиренә җиткереп башкара ала, бүтән эшкә тотына алмый.

Мәхәббәттә дә шулай. Ул бары тик бер генә кешене яратты. Чәчкәне! Бу ятатуның ахыры кавышу белән бетмәсен дә аңлый иде. Аңламыйча! Дөрес, соңгы вакытта ире белән аралары әйбәт түгел икән, дигән имеш-мимешләр дә колагына чагыла иде. Арада тирән упкын. Ул упкынга тормыш тәҗрибәсе дә, еллар тезмәсе дә яшеренгән. Аларны бары тик сәнгатькә мәхәббәт кенә берләштерә.

PRESSA.RU

Тик аның тормышы яңа моң, яңа аһәң белән тулды. Гөлсинә аның өчен якын дус, сердәш кенә булып калды. Кызның хисләре турында ул уйлап та карамады. Шуңа күрә Гөлсинәнең радио тирәсендә йөрүләренә, диктор булырга тырышуларына һич исе китмәде. Бүтәннәр йөри бит әле. Аларга ярагач, нигә Гөлсинәгә ярамасын?

Гөлсинә ныклап микрофон алдына утырырга ниятләгәндә, Равил инде чарланып беткән иде. Шуңа күрә ул, Гөлсинә каушап, авазларны йота башлаганда, аның кулына кагылып куя иде. Бу аның:

– Тыныч тот үзеңне, каушама, барысы да әйбәт булыр, – дию иде.

Кызның тавышы моңарчы бер генә хатын-кыз диктор тавышына да охшамаганлыгын радиода тиз сизеп алдылар һәм, вак-төяк тапшыруларда чарланып киткәч, хәбәрләр программасына Равил белән даими пар итеп куйдылар.

Гөлсинә моны күктән төшкән бәхет итеп кабул итте. Һәм бу эшкә баш-аяк белән чумды. Иртәнге тапшырулардан соң укуга йөгерә, укудан соң кичке тапшыруларны алып бара да хастаханәгә төнге дежурга чаба. Шулай атналар, айлар, еллар үтте, һәм торабара, ике кулына бер булып, радио гына калды.

Көн саен бергә чыгыш ясауларына халык шулхәтле ияләште, ә радиодагылар аларны стажлы кияү-кәләш дип тә йөртә башладылар.

Кызлар чәчәк кебек бит ул. Бер вакыты узгач, алар сула. Тик Гөлсинә үзен килеп алганнарын көтеп тора торган кыз түгел иде. Ул, ниһаять, үгезне мөгезеннән үзе тотарга булды.

– Стажлы кияү белән кәләш булып күпме яшәргә була? Болай булса, без синең белән гомер буена кысыр кияү белән кәләш булып калачакбыз. Туй балдагы алырга күптән вакыт, – диде ул Равилгә.

– Нинди туй балдагы? Кемгә? Әллә кияүгә чыгасыңмы? – диде Равил аны аңламыйча.

– Кемгә булсын? Синең белән миңа инде.

– Мин бит өйләнергә уйламыйм. Кәләшем юк.

– Ә мин?

– Син? – Равил тотлыкты. – Чынлапмы?

– Чын булмыйча! Гел уйнап йөрергә без бала-чага түгел!

Шулай икән шул. Бала-чага түгел икән. Ярата ул Гөлсинәне, тик өйләнер өчен башкача ярату кирәк. Егет Гөлсинәдән башка яши ала, ә Чәчкәдән башка?

Ул аның һәр концертын карап барды, үзенең аңа тиң түгеллеген белә торып аны сөйде. Аның үзе яшендәге җырчы улы барлыгын да, ир хатыны булуын белү дә өметен өзмәде. Нәрсәдер көтте дә көтте, өмет юклыгын белә торып көтте. Егетнең Чәчкәле дөньясында Гөлсинәгә урын юк иде.

Гөлсинә аны икенче көнне үзе белән ательега алып керде һәм туй күлмәгенә заказ бирде. Кибеткә кереп балдак сайлады. Равил алдында бертуктаусыз сөйләнде, «өйләнмим» дип авыз ачарга җай калдырмады.

Икенче көнне Равил Чәчкә янына керде. Чәчкә үзе генә иде. Ул җылы шарфка төренгән, кәефе юклыктан зарланды. Соңгы вакытта «Чәчкә авырый, авыруы җитди», дигән сүзләр Равилнең колагына килеп ирешкән иде.

– Өйләнергә җыенуыңны ишеттем. Әнә бүгенге газеталар сезнең турыда язалар. Кибеттә балдак сайлаганыгызны фотога төшергәннәр, – диде ул.

Равил өчен Чәчкә ифрат шат иде.

– Мин өйләнмим! – диде Равил чарасыз калып.

– Ничек инде өйләнмисең, үскәнем? Ир-ат кеше өйләнергә тиеш. Табигать кануннарына каршы килергә ярамый. Хатын-кыздан башка тормыш тормышмыни?

– Өйләнә алмыйм мин!

– Юкны сөйләмә. Гел яратып кына өйләнмиләр. Гел бергә булгач, бер-берегезгә ияләшкәнсез, хисләрегез үткенлеген югалткан төсле тоеладыр. Бергә тора башлагач, яңара ул.

– Безнең арада берни дә юк!

– Ничек инде?

– Мин бүтәнне яратам.

– Ә ул?

– Ул... ул...

– Аңлашылды. Җавапсыз мәхәббәт.

– Мин сезне яратам! – дип ярып салды Равил.

– Ах син, әнә күңелеңдә нинди хөсетлек икән бит! – диде Чәчкә. – Рәхмәт сиңа, үскәнем. Мине шундый биеклеккә күтәргән, йөрәгеңне ачкан өчен рәхмәт. Ә мин тормышымның мәгънәсезлегенә ышанган идем, алга таба халкымның мәхәббәте булмаса, нишләр идем, үзем дә белмим. Синең сүзләрдән соң миңа күк капусы ачылгандай булды. Соңгы сулышымда да үземне бәхетле тоярмын.

Равил, чарасызлыктан хушлашып, ишеккә юнәлде.

– Равил! – дип туктатты аны Чәчкә. – Син дә бит... Син дә минем соңарып чыккан кояшым... Кил әле, шуның өчен маңгаеңнан үбим үзеңне...

Шулай аерылыштылар. Ә икенче көнне иртән радиога килгәч, Равил аның үлем хәбәрен ишетте. Йөрәге... Артык таушалган булган аның йөрәге...

Чәчкә үлеме белән Равилне радио белән бәйләп торган җеп өзелде. Шуңа күрә радиодан китү аның өчен фаҗига булмады. Равил бүтән эшкә күчте. Гөлсинә калды.

Чәчкә, үлсә дә, Гөлсинәдән барыбер тартып алды Равилне. Гөлсинә аны менә шуның өчен хәзер дә көндәше итеп кабул итә. Әнә бит, бәхетле гаилә корып, оныкларын күрү бәхетенә ирешсә дә, Чәчкә турындагы һәр тапшыруда каушый, кабалана, дулкынлануын сиздермәскә тырышкан саен, тартыкларны йота.

Равил һаман ялгыз. Аның өчен бер нәрсә ачык: ул ике дистәдән артык елга соңлап туган, әллә Чәчкә апасы алдан туганмы? Бары тик шуңа күрә юллар аерылган, язмышлар буталган.

Гөлсинә, тырышып-тырышып, Чәчкә апасына чираттагы мәрсия укуын тәмамлап килә...



Асия
ЮНЫСОВА

ТЕЛ ТИБРӘТҮ ДИП ЯЗДЫМ ДА ҮЗЕМӘ КЫЗЫК БУЛЫП КИТТЕ. ӘГӘР МИН «ТЕЛ ТИРБӘТҮ» ДИП ЯЗЫП КУЙГАН БУЛСАМ, БУ БИТ «БИШЕК ТИРБӘТҮ» КЕБЕГРӘК ГАМӘЛ БУЛЫП АҢЛАШЫЛЫР ИДЕ. Ә МЕНӘ ТАЛ ТИРБӘЛӘ ДӘ, ТИБРӘЛӘ ДӘ АЛА.

ТЕЛ ТИБРӘТҮ

Тирбәлгәндә, ничектер, бер эш башкарган кебегрәк димме соң. Ә менә тибрәлгәндә бу эшгамәлгә хисләр килеп кушыла сыман, үтә дә нәзек, нечкә хисләр... Бу тибрәлүгә инде, һичшиксез, шул талга кунып, сандугач сайравы да кирәк.

Әй, нинди гүзәл, нинди нәфис, нинди сизгер син, татар теле. Хәтта үз урынын төрки телләр анасы сыйфатында дәгъвалаган төрек теле дә һәр халәт төсмеренә сизгерлек җәһәтеннән татар теленнән бик нык калыша. Иң кызыгы: фәкать татар баласы гына шул күзгә күренмәс ефәк кебек нәфис аерманы тоемлый ала. Игътибарга алганым бар: бүтән халык арасында үскән, татар телен яхшы беләм дип уйлаган татар балалары да шул нәзеклекне югалткан булып чыга. Әйтик, ул кеше кемнеңдер өенә кайтуын хәбәр итәргә теләгәндә: «ул өйгә килде», дип сөйләп куярга мөмкин. Тел гыйлеме бала чагында сеңеп кала шул ул. Соңыннан өйрәнгәне барыбер чит тел кебегрәк үзләштерелә.

Шулай бер кичне «Бәкер» шифаханәсенең зур юлында кичке шифалы һаваны сулап йөреп торам. Миннән алдарак шундый ук салмак адым белән тагын дүртәү атлыйлар. «Бәкер»дә Себер якларында бәхет эзләгәннәр еш очрый. Кырым, Төркияләрне түгел, нәкъ менә «Бәкер»не сайлый алар ял итү урыны итеп. Татар мохитен сагыну, җирсү кайтара аларны. Болар да шундыйлар, ахрысы. Атлый-атлый кошлар исемен йөрткән биналарны күзәтәләр. Исемнәрен русчага тәрҗемә итеп баралар. Үзенә күрә бер имтихан: янәсе, онытылмаган икән әле туган



тел. Бик җиңел генә «Сандугач»ны тәрҗемә итеп куйдылар: «Соловей! Да, да, соловей!» «Аккош»ның тәрҗемәсе тагын да җиңелрәк, чөнки сурәте бик төгәл төшерелгән. Өстәвенә, әнә генә күлдә аккош үзе дә йөзеп тора. «Карлыгач»ны да ерып чыктылар. Чиратта «Тургай». Ни җырчы кошның үзен таный алмыйлар, ни сүзен белмиләр. Түзмәдем, бик тавыш күтәрмичә генә, ярым пышылдап кына диярлек «жаворонок» дип куйдым. Туйда кәләш гөлләмәсен тотып алган кызлар кебек сөенештеләр: «Тургай! Как красиво звучит! Ты ведь у нас тоже тургай!» Араларыннан берсе калыша төшкән иде. Һаман үз алдына сөйләнә бу: «Что это такое – не знать свой родной язык? Как это называть?»

Мин тагын ярдәмгә ашыгам: «Это позор!» Ишетте бит бу сүземне дә: «Да, да, позор! Но я не виноват! Не учили меня! В русской школе я учился». Таныш, бик таныш проблема бу. Күпләр шулай «югалтты» ана телен. Татар теле «кухня теле» статусын саклаганда да югалмый иде әле ул. Ләкин «телсез буын» дәү әниләр яшенә җиткәч, кинәт кенә хәл хөртиләнде. Чөнки 90 нчы елларда «уянган» зиһенле яшьләребез үз балаларын җәйгә, әби тәрбиясенә өмет баглап, авылга кайтаралар да бит...

Башлыйм әле яңабаштан. Әлеге дә баягы «Бәкер» күленә якындагы Иштирәк авылыннан бер матур апа дүрт оныгын ияртеп су коенырга килгән. Балалар тереләр, үткеннәр, тыңлаучаннар. Күренеп тора – тәрбияле гаиләдән болар. Исемнәре дә уптым илаһи түгел, уйлап куелган матур, мәгънәле исемнәр.

Менә шушы Нариман, Сәмирхан, Зәринә, Сәмираләр белән дәү әни фәкать русча гына сөйләшә. «Татарча сөйләшергә өйрәт дип кайтаралар да бит. Балалар мине аңламагач, русча кычкырам инде», – дип аклана дәү әни. «Соң син аларны үзең «аңлама», – дип котыртам аны, – «аңгыра» дәү әни аңласын өчен татарчага күчкәннәрен сизми дә калырлар».

Халык арасында буталып йөри торгач, файдам да тиде. Сигез яшьлек Алсу әнисенең «мама» түгел, «әни» икәнен белеп китте. Ә бит югыйсә кыз баланың анасы ниндидер оешмага күчкәнче мәктәптә татар теле укыткан. Безнең алга утырып бер-ике татар әкияте тыңлаганнан соң, бу бала әнисенә беләсезме нинди дәгъва белдерде: «Ты со мной совсем не занимаешься!» Киләчәктән кайтаваз бу. Киләчәктә әйтеләчәк гаепләү. Тагын да аянычы бу да түгел әле. Алсу татар гимназиясенең беренче сыйныфын тәмамлаган икән. Димәк, әни кеше кызын телдән аерырга җыенмый. Ләкин безне, Алсуны да, урап алган рус телле мохит татар баласын йота бара.

PRESSA.RU

Сәламәтлек телим мин сиңа...

Бу дөньяда яшәү гаҗәп авыр –
Борчулары йөри мең килеп,
Ә бәхетне саулык кына бирә –
Сәламәтлек килсен иң элек.

Кушымта:
Бәгырьләрне телгән борчулардан
Көчлеләр дә кайчак бер сына,
Бирешмичә, янып яшәр өчен
Сәламәтлек телим мин сиңа.

Байлыгы да читтә өелеп кала,
Дәрман биргән саулык булмаса,
Сөю уты чәчеп, йөрәгеңдә
Дөрләп янган учак тормаса.

Кушымта.

Кадерен белми, җуйсаң саулыгыңны,
Мең тарафка эзләп чабарсың,
Хәлсез калып, өметең сүнгән чакта
Бу җырымнан шифа табарсың.

Кушымта.



САУЛЫК КЫНА БИРӘ БӘХЕТНЕ!

Инде ничә еллар биш жанрда (шигърият, проза, балалар өчен шигырь, әкиятләр, тәрҗемә һәм публицистика) язсам да, бала чактан ук җырлап, биеп үскәнгә, җыр-музыкага да тартылу көчле миндә. Заманында Фәридә Кудашева, Әлфия Афзалова, Илһам Шакиров җырлаган җырларны отып алып, мәктәптә уздырыла торган бәйрәмнәрдә, клубта үткәрелә торган кичәләрдә сәхнәгә чыгып җырлый идем. Бигрәк тә Хәсән Туфан, Гөлшат Зәйнашева, Мостай Кәрим сүзләренә язылган җырлар ошый иде. Чөнки барысы да мәгънәле, көйләре дә бик матур.

Безнең әни бик матур җырлый иде. Аның Яңа ел бәйрәмендә Габдулла Тукай сүзләренә җырлана торган «Сөялгәнсең чатта баганага» («Зиләйлүк») җырын җанга үтеп керерлек, үзәкләрне өзәрлек итеп җырлавы (аны ул гына белә иде) әле бүген дә күңелдә. Бәлки, шуңа күрәдер дә, махсус уйлап язмасам да, җыр сүзләре һәм алар нигезендә матур җырлар үзеннән-үзе туа баргандыр. Минем сүзләргә язылган җырлар инде җитмешкә якын. Беренче җырларым исә моннан кырык елга якын элек үзем язган көйгә һәм танылган композиторыбыз Резеда Ахиярова музыкасында туды. Алар радио-телевидениедә күп мәртәбәләр яңгырады. Шуны да әйтеп үтәсем килә: көен дә, сүзләрен дә үзем язган «Ни хәлләр итим икән?» дигән тәүге җырым педучилищедан соң Кыргызстанның Ош өлкәсендә укытканда – 1969 елда язылды. Аның үз тарихы бар: Алжирда илчелектә эшләүче егетем өйләнергә кайтты. Рус булганга, әтием ризалашмады, татар егетен тап, диде. Чөнки нәкъ шул көннәрдә Илгиз абыем өйләнде, рус кызын алды. Кызның әти-әнисен безнең әти үзе барып ризалаштырып кайтты. Алар, башка дин кешеләре булганга, шулай ук риза түгел иде. Ә туй барганда, татарларны рәнҗетерлек сүзләр әйтә-әйтә, кәләш ягы ызгыш чыгарды. Шуннан соң әти миңа теге сүзләрне әйтте. Әтинең сүзен аяк астына салып таптыйсым килмәгәнгә, биш ел йөргән (күбрәк язышкан) егетемне ташлап, елый-елый яңадан Ошка чыгып киттем. Анда барып җиткәч язылды менә шушы җыр. Бер елдан соң кайтып, университетка укырга кергәч, Резеда Ахиярова белән очрашып сөйләштек тә, ул аны нота-ларга салып эшкәртеп бирде. Беренче башкаручысы Лидия Әхмәтова булды. Сүз уңаеннан шуны да әйтим: бүгенге көндә көен дә үзем язган җырым – берничә. Өстәвенә, элек мәдәният министры булып эшләгән энем Илдус та кайбер сүзләремә көй язды. Җырларымның һәркайсының үз тарихы бар. Мәсәлән, «Кояшың яктырак яначак» дигән шигыремне өч композитор көйгә салды. Һәрберсенең үз яңгырашы. Аларны Татарстанның халык артистлары Лидия Әхмәтова, Зөлфия Шакирова Венера Ганиева һәм Хәния Фәрхи халыкка җиткерде. «Туган көн», «Синнән башка» дигән җырларның тарихы да шулайрак. Җәвит Шакиров башкаруындагы «Илле яшь», Рөстәм Закиров репертуарындагы «Күзләреңә тагын карыймчы», берничә җырчы башкаруындагы әтиемә багышланган «Гармун» җыры да халыкка киң таралды.

Халык күңелен яулаган «Сәламәтлек телим мин сиңа» дигән җыр турында тәфсилләбрәк сөйлисем килә.

Иң изге теләкләребезнең беренчесе – саулык-сәламәтлек, дияр идем мин! Якыннарыбыз, туганнарыбыз, дусларыбыз белән күрешкәндә дә: «Исәнмесез?», «Саумысыз?» – беренче сүзебез. Саубуллашып киткәндә дә: «Сау булыгыз!», «Сәламәт булыгыз!» дигән сүзләр – шулай ук беренче.

Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән бирелә торган бу халәткә багышлап күптән шигырь язасым килгән иде. Никтер, уй төшкәч тә язылып китмәде: дөнья мәшәкатьләре саулыкны кайгыртырга вакыт калдырмый иде. Ә менә 1998 елда йөрәккә операция ясалгач, язмас җиремнән язарлык булдым. Операциягә кергәнче, исән калырмынмы, дип борчылдым. Уңышлы үткәч тә, ничә ел яши алырмын икән, дигән курку басты. Ходайга шөкер, бүгенге көндә дә халкым, киләчәк буын – балалар белән мәктәпләрдә, гимназияләрдә очрашуларга йөреп, иҗат итеп, җәмәгать эшләрендә катнашып, зур активлык белән яшәп ятам. Сәламәтлек булмаса, боларны эшләп булыр идеме? «Сәламәтлек телим мин сиңа» дигән җыр менә шулай туды. Ул сүзләргә танылган дүрт композитор көй язды: беренчесе – Резеда Ахиярова (анысын Татарстанның халык артисты Асаф Вәлиев башкара), икенчесе – Луиза Батыр-Болгари (ул җырны Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Нәргиз җырлый), өченчесе – Башкортстан композиторы Илдар Низамов (Башкортстанда Нурия Ярмөхәммәтова җырлавы аша беләләр), дүртенчесе – Илназ Бах (әлеге җыр яшь җырчы Раяз Фасыйхов репертуарында). Җырларның дүртесе дә миңа бик ошый. Әмма дүртенче вариант, әллә яңа булганга, әллә яшь җырчы башкарганга, тагын да матуррак кебек. Дөресен әйткәндә, алдагы өч вариант бүгенге көндә дә яңгырап торса да, җырлар тарихына кереп бара бит инде. Кабат башкаручы булса гына яңарыш табарлар дип уйлыйм.

Кадерле милләттәшләрем, чынлап та саулыкны сакламыйча, байлык артыннан гына куып, бәхетле булырмын дип уйламагыз. Чиргә сабышып, бакыйлыкка күчеп китсәң, барысы да өелеп кала. Үзең белән бернәрсә дә алып китә алмыйсың. Миллионлаган акча түксәң дә, авыруны коткарып кала алмаган очраклар бик күп. Шуңа күрә, беренче чиратта, сәламәтлекне саклагыз. Сәламәт кеше генә барысын да булдыра. Авыруның күзенә берни күренми.

Сезнең һәммәгезгә дә иң изге теләкләр, хөрмәтле милләттәшләрем! Бу җыр сезгә, шигырьдә язылганча, чынлап та шифа китерсен иде!

Флёра ТАРХАНОВА,
Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе.

PRESSA.RU



АВЫЛ МАҖАРАЛАРЫ



Алмаз ЗАКИРОВ

Мажаралар, сәяхәтләр, адреналин, экстрим – болар минеке! Студент елларындагыча, Америкага китеп эшләп кайтсаң иде ул!.. Нью Джерси штатының Фрихолд шәһәреннән 22 чакрымдагы Маналапан шәһәренә – эш урыныма көн дә автобуска түләп йөрмәс өчен (аена 60 доллар), 40 долларга велосипед сатып алган идем анда. Бер йортта бергә яшәгән Литва егетләре шулай өйрәтте. Кайтып китәр алдыннан җыенызбынкын сатып калдырдым. (Өйләренә миннән берничә көнгә алданрак очкан шул Вильнюс малайлары киңәше буенча инде.) Узган ел танышларымның: «Рульгә утырып безнең белән Кырымга барасыңмы?» – дип бер сызгыруы җитте – мин инде бер ягы – тау, икенче ягы диңгез булган серпантин юлларга бик рәхәтләнеп чыгып киттем! Юл озын һәм ялыктыргыч тоелмасын өчен, Казаннан Ростовка кадәр араны тукталышларсыз гына үзем үттем. Абхазиядә исә Кавказ егетләре үзләренә кунакка дәште – авызны ут кебек өтә торган шашлык белән сыйладылар.

Бу җәйдә дә әнә шундыйрак мажаралар турында хыялланган идем. Таптым бит – авылга кайтам!..

Бәрәңге бакчасы, көтү, үгезләр

Балачагымда каникулларга ашкынып кайта торган авыл еракта калган күңелле көннәре белән ымсындыра башлады. Көтү көтү, балык сөзү, трассага алып чыгып сатабыз дип, кысла тотып пешерүләр, атка атланып чабу, таңнар аттыру, бикле ишекне ачтыра алмагач, форточкадан керүләр (әбекәй белән бабкай, теге малай кич чыгып йөрмәсен әле, дип, юри бикләп куялар, аннан уятып та булмый үзләрен), матайда кызлар озату. Боларга әле чүпле бәрәңге бакчасы, колорадо коңгызлары өстәлә... Кышын төлке, куян ауларга барабыз...

...Палатка, спальник (йокы капчыгы), кабартылма матрас, җыелмалы өстәл, 8 литрлы казан (Кырым татарларыннан пылау пешерергә өйрәнеп кайттым былтыр!), кармак, спиннинг, куртка, ау костюмы, кроссовкалар машина багажнигына... чак сыйды! Язын сплавтан кайткач, Наил, Илшатлар белән Башкортстанның Урал ягындагы тау елгаларына барып чыгу уен да күңелгә беркетеп куйган идем: авылдан әллә ни ерак калмый анда. Болар – хыялда.

Ә чынлыкта...

Чынлыкта, мин уйлаганнан да көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты быелгы җәйге ялым. Көтүче, балыкчы, җиләк җыючы, аш пешерүче, төзүче, хәтта детектив та булырга туры килде. Өстәвенә, 90 яшьлек әбекәйгә дә күз-колак буласы. Сагынуларына чак чыдап, кышны Казанда үткәрә дә, яздан ук ашкына-ашкына авылга кайта ул безнең. Аннары 360 чакрымлы авыл белән Казан арасында атна саен тыз да быз йөрибез. Һи, нәрсәсе бар инде аның, дисезме? Мин дә шулай дигән идем дә...

Иртән чәй эчкәндә әбекәй гел бер үк сүзләрне кабатлый: «Бәрәңгене корт ашап бетерә инде...» «Ярар, бүген үк хәл итәрбез аны», – дип тынычландырам да... «Иске Иделдә балык тотабыз, киттек!» – ди Наил. Мондый форсатны ничек ычкындырмак кирәк?! Иртәгә дә качмас әле бакча, дип, тиз-тиз җыенам да – әллүр Агыйдел ярына.

Икенче көнне «Корадо», «Танеко» ише моңарчы колак ишетмәгән препаратларны әзерләп, уңъяк күрше Эдуард, сулъяк күрше Рөстәм белән ничек, кай вакытта агу сиптерсәң яхшырак буласын энәсеннән җебенәчә сорашып, битлекләр әзерләп, кояш сүрелгәч, бәрәңгене коткарырга ниятләгән генә идем... Көтүдә Наилләр чираты икән. «Килеп кит, су да кереп чыгарбыз», – дип чакыралар.

Уу-у! Андагы киңлек! Яшел тугай! Ромашкалар... Күбәләкләр... Кәккүк кычкыра... Чыбыркы тавышлары. Үшән сыерлар, әз генә якын килсәң дә, өркелеп бер читкә тайпылучы куркак, аңгыра сарыклар... Балачакны искә төшереп, атка атландым. Атым, ток-ток басып, киреләнмичә генә, мине еракта рәшә булып күренгән офык читенә таба юртып алып китте. Баш очымдагы каурый болытлар безгә иярде, җиләк исе, чәчәк исе, саз үләннәре исе белән җил борыннарны кытыклап узды. «На-а, малкай! Очтык, әйдә!» Атым, шуны гына көткән кебек, алга томырылды. Үземне Америка ковбойлары кебек хис иттем.

Илшат кул изәп чакыра: «Бу челләдә пешеп үләбез, әйдә, тизрәк суга чумабыз!» – ди. Теге якта – үгез көтүе. Шөлләтә бераз. Җитмәсә, Рифкать абыйның: «Егетләр, ычкыныгыз, шәрә кешене яратмыйлар!» – дигән сүзләре күңелгә шом салды. Бер үгез, әнә, ачуланып карап тора! Шәрә дигәч тә инде, без бит плавкидан. «Нәрсә булсын соң!» – дип, Илшат, шап-шоп килеп, суга кереп китте, мин аңа иярдем... Курыкканга – куш, диләрме әле – теге ярдагы ала-кола үгезләр соры тау булып күренде күземә! Котыртмыйк боларны дип, куе таллык-чытырманлыкны ера-ера, чыгу юлына борылдык. Шунда нәрсәдер шап итте. «Булды бу! Берәр агачка менү ягын кара!» – ди Илшат. Җан-фәрманга агачларга таба чабам. Йә Хода! Кросста да болай чапканым булмагандыр. Ничек котылырга, кая кереп качарга? Мин инде үгезнең тояк тавышларын ишетәм кебек. Бер адым, ике... Тизрәк, тизрәк! Сабантуйда колгага үрмәләгән кебек, әллә нинди ботаксыз шәрә агачка маймыл тизлегендә ничек менә алдым икән мин?! Җирдән чак аерылып өлгердем, теге үгез дә күзләрен алартып, пошкыра-пошкыра тоягы белән җирне тырный башлады. Бераз һушны җыйгач, Илшат: «Берәр ботак сындырып бир әле, шулай кусаң китәргә тиеш», – ди. Авыл малае шул, мин андый нечкәлекләрен белмим дә. Табан ялтыратуларыбызны ярый әле кызлар күрмәде!

Кайтып керсәм, Эдуард инде бакчага агу сиптерә; Рөстәм ике егет ияртеп кайткан: бәрәңге төпләрен өяргә маташалар. (Әби тәки тынгы бирмәгән боларга!) Ура! Эңгер-меңгердә ерып чыктык бу эшне. Инде тыныч күңел белән кич чыксаң да ярый.

Их әбекәй, синең сүзне тыңлап, бәрәңге арасында гына йөргән булсам соң!..

Әбекәй – сыйфат комиссиясе рәисе

Бу өйнең эше гел бетеп тормый икән! Әле пластик тәрәзәләр куясы, әле түбәсен профнастил белән ябасы, өй тышлатасы, электр чыбыкларын алыштырасы, коймаларны яңартасы... Җәй саен әле берсе, әле икенчесе. Өй нигезен ныгыту чүп кенәдер дисәм, булыр сиңа! Стеналарны тигезләргә, грунтовка ясарга кирәк, диләр... Шаккатып карап тордым. Ярый Рөстәм шәп егетләр табып бирде. Күрше авыл егетләре берничә көндә ялт итеп тә киттеләр. Тик аңа кадәр әле төзелеш материаллары юнәтергә, арзанрак бәядәгеләрен эзләргә, анда чабарга, монда чабарга кирәк иде. Иләннәр салкын булуга әбекәйнең эче поша, өйне ныгыту өчен акчаны һич җәлләми бирмәкче. Тик аның акча исәбе узган гасырдагыча кал-

Фото: Алмаз Закиров

PRESSA.RU

ган шул. 50 мең ни, 5 мең ни аңа. Ә кирәкнең очы-кырые юк. Такталар, агач рейкалар, монтаж күбеге, җылыткыч материал, саморез, сайдинг, кадак... Әбидән акча алу – федераль бюджеттан субсидия сорауга тиң: тиенен-тиенгәчә нәрсәләргә тотканыңа отчет биреп барасы. Өч көн дигәндә эш бетте, әбекәйнең сыйфат комиссиясен узганнан соң (ул бик ошатты!), исәп-хисап ясап, егетләрне озаттык.

Каен урманы исен аңкытып, пар-пар себеркеләрем мунча түбәсендә эленеп тора .

Утын ярып маташа идем, Эдуард әйтә, Питраугa кадәр пиннекләр әзерләп куярга кирәк, ди. Мунча себеркесен безнең авылда шулай диләр. Соңга калсаң, яфраклары да коела, себеркесе дә каты була икән. Аның олы тәгәрмәчле вездеходы бар, теләсә нинди урман-чытырманнарга, агач ешлыкларына да керә торган. Тайганы да ерып чыгадыр, билләһи! Киттек шуңа утырып. Яшь каен, яшь имән ботакларын иплән кенә сындырып җыйдык, әллә кая эчкәре кереп, хуш исле зәңгәр мәтрүшкәләр өздек. Себерке бәйләргә дә өйрәнеп кайттым. Әбекәй канәгать, ай-яй, күп эшләдең, дип мактый.

Авыл кешеләре гадирәк, ярдәмчелрәк, беркатлырак була икән. Әллә ниләр майтарсалар да, кәпрәеп йөрмиләр. Мәктәп еллларында ничек дус булсалар, нәкъ шулай аралашалар да. Бүген пылау белән сыйлыйм әле үзләрен.

Тә-әк, дөгене ун кат юдым. Ишегалдына казан астым. Башта башлы суганны кызарганчы тоттым, аны алып куеп ит, кишер кыздырдым, сарымсак, зира, куркума кебек тәмләткечләр, аджика куштым. Иң ахырдан дөгене салдым. Ошаттылар егетләр! Казан гына кара корымга буялып беткән иде. Әби ком белән юарга кушты. Кара, чынлап та агарта икән!..

Паспорт белән... җиләккә

Быел урманда җиләк утырып җыймалы, диләр. Ялларга әни дә кайткан иде. Классташы Әлфия апа котыртты: «Төкәй яланына гына барыгыз. Ике сәгатьтә биш литрлы чиләгем тулды», – ди. Җиләк диюгә, әбекәйгә җан керде. Яшьрәк чагында су чиләген тутырып җыеп кайта торган булган ул! Катыкка салып та ашаганнар, как та койганнар, кышка җиләк кайнатмалары да әзерләгәннәр. Аны да алып барыйк әле, урман һавасы сулар, ичмаса. Әйтүебез булды – сөенә-сөенә җыена да башлады! Яулык, кәлүш, таяк... Һәркайсын көчкә эзләп табып, яңадан югалтып, кабат кулына тоттыргач, кечкенә кара сумкасын да алды. «Дөнья хәлен белеп булмый, паспорт, документлар, акча...» – дип сөйләнүенә исем китмәгән иде. Төйнәп бәйләнгән зәңгәр пакетны кулыннан алдым да багажникка ыргыттым. Йә капкаларга дип алган ризыктыр инде...

Басу юллары, башаклар, зәңгәр кыңгырау чәчәкләр... Ул җиләк! Утырып түгел, ятып җыймалы! Әбекәй дә җыя: чүгәләп түгел, ятып. Һич бездән калышмый. Аннары, арып-әлсерәп, күләгәгә барып чүмәште. Черем итеп тә алды. Ул бик канәгать иде. Чәчәкләр җыеп, матур күренешләрне фотога төшерә-төшерә кайттык. Әйберләрне машинадан бушатканда зәңгәр пакетын үз кулларына тоттырдым: теге сумкасы шуның эчендә булган икән.

Ярый, хуш, җитте кич, батты кояш. Әбекәй генә пошаманда. «Документларым, паспортым, акчаларым юк!» – ди, чак еламый. Җиләк аланы, машина, багажник берәмтекләп күз алдыннан йөгереп узды. Урманда бездән башка бер җан иясе дә юк иде бит! Зәңгәр пакет та ничек салынган булса – шулай, исән-сау кайтты. Күзгә күренми торган җан ияләре килеп, пакетны чишеп, сумканы ачып, акчаларны алып, кире төйнәп куймагандыр бит инде?! Юк, бу логатькә сыймый! Тукта, тукта... Әбекәй, мөгаен, өйдә калдырган ул янчыгын... Ашыгып, сумканы гына пакетка тыккан, ә янчык – калган! Өйнең астын-өскә китереп, янчык эзли башладык. Сандык та, китап киштәләре дә, урын-җир дә актарып ташланды. Караватаслары, мунча алды,









карлыган куагы төпләре, шкаф, суыткыч эчләре, өстәл тартмалары кырык тапкыр тикшерелде – янчык беркайда юк! Әллә... берәрсе? Юк-юк, ноутбук, фотоаппарат, үземнең акчалар... бар да үз урынында. Эт тә кермәгән! Хәтерсез әбекәем каядыр кыстырып куйган да оныткан инде. Ләкин бит паспортсыз да, акчасыз да яшәп булмый. Бер айлык пенсия акчасын кыстырган саклык кенәгәсе паспорт эчендә булган. Тиз арада милициягә хәбәр итәргә, паспорт өстәленә гариза язарга кирәк. Шулай да җиләккә дигән сылтау белән теге аланлыкны ике тапкыр урап, капшап кайттым әле. Төшеп калган булса, табылыр иде. Аннан урманда шул 2-3 көндә кем генә йөрмәс? Дүшәмбе паспорт өстәле эшләми, сишәмбе – Ураза гаете көне, чәршәмбе, әбекәйне утыртып, район үзәгенә төшәсе, яңа паспортка фото ясатасы, югалу турында гариза язасы... Уф!..

...Гает көнне чәйләп утырганда ишектә кыңгырау шалтырады. Елмаеп, таныш түгел өч хатын-кыз басып тора. Өлкәне – Фәния апа дигәне, сәлам биреп, бәйрәм белән котлады, әбекәйне сорады.

– Сөенечле хәбәрләр белән килдек әле, – ди.

Нинди сөенечле хәбәр булыр икән дип уйлап кына бетердем.

– Чаллыдан кызларым кайтты, урманга җиләккә бардык бүген...

Урман ди, җиләк ди. Әллә...

– Документлар таптык. Паспорт, саклык кенәгәсе, акчасы да шунда... Халит абыең чәй эчәргә дә бирмәде, тизрәк сөендереп кайтыгыз ди...

Бу апа миңа шул минутларда фәрештәнең үзе кебек тоелды. Никадәр мәшәкатьтән коткардылар! Әби дә елый, Фәния апа да... Соңыннан, бу хәлне ишеткәч, күршеләр дә... Сөенечтән! Исенә төште әбекәйнең, паспортын халат кесәсенә генә шудырган булган бит! Әллә нинди могҗизалы көн булды ул!

Тозы да таман гына...

Авылда, әбекәй өендә гадәти көн дәвам итә. Миңа иртүк торып су алып керәсе, кибеттән ипи алып кайтасы, ботка пешерәсе (кыен түгел икән, кайнап торган суга салып болгатып кына торасы), көн саен дүрт төрле даруын эчерәсе, савытларны юасы, кыяр-помидорга, чәчәкләргә сибәр өчен су агызып куясы, идән юасы, Рәисә апа сөткә кер дигән иде... Кичә җыйган карлыганнан вареньe кайнатырга кирәк. Ничек? Күпме шикәр комы салырга? Ярый телефон бар. «Килога кило ярым исәбеннәнме? Хәзер песокка йөгерәм... Нәрсә-нәрсә? Банкаларны юарга? Тукта әле, әбекәй... Юк, сиңа әйтмим, әни... Нинди кирәк? Хәзер... шундадыр...»

Телефоннан сөйләшкәндә әбекәй әнә шулай килеп кысыла. Йә көрәк, йә таяк, йә чиләк, йә башмак эзли: аныңча – кемдер алган. Бик оста итеп эш куша тагын. «Тавыклар кермәслек итеп берәр терәү куясы бар», «Мунча ягып җибәрәсеңме?», «Бәрәңге бакчасы чүп кенә!», «Ишегалдындагы үләннәрне чабып кына керерсең әле»...

> *Анысы да монысы, бөтен күрше-күлән бу югалту турында хәбәрдар, һәм барысы да чын күңелдән тизрәк табылуын тели иде.*

Ә минем аш пешерәсе бар! Кайнап чыккач, итнең күбеген җыясы, ди. Кайда соң тишекле кашык? Тоз савыты кайда? Суган да кирәк. Уф! Күбеге тарала инде мин җыйганчы. Нәрсә дисең, әбекәй? Кайчы?! Кайчы сорамыйм! Җыйганчы дим! Туктап тор әле, бәрәңге әрчисем бар! Тимә, алып куйма ул табакны! Чиләк, чүмеч, кәстрүл тезелеп китте инде... Баш кайный. Җитешә алмыйм һич. Әбекәй, бар, ятып тор әле! Паспорт? Тагын кая куйдың икән? Хәзер эзлибез... Ул арада аш пешеп чыга. Токмач кына салам да... Ашның тозы... эх, әзрәк чыгынкырак бугай. Күбрәк салып ташлаганмын тозны.

Өстәл янына утырышабыз. Әбекәй, шулпаны авыз итеп карау белән, канәгать калып, мактап җибәрә:

– Бик тәмле булган! Тозы да таман гына...







PRESSA.RU



Кешенең өч туе бар. Аның беренчесе – бәби туе. Бу туйны без үзебез ясамыйбыз, чөнки әле биләүсәдә генә ятабыз. Соңгы туй – женаза. Анысына да катнаша, «мин шулай узуын телим» дия алмыйбыз...
Ә гомерлеккә дип сайлаган яры белән кавышуны – яшьлек туен башыннан ахырына кадәр һәркем үзе оештыра, үзе ничек тели – шулай үткәрә ала. Бу туйның ничек узуы безгә – тамадаларга да бәйле. Мин үткәргән туйлар үзенчәлекле – алар хәләл, анда Коръән ашы белән заманча йолалар бергә кушыла.

КИЛЕН ТӨШӘ...



Гамил НУР, хәләл тамада

Гореф-гадәтләр

Яшьләр белән беренче очрашу-танышуда ук: «Әти-әниләрегез кайсы яктан?» – дип сорыйм. Башта аптырап китәләр, аннан аңлыйлар. Чүпрәле районыннан икән, димәк, кунаклар күбрәк шуннан булачак: ул яктагы тәртип буенча, чәйне мәҗлеснең башында ук чыгарырга кирәк, ә бәлеш карабодай белән булса әйбәтрәк... Әйе, мин тамада-алып баручы гына түгел, туйны оештыручы да.

Гореф-гадәтләр сакланган авылларда туйлар, гадәттә, бер-берсен кабатлый. Моңа тыныч карыйм: туйга ниндидер яңалык кертү кайчак ясалмалык хисе генә тудыра. Гомумән, милли йолалар ерак авылларда гына сакланып калган хәзер. Йолаларны хөрмәт итүче, җыр-биюгә мөкиббән татарлар Башкортстанда яши. Алар суга төшерү йоласын да саклыйлар (безнең Актанышта да очрый ул), сандык сату, чәкчәк ашатуны да. Түбән Новгород, Мәскәү татарларында «чынаяк-чәшкә» дигән йола бар: табындагы һәркем чынаяктагы баллы ширбәтне каба, җырлый, аннары яшьләргә котлавын әйтә. Азнакайда кияү белән кәләшне бавырсак кабып котлыйлар – бу шушы якның матур йоласы. Кайбер төбәкләрдә «поднос өстенә менеп бию» бар. Биючеләр өстенә вак акча сибәләр – кияү белән килен аннары ул акчаны себерке белән себереп ала. Тау ягы районнарында (Яшел Үзән, Кайбыч, Апас, Кама Тамагы, Буа), Чуашстанда туйга алып килгән күчтәнәчне мәҗлестә табынга чыгарып, шуңа дога кылдыру йоласы бар, аны «саум» («савым»), диләр.

Уен-җырларны кабатламаска була, ә бу йолаларны мин кабатлату ягында. Әнисе 20-30 ел элек килен булып төшкәндә башта мендәргә баскан, бал-май капкан икән, кызы да туенда шуны эшләсен.

Кайбер туйларга ярты ел алдан әзерләнә башлыйбыз, ким дигәндә ике ай алдан тотынабыз. Хәмерсез туйдан күпләр әле дә курка. Минем белән очрашканчы, дуслары, туганнарыннан: «Аракысыз кызык булырмы?» – дип сорашалар. «Кызык булыр, әмма моның өчен минем берничә таләбемне үтәргә кирәк», – дим аларга. Туй буш, киң, пыяла ресторанда үтәргә тиеш түгел. Диварлары сары, шәмәхә, куе кызыл төсле булганны сайларга кирәк. (Моны мин уйлап чыгармадым. Казандагы иң популяр, халык иң күп йөри торган рестораннар ак түгел, нәкъ менә шундый җылы төсләрдә.)

Өстәлләрне дөрес урнаштыру да зур роль уйный. Музыкаль бизәлешкә дә таләбем югары. (Әмма кайвакыт музыка кулланырга да рөхсәт итмиләр. Ул очракта психологик таләпләрне тагын да тирәнрәк куям.)

Яңа йолалардан. Казанда чәй өстәле оештыру гадәте бар. Мин аны мөмкин кадәр матуррак ясарга тәкъдим итәм. Самавыр, иске сөлгеләр белән бизиләр, кемдер сандык та алып килә. Мәтрүшкә, сөтле чүлмәк, кәрәзле бал да куйгач, экшен килеп чыга.

Туйның дәрәҗәсе нәрсә белән бәяләнә?

Бу очракта һәркем аякны юрганына карап суза дию дөрестер. Хәзер дөнья, бердән, шәрыкләшә; икенчедән, Европа стандартларын сайлау да бара. Европада парлар язылыша да, 5-6 кеше ресторанга барып утыра: ашыйлар, теләсәләр – биеп алалар, шуның белән бетте... Ә бездә шул ике вариантның төрле вариацияләре бар. Кемдер Европача кылана: туганнарын туйга чакырмый, әмма шул ук вакытта эчтән азиат булып кала: санаулы гына кунакларын кыйммәтле – дүртәр мең сумлык ресторанга алып бара.

Соңгы вакыт яңа тенденция күзәтелә: туйны ясап тормыйлар, никах кына укыталар. Кризис вакытында чыгымнарны киметүнең бер юлы бу. Никах мәҗлесе тыйнак булса да ярый, андый ук затлы күлмәк тә кирәкми, кыйммәтле зал белән дә мактанасы юк, лимузиннар да ял итә, артист чакырмадым дип акланмыйсың.

Табынның сыгылып торуы белән дә халыкны шаккаттырып булмый. Берәү дә мәҗлескә ашарга дип кенә килми, аннан күпләр бүген диетада утыра. Кайбер акыллы егетләр – мин аларны шулай дип саныйм – кызлары авылдан икән, туйны районга кайтып ясый. Чөнки Казандагы 3 мең сумлык менюга караганда, әйтик, Балтач кафесындагы 1 мең сумлык меню тәмлерәк тә, мулрак та. Туй үткәрүче, шулай итеп, 200–300 мең сумын янга калдыра ала. Арзанлырак итү юллары тагын да бар: зур коттеджны арендага алып, туй мәҗлесен шунда гына уздырырга яки элеккегечә өйдә генә дә үткәрергә мөмкин. Арзанлы зал алып, табынны үзе әзерләүчеләр дә бар. Пыяла диварлы зур, биек заллар күп чыгым сорый: аларны «тутыру» өчен бай программа кирәк.

Минем клиентларым башлыча мөселманнар, алар исраф итмәскә, кредит алмаска тырыша, шуңа күрә туй дип тә зурдан купмый. Әмма туй, асылда, барыбер әти-әни акчасына ясала.

Үткәннәр үткәндә калсын

Нәсел-нәсәбәсендә берәр проблемасы – шкафында скелеты булмаган кеше юктыр. Кемдер уйнаштан туган, кемнеңдер атасы йөргән, анасы эчкән, аерылышкан, кайнанасы белән ызгышып яшәгән... Туй – элеккеге шушы гөнаһлардан арыну, чистару, пакълану, үпкәрәнҗүләрне оныту вакыты да. Туйга әзерләнәбез. Кәләш: «Әнием килмәячәк», – ди. Кыз ислам диненә күчкәннән бирле – ике ел әнисе белән аралашмаган икән. Телефон номерын алып, үзем шалтыратам. «Кемнәрнеңдер кызлары бөтенләй әдәпсез юлда йөри, ә сезнеке алай түгел бит. Аның теләген хөрмәт итегез», – дим. Әнисе килде туйга, табында утырды, яшьләргә хәер-фатихасын бирде.

Бездә туй чыгымнарының төп өлеше мактануга, пафоска китә.

Яки менә кияүнең әтисе белән әнисе күптән аерылган. Әтиләре туйга яшь хатыны белән килмәкче. Әни кеше мондый чакта бар ихтыяр көчен җыя, баласы хакына ризалаша. Туйда әтисе белән яшь хатынга икесенә бергә сүз бирмәскә тырышабыз, гомумән, яшь хатыны турында әйтмибез. Кайчак егет: «Әти яңа хатыны белән бәхетле, ул апаны яратабыз, без риза, килсен», – ди. Кайчак, аерылганнан соң, ике як та тормыш корган була – икесе дә парлап килә.

Туй – яңа тормышка аяк басу вакыты. Хәзер барысы да башкача булачак. Һәм барысы да син теләгәнчә генә дә түгел. Туйда тамада, сиздермичә генә, яшьләрне шушы үзгәрешләргә әзерли. Туй җыр-биюсез, музыкасыз узса, интеллектуаль уеннар уздырам. Әйтик, тест ясыйм. Тормыш тәҗрибәсе, дини гыйлеме зур булган күркәм бер гаиләне чакырып, алардан имтихан алам. «Бөтен нәрсәдән дә күбрәк кемне яратасыз?» – дип сорыйм. Алар: «Беренчедән – Аллаһы Тәгаләне, икенчедән – пәйгамбәребезне, өченчедән – әти-әнине», – дип җавап бирәләр. Иремне, хатынымны үлеп яратам, дигән сүз әйтмиләр. Шәригатьчә шулай дөрес була. Берәүнең дә үз хатынын әнисеннән күбрәк яратырга хакы юк. Шулай ук беркем ирен үзен тудырган әнисеннән артыграк ярата алмый. Шуңа күрә кияү белән килен туйдан үзләренең ире яки хатыны өчен беренче урында түгел икәнен аңлап китәргә тиеш. Мәхәббәт, кайнар хисләр ярты елга, өч яки ун елга җитәргә мөмкин, аннары аны үзара хөрмәт алыштыра. Туйда кәләшкә: «Иреңнең әнисе бар – ул аны ярата. Син ireңнең үзеңне яратуын теләсәң, аның әнисен яратырга тиешсең», – дим. Кияүгә дә әйтәм: «Теща» дигән сүзне телеңә кертмә: яратасың икән, хатыныңны аның әнисе белән бергә яратырга тиеш буласың», – дим.

Туйга әзерлек вакытында ике нәсел үзара ярышырга теләгәнен сизсәм, алар белән саубуллашам. Туй: «Безнең як – 150, сезнеке 100 мең генә салды. Безнекен – киленгә, сезнекен кияүгә бирәбез», – дип тәмамлана икән, моның ахыры барыбер матур бетми... Мин, гадәт-

PRESSA.RU

тә, киленнән: «Без бу акчаны әти-әнигә тапшырабыз», – дип әйттерәм. Әти-әнинең алып калырга хакы бар, чөнки туйны күп очракта алар ясый.

«Ә мин болай телим!»

Кияүгә чыгу, ак күлмәктән туй түрендә утыру турында хыялланмаган кыз бала юктыр ул... Барысы да китапларда язганча булачак дип көтә ул: үзен бары тик принцесса образында күрә, принц – ак атта (ак лимузинда дип укы!) киләчәк, вакыйгалар патша сараенда барачак... Ә чынбарлыкта кияүнең әле фатиры да юк, туй да ашханәдә генә уза, лимузин исә чамасыз кыйммәт тора икән... Тамаданың бурычы – әнә шундый кәләшнең хыялларын бераз «сүндереп», сак кына аны җиргә төшерү. Алай гына түгел, туйга әзерлек барышында аңардан уңган, булган, сак хуҗабикә ясау, «Моны эшләмәсәк тә була, артык чыгымнар чыгармыйк әле», – дип, аның үз авызыннан әйттерү. Кәләш туйны үзе өчен дип уйлый. Чынлыкта, туй киленбикә өчен түгел, ә кунаклар өчен ясала. Алар бу мәҗлескә бүләк белән киләләр, шуңа күрә аларның күңелен күрергә кирәк. Табында йөз кунак утыра икән, кәләш анда йөз дә беренче кеше генә. Ул үзенең нәфесен бассын, тыя төшсен. Кунаклар разый калсын – аның иң беренче теләге шул булырга тиеш.

Халык өчен чыгымы аз булган, ә милләт өчен файдалы формат – никахлар әйләнеп кайтты.

Кайчак кәләш: «Европадагы кебек туй кирәк миңа», – дип сүз башлый. «Ярый, әмма шунысы да бар: Германиядә менә туйлар бик тыйнак, гади үтә, сезгә шундый кирәкме?» – дигәч, ул аптырап кала.

Авылдан килгән туганнарыннан оялган кәләшләр очрый. «Аларга сүз бирмәскә тырышыгыз», – дип алдан кисәтәләр мине. Килешмим! Туйда һәркем бертигез. Килгән кунакны кимсетергә ярамый. «Мәҗлестә авылдан кунаклар булуы – бу бит дәрәҗә. Димәк, тамырларың тирән!» – дим кәләшкә андый чакта.

Туй бармый...

Андый хәлләр дә була. Башкортстан татарлары, мишәрләр – дәртле халык, алар җырга да кушыла, уртага сикереп төшеп тә бии. Казаннар, Казан артлары – андый түгел, шуңа күрә аларда мәҗлесләр гел салкын башлана, җаннарын эретер өчен шактый тырышасың. Табиблар табында бик гади була белә, юктан да көләләр. Укытучылар – басынкы, аларны кузгату авыррак. Тик кузгатсаң, туктатырмын димә! Боларның барысына да алдан әзер буласың, туйны оештырганда ук кунакларның нинди
рәк булачагын белешәсең. Кемдер: «Безнекеләр артык күңелле кешеләр түгел инде», – дип кисәтә; икенчеләр: «Борчылмагыз, үзләре чыгып җырлаячак», – диләр.

250 кешелек иң зур туйны Самарада үткәрдем. Әмма табынга күпме кунак җыелуы тамада өчен алай ук мөһим түгел. Кеше күп булганда, котлауларны кыскартам, уеннарны мавыктыргычрак итәм, тәнәфесләрне башкачарак оештырам. Мөселманнарга туйны музыкасыз, җырсыз, биюсез дә үткәрәбез менә. Андый чакта авыллары тарихын өйрәнеп барам, күренекле кешеләрен искә төшерәм – алар арасына шулай итеп керәм. Татар туенда, гадәттә, бөтен нәрсәне хатын-кыз эшли: җырлый, бии, сүз әйтә, бүләкне тапшыра... Ә мөселман туенда – киресенчә. Хатын-кызлар, гомумән, аерым бүлмәдә утыра, без киленне хәтта күрмибез дә.

Күчтәнәч

Франциядә һәм Мәгъриб илләрендә «бонбоньерка» дигән әйбер бар. Гламур журналлар аша ул безгә дә килеп җитте инде – конфет яки башка берәр ризыкны матур итеп төреп, һәр кунакка таратып чыгалар. Мин конфет урынына сабын, Казан күренешле магнит яки китап бирергә тәкъдим итәм. Дини кешеләр туенда яшьләргә намаз тәртипләре, йолалар турында китаплар тараттырам: шул китапны укып, кемдер намаз укырга, һичьюгы берәр дога өйрәнсә, бу туйның савабы, бәрәкәте арта. Мәҗлестән соң «әйбәт булды» дип китү генә аз, аны бер елдан, аннан соң да искә алсыннар. Туйдан алып кайткан шул кечкенә бүләк исә аны хәтерләтеп торсын...

Һәр туй ахырында торт чыгаралар хәзер. Нинди генә тәмле булса да, күпләрнең алдында ул кагылмаган килеш кала. Ә нигә аны берәр савытка салып кунакларга биреп кенә җибәрмәскә? Бавырсак яки чәкчәк тә салсалар, тагын да әйбәт. Гомумән, туй күчтәнәч белән тәмамланса бик матур.

Катнаш туйлар

Хәзер калада һәр ике туйның берсе – катнаш дисәм дә, ялгышмам... Яшь парлар икесе дә татар булган очракта да, табынга бер авыз татарча белми торган кунаклар җыелырга мөмкин. Туйны Арчада гына саф татарча алып барган бар. Казан арты районнарында булгалый әле. Мәскәүдә, мәсәлән, туйлар гел русча бара дисәм дә була. Дөрес, аның каруы, анда гел татарча җырлыйлар. Кайчак туйны татарча алып барасың, әмма котлаучылар русча гына сөйли.

Һәр туй – үзенчә катлаулы. Менә әле әзерләнәбез: егетнең әнисе татар, әтисе рус, ул татарча белми, сөйләшми. Кияү дә татарча аңламый. Туганнар да безнеңчә сөйләшми. Кыз татарча белә, әти-әнисе дә үзебезчә сөйләшә, тик алар Үзбәкстанда яши, туйга килә алмый. Кияүнең әтисе бер фамилиядә, егет – икенчедә: аның үги икәнен мәҗлестәгеләргә сиздерергә ярамый... Ә тамада һәркемнең күңеленә ачкыч табарга, ярарга, үзен яраттырырга тиеш!



Язманы тулысынча сайтыбызның «Гореф-гадәт» сәхифәсендә укыгыз.



Гөлназ БӘДРЕТДИН

Башкорт дәүләт аграр университеты

Кияүдә түгел

Карьера: «БИЗНЕС Online» электрон газетасы журналисты.

Тормыш шигаре: «Үз-үзеңә ышансаң, кешеләр дә сиңа ышаныр!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Бәхетле хатын – кыз таба...



Уфадагы ике туганымның балалары туарга тора. Түбән Камада бер туганымның кызы туды. Казандагы ике якын дустым гаиләсе бу көннәрдә ишәергә тора. Бишесендә дә кыз бала! Кызлар күпләп тугач, тормышлар имин була, диләр. Бирсен Ходай! Милләт кызлары булып үссеннәр! Сеңлемнең кызы Сәйдә «р» хәрефен әйтергә өйрәнгән менә. Шатлыгыннан миңа шалтырата: «Апа, тыңла: татаррр, татаррр!» – ди. Балалар үзләренең кем икәнлеген белеп үсә – шунысы куандыра.



Заман белән бергә атлыйбыз!




Шаулап-гөрләп VII Бөтендөнья татар яшьләре форумы узды. Дөньяда нинди яңа форматтагы алымнар булса, форум эшендә барысы да кулланылды. «Face to face» (йөзгә-йөз) рәвешендә танышу дисеңме, Дөнья татар кафесы, Татар проектлары аллеясе, Акыл фабрикасы... Россиядә беренче тапкыр иң зур колачлы стратегик сессия уздырдык – ул безгә бер меңгә якын яңа проектлар тудырырга мөмкинлек бирде. Мондый сессияне беренче булып татар яшьләре уздыруы – искиткеч горурлык! «Печән базары» фестиваленең дә быел дүртенчесе узды. Бу проектыбыз да максатларына ирешеп килә!

Татар кызлары булдыра!

Җәйге Олимпия уеннары тәмам. Татарстаннар зур уңышка ирешмәсә дә, читтә яшәүче татар спортчылары моны «төзәтте». Алия Мостафина алтын, көмеш һәм бронза медаль, Казакъстан өчен чыгыш ясаган Гүзәл Манюрова көмеш медаль, Украина өчен чыгыш ясаган Ганна Ризатдинова нәфис гимнастикада бронза медаль яулады. Кырымда туып-үскән кызның бабасы Наил – Казан татары, Ганна бу турыда һәрдаим әйтә. Чиләбе кызы Эльвина Кәримова да суда туплы уйнау командасында өченче урын алды. Тагын бер татар кызы Гөлназ Гобәйдуллина медаль алмаса да, йөзү буенча Олимпия рекордын куйды. Төркия өчен чыгыш ясаган Нур Татарны да татар кызы, диләр.

сөендерде    көендерде

сөендерде    көендерде

сөендерде    көендерде

Җәйне күрми калдым...

Ике ел элек ипотекага фатир алган идем. Кризис көчәя барган саен, аны түләү авырлаша. Кредитымны түлисе бар дип, яңа эшкә күчтем – ялсыз эшләргә туры килде менә: җәйне Казанда уздырырга мәҗбүр булдым. Әбибабайлар мәрхүм булганнан соң, авылларга да юллар ябылды. Балачакның иң матур, иң бәхетле көннәре алар янында – авылда узган.
Вакыт узган саен, шул көннәр күбрәк сагындыра. Мәтрүшкәне дә, хәтта, хәзер үзебез кайтып җыймыйбыз, дуслар китереп бирә.

Өмет – әти-әниләрнең үзаңында

Россиянең яңа мәгариф министры үтә дә дини, православ диненә бик бирелгән кеше, диләр. Моңа кадәр Татарстан мәктәпләрендә православ мәдәнияте укытылмады: безнең республика мондый мәҗбүрияттән сакланып килгән бердәнбер төбәк Россиядә. Безнең балаларга «Дини мәдәниятләр һәм дөньяви әхлак нигезләре» дәресе керде. Татарстан митрополиты, үз вазыйфасына керешкәч үк, Татарстанның бу яктан проблемалы төбәк икәнен әйтте. Яңа мәгариф министры, православ мәдәниятен мәҗбүриләп, бөтен мәктәпләрдә, шул исәптән Татарстанда да кертә башламасмы – шунысы борчу тудыра.

Китәләр...

Узган айда танышларым арасыннан бер яшь татар гаиләсе чит илгә чыгып китте. Шунда яшәргә, бөтенләйгә... Күңелем сыкрап калды, нәрсәнедер югалттык сыман. Бер яки ике очрак кына булса, бер хәл иде – чит илгә чыгып киткән татар яшьләренең саны елдан-ел арта. Укымышлы, зыялы яшьләребез китә... Димәк ки, алдынгы яшьләр, Татарстанга караганда, чит илдә яшәүне кулайрак күрә. Мондагы тормышны ямьләндерү, яхшы якка үзгәртү өчен тырышырга кирәк тә бит... Анысы да үз кулыбызда.

PRESSA.RU




ВИСБАДЕН



МОНДА ПУШКИННЫҢ КЫЗЫ НАТАЛИ (ГРАФИНЯ МЕРЕНБЕРГ) ГОМЕР ИТКӘН, МОНДА УРАМДАГЫ ҺӘР АГАЧКА НОМЕР СУГЫЛГАН, ҺӘР ВИЛЛА АРХИТЕКТУРА ҺӘЙКӘЛЕ САНАЛА...

280 мең кеше яшәгән кечкенә генә шәһәр ул Висбаден. Франкфурт-Майне аэропортына туры рейслар ачылгач, Казанга шактый якынайды ул хәзер.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА





Алда ике көн ял булганга күрә беркая да ашыкмыймы соң бу Висбаден халкы? Урамдагы барлык кафелар, рестораннар шыгрым тулы – буш өстәл табам димә. Тирә-юньдә – берьюлы бик күп кеше сөйләшкәндә була торган гүләү. Тыныч гүләү. («Ашыгыч ярдәм», «Янгын сүндерү» машиналарының безне сискәндергән тавышына алар игътибар да итми. Гел шулай бик каты кычкыртып узганга күп йөриләр кебек тоелдымы соң?) Висбаден шәһәрен «немецларның Ниццасы» дип атыйлар. Мондагы кадәр байлар Германиянең бер каласында да юк. Алар яшәгән виллаларның матурлыгы, затлылыгы! Әйе, тормыш матур, ул – бер генә, ашыгып, кабаланып нигә ямен җибәрергә? (Хәер, халык шимбә кичкә таба бер ашыгып, ыгы-зыгы килеп ала икән. Якшәмбе көнне аларда кибетләр эшләми. Хәтта ипи кибете дә! (Безнең: «Ничек инде эшләми?» – дигән соравыбызга сорау белән җавап бирделәр: «Ә сатучылар ял итәргә тиеш түгелме? Профсоюзлар беркайчан да аларны эшләтү белән килешмәячәк!») Шуңа күрә шимбә көнне кичке якта һәркем: «Берәр нәрсәне алырга онытмадыммы? Ялларда аптырамаммы?» – дип борчылырга керешә, кибет киштәсендә ни күрә – кирәксә дә, кирәкмәсә дә шуны сатып ала башлый. Әйе, шимбә – немецлар өчен кечкенә ахыр заман!)

Сугыш вакытында Висбаден өстенә бомбалар яумаган – америкалылар яраткан бу шәһәрне.

Висбаден гомер-гомергә туристлар шәһәре саналган. Гади туристлар түгел – аристократлар! Мондагы казино дөньяның иң билгеле һәм иң бай кешеләре өчен очрашу урыны булган. Кайчандыр бер уен өстәле артына Достоевский һәм Вагнер утырган монда. Комарлы уеннар белән Достоевский нәкъ шушында мавыга.

«Нассауэр Хоф» отелендә Федор Михайлович торган бүлмәнең тәрәзләре Висбаденның курзалына карый. Юлны гына атлап чыгасы да, казино ишекләрен ачасы... Беренче тапкыр ул бәхетен 1862 елда сыный. Анысында югалту аның кадәр зур булмый әле. Икенче тапкыр аяклары аны казинога 1863 елның җәй ахырында алып керә. Язучының Парижга, сөяркәсе Апполинария Суслова янына барышы. Күп акча отуның серен дә ачкан күк була да бит... Юк шул! Өстәвенә, бер югалтуга икенчесе кушылып китә: Парижда Суслова аны: «Син бик соң килдең. Мин инде башка берәүне яратам», – дип каршы ала... Ә 1865 елда Достоевский бу казинода үзенең бөтен байлыгын калдыра! Бар ашаганы ипи белән судан торган көннәр башлана. «Отельдәгеләр ач икәнемне белмәсеннәр өчен көндез чыгып йөреп кайткалыйм», дип яза ул хатында, Висбаденны «каһәр төшкән кала», дип атый, «күземне ачып карыйсым да килми», ди. Атаклы «Игрок» романын шул вакытта яза ул. 26 көн эчендә! Китап өчен алган акча бурычларны түләргә, Россиягә кайтырга җитә. (Романны тәмамлаганчы, язучы стенографист кызга гашыйк булырга өлгерә. Яшь аермалары бик зур булса да, Анна белән кушылып, гомер азагына чаклы бергә яшиләр алар. «Рулеткага башка якын да килмәм!» – дип, Достоевский шушы Анна Сниткинага вәгъдә бирә инде. Тормышта гел шулай: бәхетсезлектән бәхеткә дә күп вакыт бер генә адым.)

Әмма Висбаден дөньяга атаклы казиносы белән түгел, термаль чыганаклары белән таныла. Аларның шифасы инде бу җирләрне ачкан борынгы римлыларга ук билгеле була. Рус дворяннары монда килеп айлар буе ял итәргә яраткан. Романовлар, русның бөек рәссамы Явленский, әдипләр Тургенев, Гоголь, композитор

PRESSA.RU



Чайковский… Менә ни өчен Висбаденны «рус эзләрен иң күп саклаган немец шәһәре» дип атыйлар!

Сүз уңаеннан: казиноның ишекләре бүген дә ачык. Анда рулетка да, блек-джек та, покер да уйныйлар, төрле модельдәге ике йөзләп уен автоматы да үзенә чакырып тора диделәр. Билеттан баш тарттык – бу безнең дөнья түгел… Ә менә термаль чыганакның никадәр кайнар икәнен тоеп карый алдык! 67 градус! Кул пешә! Бассейнга аны суытып тутыралар, әмма бу суда 20 минуттан артык ятарга ярамый – аннан ул файдадан бигрәк зыянга әйләнә.

Курзал янәшәсендә Достоевскийга бюст куелган. Язучыны хәтерлиләр!

* * *

Германия табибларын могҗиза тудыручыларга тиңлиләр. Ярдәм эзләп алар янына чыгып китүдән Ходай үзе сакласын, әлбәттә… Әмма «сакланганны саклармын» дигән сүз дә бар бит. Эшлекле сәфәргә барган яки ял иткән җирдән сәламәтлегеңне тикшертеп кайту мөмкинме икән биредә?

– Бик мөмкин! – ди доктор Виктор Буяновский. – Диагностика өчен бер көн җитә: йөрәк, үпкә, корсак куышлыгын, баш миен, кан тамырларын, калкансыман бизне, канны тикшерергә, гастроскопия ясарга. Алдан ук әйтеп куям: бәяләр Мәскәү клиникаларыннан югары түгел.

«Clinical Solutions» компаниясенең идарәче директоры Виктор Буяновский инде ун елдан артык чит ил пациентларын Германия клиникаларына дәваланырга һәм тикшеренергә килүне оештыру белән шөгыльләнә. Шул вакыт эчендә компания 4 мең кешегә ярдәм иткән. «Сезне бай һәм бәхетле итү кулыбыздан килми, әмма сәламәт булсагыз, моңа үзегез ирешәчәксез!» – диләр алар.

Без бүген Висбадендагы «DKD Helios» клиникасы белән танышабыз. Шаккату, мөгаен, аның ишеген ачып керүгә башланадыр: зур холл, кибетләр, кафе, чәчтарашханә, банкомат… Отельгә эләктем дип уйларсың! Бер мең урынга исәпләнгән күп профильле клиника бу. Монда күргәннәрнең барысын сөйләп чыгу мөмкин түгел, тик шулай да…

Профессор Маркус Кнуф балалар һәм яшүсмерләр үзәген җитәкли. Күп сөйләшми ул, әмма шушы сабыйларны аталарча яратуы, алар өчен борчылуы, сөенүе – барысы да йөзендә чагыла. Сүз аларга күчтеме – балкып китә! Докторның иң зур горурлыгы – яңа туган балалар реанимациясе бүлеге. Ел саен авырлыгы кило ярымнан азрак булган 70-80 баланы саклап калалар икән. Әти-әниләр палатасы да шунда ук – теләгән чакта сабыйлары янына керә, шушында куна алалар.

– Ә хәзер сезгә тагын бер могҗиза күрсәтәм! – профессорның йөзе кабат балкый. – Менә бу егет 340 граммлы булып туды. Ул инде хәзер үзе сулый!

340 грамм! Булмас дисезме?! Үз күзләрем белән күрмәсәм мин дә ышанмас идем… Уч төбенә сыеп бетәрлек ул нәнигә кигезерлек кечкенә памперс та тапканнар хәтта! Кювезларның башкаларында үсеп ятучы 900-1000 граммлы балалар аның янында баһадир булып күренде.

22 атнадан туарга ашыккан бармак башы кадәр малай күзләрен ачып, кулларын селкетеп, безне озатып калды. Реанимация бүлегеннән чыгабыз: гаҗәп – урамда нинди кием, нинди аяк киеме белән йөрсәк – шулай кердек без анда.

Доктор Габриэль Хун – диагностика клиникасында гинекология һәм гинекологик онкология бүлеген җитәкли.

– Бөтендөнья сәламәтлекне саклау оешмасы мәгълүматлары буенча хатын-кызлар арасында иң таралган авыру – күкрәктәге яман шеш, – ди ул. – Чирне мөмкин кадәр иртәрәк ачыклау максатыннан Германиядә күп эшләнә – диагностика шуңа корылган. Бездә 30 яшьтән узган һәр хатын-кыз елга бер тапкыр күкрәгенә УЗИ ясатырга тиеш. Гадәттә, ясаталар да. Маммографиягә караганда, УЗИда шеш яхшырак күренә. Әгәр күкрәктә ниндидер үзгәрешләр барлыгы ачыклана икән, шунда ук пункция ясала, аннан, кирәк икән инде – химия терапиясе. Операция вакытында, гадәттә, күкрәкне тулысынча түгел, аның шеш булган өлешен генә алабыз. Фәнни яктан расланды инде – күкрәкне бөтенләй алып ташлау терелү-терелмәүдә бернинди роль уйнамый. Күкрәкне саклап калу исә хатын-кыз өчен психологик яктан да, эстетик яктан да бик мөһим. Яман шеш диагнозы куелган хатын-кыз иң элек онкопсихолог белән аралаша. Психолог ярдәмен авыруның туганнары да ала: бу хәбәрдән беренче мәлдә алар да югалып кала бит…

Диагностика клиникасына мөрәҗәгать иткән һәркемгә аерым табиб билгеләнә дип сөйләделәр:

тикшеренү планын ул билгели, соңгы сүзне дә ул әйтә. Бер көнлек бу тикшеренү программасы – Check-Ur – бөтен дөньяга билгеле. Аны узарга Германиянең барлык почмакларыннан гына түгел, Европаның барча илләреннән, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Россия, Украина, Америка, хәтта Кытайдан киләләр! Япониянең исә клиникада үз вәкиле бар. Теләге булганнарга виза алырга да, кунакханәгә урнашырга да булышалар, клиника белән аэропорт арасындагы трансферны да оештыралар, тәрҗемәче дә табалар. (Хәтта медицина самолеты белән авыруны барып алып та кайталар! «Андый очраклар да бар, – дип сөйли Виктор. – Берничә ел элек, мәсәлән, Мәскәүдән шалтыраттылар: бала җитлекмичә туган, хәле авыр. Очкычта алып кайттык. 900 граммлы иде. Балалар реанимациясе бүлегендә 3 айдан артык ятты ул. Быелтыр алар белән Мәскәүдә очраштым: сау-сәламәт, шундый шук бала»)

Кемгәдер үзенә куелган диагноз буенча тагын бер фикер ишетү бик мөһим: интернет аша җибәрелгән анализлар буенча клиника профессорлары үз сүзен әйтә, дәвалау буенча тәкъдимнәрен юллый. Өстәмә тикшеренүләр кирәк дип тапкан очракта – клиникага чакыралар.

Ә шулай да бездә һәм менә аларда медицина хезмәте күрсәтүнең аермасы нәрсәдә? Заманча технологияләр белән безнең хастаханәләр дә мактана ала бит хәзер. Бу сорауны Краснодар өлкәсендә яшәүче туганын Висбаденга дәваланырга алып килгән абзыйга да бирдек. Без бу очракта көчсез дип, 32 яшьлек иргә үзләрендә ярдәм күрсәтүдән баш тартканнар. Яман шеш... «DKD Helios» клиникасында аңа 8 сәгать дәвамында бик катлаулы операция ясаганнар, ул инде аякка баскан.

– Монда һәркем – шәфкать туташлары, докторлар, реаниматорлар үз эшен белә һәм җиренә җиткереп, иң югары дәрәҗәдә башкара. Бөтен сер – шунда, – диде әңгәмәдәшебез.

– Юк, безнең докторлар да Аллаһы Тәгалә түгел, – дип сүзгә кушыла Виктор Буяновский. – Өмет булмаган очракта өмет уятмыйбыз... Безнең сайтка көн саен 70-80 кеше керә. Менә бу еллар эчендә 9 «запрос» булды. Миңа әле аларны өйрәнергә, белгечләр белән киңәшергә кирәк. Ярдәм итеп буламы, ярдәм итәргә кирәкме? 24 яшьлек бер кыз менә күзлектән котылырга тели, килешми, ди. Аның проблемасын хәл итү өчен пычак астына яту мәҗбүри дә түгел. Күзнең мөгез катлавы нәзек булса, аңа лазер белән кагылмавың хәерлерәк.

Ай саен керемнәренең саллы өлешен үзенә алып барган медицина страховкасы (студентлар өчен, мәсәлән, бер айга ул – 50 евро, 1500 евро алып эшләүче хезмәткәр өчен – 150 евро, хезмәт хакы 5000 евро булган менеджер өчен – 500 евро) сәламәт яшәү рәвеше яклыларны, исәнлеге турында даими кайгыртучыларны хуплый анда. Сирәгрәк авырсаң – страховканы түләүдә дә ташламаларга ия буласың. «Әмма кирәк икән, кереме аз булганнарга, эшсез сукбайларга да медицина ярдәме, һичшиксез, күрсәтелә», – дип кат-кат әйттеләр. Кеше кадерен бар нәрсәдән өстен куюлары һәр гамәлләрендә чагыла. Виктор сөйли:

– Нюренбергта хирург булып эшләгән чагым. Берсендә клиникадан төн уртасында шалтыраттылар. Бик тиз барып җитәргә кирәк иде... Шәһәрдә сәгатенә 50 километрдан артык тизлек белән йөрергә ярамый. Ә минем һәр минутым исәптә! Өлгерергә кирәк, тик ничек? Өйдән чыгышлый полициягә шалтыраттым: хәлне аңлаттым. Машинамның номерын, кайсы урамнан кая баруымны гына сорадылар... Берничә минуттан алдымда полиция машинасы пәйда булды. Шәһәр урамнары буйлап сәгатенә 150 чакрым тизлек белән очтык без! Клиникага килеп җиткәч, машина тәрәзәсен төшереп кул гына болгады да, полицейский китеп барды...

Немецлар бер елга табибларга уртача 15 (!) тапкыр мөрәҗәгать итә икән.


* * *

Висбаденнан Рейн елгасы үзәненә – 20 чакрым. Шулкадәр җир узып килеп тә аны ничек күрми китәсең?

Әгәр кайчан да булса безгә берәр чит планетадан килсәләр һәм туп-туры шушы Рейн үзәненә төшсәләр, алар: «Җирдә кешеләр виноград кына ашап тора икән», – дип уйлар, мөгаен. Уңда, сулда, артта, алда, тау битендә, тау итәгендә – бөтен җирдә йөзем куагы! Атаклы немец рислингының туган төбәге бу. Рислинг шәрабына шикәр бөтенләй кушмыйлар – куагында балланган йөземнән генә ясыйлар. Ә йөземдә шикәрнең күпме булуы аны кайчан, ничек җыюга бәйле. Иң баллысы – җылылык 7 градус торган төнне җыелганы икән. Алты да түгел, сигез дә – нәкъ менә җиде! Һәр елны мондый төннәр булмый да икән әле.

...Виноград үстерү белән шөгыльләнүче Гросссларның җәйге террасасында утырабыз. Янәшәдә – йөзем бакчасы, яшел тәлгәшләргә бирелгән үрелсәң дә кул җитәрлек. Гросссларның әти-әниләре дә, әби-бабалары да йөзем үстергән, шәраб ясаган. «11 гектар мәйдандагы 6-7 мең виноград куагын мин дә улыма тапшырырмын дип өметләнәм, – ди хуҗа. – Бу эш аңа ошый, инде бүген үк кул арасына керә. Күрәсез, кафе да тотабыз. Унсигезәр сәгать аяк өстендә без, алай да өлгермибез. Уңышны җыярга Польшадан килгән эшчеләр булыша. Барысы да кул белән эшләнә. Рислингның 25 сортын ясыйбыз. Виноград үстерүче ир-атка башлы-күзле булу авыррак хәзер – хатын-кызның авылда бик каласы килми. Минем ул яктан бәхетем булды...»

Казан–Висбаден–Казан.



Язманы тулысынча сайтыбызда – «Мин ачкан дөнья» сәхифәсендә укый аласыз.

PRESSA.RU

16+

БЕЗНЕҢ КӘЕФ ХАТЫН-КЫЗГА БӘЙЛЕ...



Зиннур ХӨСНИЯР – язучы;
өйләнгән;
гаилә стажы – 30 ел;
ике бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Буй-сынына, йөз-кыяфәтенә, әлбәттә. Холкының нинди икәнлеген барыбер шундук белеп булмый. Шулай да үзем яшьтән (яшүсмер чактан хәтта!) кара күзле кызларны ошата идем. Кемгә нәрсә, кәҗәгә – кәбестә дигәндәй, кемнең күңеленә кем ошый.

Ничәнче курста укыган чак булгандыр, соңгы лекциядән соң гардеробта бер кызны күреп, «җуләрләнә» яздым. Гардеробны ике-өч мәртәбә урадым, ул анда кем беләндер сөйләшеп тора иде. Сүз куша алмадым. Моңа кадәр булган кыюлык кая киткәндер?

Шулай кайтып киттем тулай торакка. Их, бу авыллык дип уйлым хәзер, шул чакта сүз куша алмаганыма үкенеп. Язмыш шаяртуы диген – теге кыз нәкъ безнең факультетта укый булып чыкты, алай гына да түгел, нәкъ мин укыган бүлекнең беренче курсына кергән! Ә монысы инде язмышның шаяртуы гына түгел, чын-чынлап бүләге иде! «Кызым» мин яшәгән тулай торакта яши булып чыкты. Тагын «язмыш» дим инде, шулай димичә булмый, чөнки, әлеге «мәхәббәт»нең бүлмәсенә барып, беркөнне кинога чакырган идем: «Һай, егетем бар шул инде!» – диде. Монысы инде язмышның маңгайга күсәк белән оруы иде!.. Үкенечле «гыйшык» диген син. Мин ул кызны әле дә еш искә төшерәм... Хәер, инде төгәл генә әйтә алмыйм: анымы, әллә шул чакта кичергән шашкын хисләрне, ягъни бер күрүдә гашыйк булган минутларны микән?..

Хәер, «үкенечле» дигән булдым да... Һәр кешенең була ул андый «гыйшкы», ир-атның гына түгел, хатын-кызның да. Күрәсең, дөнья шулай яратылгандыр; гадәттә, өйдә савыт-саба шалтыраганда искә төшә алар: «Их, теге чакта тегеңә өйләнгән яки кияүгә чыккан булсам соң?!» – дип кем генә авыр суламый икән?..

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Бар ягын да гафу итәргә була! Чөнки ул хатын-кыз! Шуның белән барысы да әйтелгән. Бигрәк тә – тиз үпкәләвен. Аларның күңеле сабый бала кебек: конфет бирмәсәң дә – үпкәли, уенчыгын алсаң да – үпкәли. Шуңа күрә хатын-кыз алдыннан «конфетны өзмәскә», «уенчыгына кагылмаска» кирәктер. Хатын-кызга да бер киңәшем бар: кызу чакта кул астына эләкмәскә!

3 Ә нәрсә өчен Сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәт өчен генә. Хәер, тагын бер сыйфат бар икән, ул – ялган сөйләү. Хатын-кыз сине бер сәгать элек кенә үпкән матур авызлары белән күрәләтә алдый икән, күңел тиз кайта инде андый алиһәдән.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм аңа өйдә комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Өйдә комфорт тудыра алса, шул илһамландыручы алиһә була торгандыр инде. Чүп оясында нинди илһам килсен! Хәер, яшь чакта беленми торгандыр инде ул, олыгая барганда өйдәге җылылык ир-атка күбрәк кирәк. Хәзер дөнья бигрәк тә болгавыр бит. Иң аянычлысы – тормышта кешеләр арасында ихласлык бетеп килә, кешелеклелек дигән нәрсә «мода»да түгел хәзер. Кыргыйлык... Тышкы дөньядан туеп, арып-алҗып өеңә кайтасың, җылылык, бер тамчы рәхәтлек, тынычлык эзләп кайтасың хуҗабикәң янына.

Гаилә нигә таркала? Беләсезме, гаилә ул үзе бер дәүләт! Ә дәүләттә яшәргә җайлы, рәхәт булырга тиеш. Әгәр ир-ат яки хатын-кыз ул «дәүләттә» үзенә рәхәт, сөю, наз тапмый икән, таркалачак инде ул. Ләкин әлеге дәүләтнең тоткасы – хатын-кыз. Аның назы, җылылыгы яшәтә аны...

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Ничек кенә әле! Хатын-кызлар арасында дусларым күп минем. Әлбәттә, барысы да чак кына миннән өлкәнрәк. Хатынга килгәндә исә аннан да якынрак дус юктыр инде ул. Һәм дошман кайчагында...

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– Гади, гадәти, пафоссыз булды бугай... Хәер, безнең арада барысы да аңлашыла иде булса кирәк, атсыз бармаклар гына балдаксыз иде. Институтның дүртенче курсыннан соң «Ялкын» журналында эшләдем, укый-укый. Аннан соң, язучы кешегә тормыш күрү кирәк дип, үзем теләп – гариза язып, армиягә киттем! Вәт тиле диген! Югары белемле никрут буларак, әүвәл Әфганга җибәрделәр, тик аңа кадәр Кушкада ике ай «сбор»да булырга кирәк иде. Әфганга барып җитеп булмады, Казаннан озата барган прапорщик: «Дәүләт сине биш ел бушка укыткан, әйдә, башта шуны түлә!» – дип, ничектер җаен туры китереп, Казан военкоматына кире алып кайтты. Анда бер атна ятканнан соң, Украинага – разведмәктәпкә эләктем. Хезмәт коточкыч авыр булды. Йөреп киткән кызыма, хәзерге хатыныма – зарланып хатлар язганмын, күрәсең, ул шул җәһәннәм тишегенә чаклы килеп йөрде. Аннан соң Белоруссиягә күчерделәр, тагын разведбатка эләктем. Әфганга барсаң, кайткач, фатир бирәселәр иде, берничә егет, тагын шунда җибәрүләрен сорап, гариза яздык. Бу хакта йөргән кызга хәбәр иттем. Ни ара хатны алган да, ни ара килеп җиткән: бармаска үгетләде, елый-елый сорады. Гаризаны кире алдым. Иптәшләрем китте. Ике ай Кушка шәһәрендә уен-укуда булганнан соң Әфганстанга кергәннәр, шунда беренче сугышта ук һәлак булдылар дигән хәбәрләре килде. Менә шул, язмыш диген... Сөйгән кыз мине әлеге һәлакәттән алып калды, ничек аңа өйләнмисең, ди, инде?!

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Ай-һай, бик авыр тормыш булачак бу. Бигрәк тә ир-ат өчен. Ошбу очракта ул «хуҗа дилбегәсе»н югалта. Алтыннан коелган хатын булса да, барыбер кайчан да булса исенә төшерәчәк, «мин күбрәк табам», дип төрттерәчәк. Аннан соң, гафу итегез, хатынын көн-төн бил бөгәргә мәҗбүр иткән, мал табар көнгә калдырган ир-ат нинди ир-ат инде ул – аңламыйм.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Әйбәт карыйм. Димәк, «химик реакциясе» башланган, савыты ташырга тора. Нишләсен – чыгарып түгә алмый бит инде ул аны. Әйтсен, белдерсен. Ир-ат та аны ошатса, шундук җавап бирәчәк.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Мал табу, тормышта югалып калмау. Алар күп. Тагын өстәп шуны әйтергә була: мәсәлән, тәрәк булу, хатынына карата игътибарлы булу...

10 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Хатын мактаса, күңел була инде. Бу иң көчле тәэсир, минемчә... Акылга, ихласлыкка һәм кешелеклелеккә игътибар итсәләр, тагын да әйбәтрәк булыр иде.

11 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта.

– Чибәр хатын-кызга гашыйк булучылар барыбер күбрәк. Ләкин мин гел бер нәрсәгә игътибар итәм, хатын-кыз җанына Ходай тарафыннан итагатьлелек, пакьлек хисләре күбрәк салынган була. Югыйсә үзенә кызыгып караган, «уҗымга» чыгып керергә тәкъдим ясаган ир-ат белән рәхәтләнеп аралаша ала бит инде – йозак салынмаган, чуртым да белмәячәк. Юк, хатын-кыз күңелендә һәрвакыт «әхлакый карантин» бар, Ходай Тәгалә аларның әхлак бизмәненә герләрне күп итеп салган.

12 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар сезнеңчә бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Бөтен мәсьәлә ике җенес анатомиясенең биологик төзелешендә, тагын да төгәлрәге – баш миләрендә. Хатын-кызны «логикасы» булмау хатын-кыз итә. Ир-атны исә мантыйк ир-ат итәдер шикелле. Алдан сызып куелган, шома юлдан бару адәм баласына кызык түгел. Ир-ат, гадәттә, шундый юлны сайларга ярата. Ә хатын-кыз күбрәк бүгенге дөнья беләнрәк яши.

13 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Бу сорауга «Көмеш чыбыркы» дип аталган яңа романнан бер өзек белән җавап бирү мәслихәт булыр: «Бүген кәеф эткә дә ташламаслык. Бар нәрсә дә кәефтән тора шул. Ә ул, гадәттә, турыдан-туры хатын-кыз белән бәйләнгән була...


Хатын белән күңелдән генә «әйткәләшү» озакка бармады, кул селтәдем дә урамга чыгып киттем. Дөньяда иң мәгънәсез, иң кирәксез һәм файдасыз шөгыль – кара-каршы басып, хатын-кыз белән әрепләшү! Сүзләрең көмеш кенә түгел, алтын булса да, җиңә алмыйсың син аны андый чакта! Бер сүзеңә мең җавап ишетәчәксең һәм һәрвакыт «аста» калып, ахыр чиктә җиңелүдән барыбер тотлыга башлаячаксың!..»

14 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– У-у-уууу! Бу иң үзәккә үткән нәрсә! Каядыр, мәсәлән, сәгать алтыга барасы булса, вакытны берәр сәгатькә «алга күчереп» бишкә, дип хәйләлим. Өлгерәбез...

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?

– Әнә дә бүләк, дөя дә бүләк диләрме әле? Ләкин мин күбрәк үзем алырга тырышам. Моның сәбәпләре күп, шуларның иң беренчесе хатын-кыз белән бергә (аңа тагылып) кибеттә йөрүне яратмау. У-у-уу, бу ир-атка, мөгаен, иң зур җәзадыр! Әгәр хатын иреннән нинди булса үчен алырга уйлый икән, үзе белән кибеткә яки базарга ияртеп чыксын! Шул көнне ул максатына ирешәчәк!..



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU



«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА алып бара.

«Аш-су» рубрикасының яңа кунагы – яшь җырчы Азат АБИТОВ. Ул – Чуашстанның Шыгырдан авылы егете. Әти-әнисе музыкантлар. «Үземне белә-белгәннән бирле җырлыйм», – ди ул. «Урмай моңы», «Ягымлы яз-2012», «Татар моңы-2012», 2015 елда Рәшит Ваһапов исемендәге фестиваль... Иҗат биографиясе шулай башлана. Бүген ул Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының 2 нче курсында, Венера Ганиева классында укый. Мәктәпне тәмамлаганнан бирле үзбаш яшәгән егет аш-су тирәсендә дә тәҗрибәле. Бүген безгә тәкъдим иткән ашны ул Кавказ егетләреннән өйрәнгән. Нәкъ менә көзге муллыкта әзерли торган аш ул!



КАВКАЗ АШЫ







Кирәк:

- 1 кг чамасы сөякле ит;
- 1 кишер;
- 2 баш суган;
- 2 кызыл помидор;
- 2 бадымҗан (баклажан);
- 2 баллы борыч;
- 2 чәй кашыгы аджика;
- үсемлек мае;
- тәменчә тоз-борыч.

Әзерләнеше:

■ итне сөягеннән юнып алабыз. Шушы сөяктән 2-2,5 л шулпа кайнатабыз. Ә юнып алган итне вак шакмаклап турап, үсемлек мае салынган табада кыздырабыз. Шунда ук 1 чәй кашыгы аджиканы да кушабыз. Ит бераз кызгач, утны киметеп, 1 сәгать томалап пешерәбез. Ит янына шакмаклап туралган кишер салабыз.

■ Помидорларның өске элпәсен телеп җибәреп, кайнар суга батырабыз. 3 минуттан аларны судан алып (калын элпәле помидорларны бераз озаграк тотарга да мөмкин), элпәсен салдырабыз да, шакмаклап турап, аны да табага «озатабыз». Аның соңында туралган суганны салабыз.



■ Бадымҗаннарны юып, шулай ук шакмаклап турыйбыз. Яшь бадымҗаннарның орлыгын аласы юк, әгәр дә орлыгы өлгергән булса, алардан арындырсаң яхшы. Табага бер-бер артлы башта туралган бадымҗан, аннары туралган борыч салабыз да, 10 минут чамасы кабат томалап торабыз.

■ Кәстрүлдәге шулпаны сөзеп, аңа эрерәк итеп туралган бәрәңге һәм бер бал кашыгы аджика салабыз. Бәрәңге пешкәч, табадагы яшелчәләрне өстибез, тәменчә тоз сибәбез.

■ Тәлинкәләргә бүленгән ашны, туралган петрушка белән бизәп, табынга бирәбез. Ашларыгыз тәмле булсын!

КЫШКА ӘЗЕРЛИБЕЗ



Кышка әзерләп кую өчен бадымҗаннардан гади генә ике рецепт тәкъдим итәбез. Күңелегезгә ошаганын ясап карагыз әле.

«КАЙНАНА ТЕЛЕ»

Кирәк:

- 2 кг кызыл помидор;
- 2 данә зәһәр борыч;
- 2 кг бадымҗан;
- 0,5 кг баллы борыч;
- ярты стакан аш серкәсе (200 мл);
- 12 тырнак сарымсак;
- 2 аш кашыгы тоз;
- 1 стакан шикәр комы.

Эш барышы:

помидор белән борычны (баллысын да, зәһәрен дә) иттарткычтан чыгарабыз. Аңа тоз, шикәр, комы, аш серкәсе кушып, 20-30 минут кайнатабыз.
Бадымҗаннарны юка телемнәргә турыйбыз да помидорлар янына салабыз. Ара-тирә болгаткалап, тагын 15-20 минут пешерәбез. Уттан алыр алдыннан гына вак угычтан уылган сарымсак кушабыз.
Әзер салатны кайнар килеш стерильләштерелгән банкаларга тутырып, калай капкач белән томалыйбыз.

МУЛЬТИВАРКАДА ПЕШКӘН БАДЫМҖАН ИКРАСЫ

Кирәк:

- 3 данә бадымҗан;
- 0,5 кг помидор;
- 2 данә кишер;
- 3 баш суган;
- 3 данә баллы борыч;
- 3 аш кашыгы үсемлек мае;
- 12 тырнак сарымсак;
- тәменчә тоз.

Эш барышы:

Бадымҗаннарның кабыгын әрчеп, шакмаклап турыйбыз да, ярты сәгатькә тозлы салкын суга салып торабыз. Судан алып бераз кипшертелгән бадымҗаннарны үсемлек мае тамызылган мультиварка казанына салып, «Тушение» режимында 15 минут пешерәбез (тулаем сәгать ярым кирәк булачак). 15 минуттан соң ярым боҗралап туралган суган һәм эре угычтан уылган кишер өстибез. Тагын 15 минуттан ваклап туралган помидорларны салабыз. Алары да 15 минут пешкәч, шакмаклап туралган борыч кушабыз. Пешеп җитәргә 10 минут кала, вакланган сарымсак өстибез, тәменчә тоз сибәбез. Теләсәгез, 1 аш кашыгы аш серкәсе сала аласыз. Гәрчә, серкә салмасаң да бик яхшы саклана ул.

PRESSA.RU



ҖӨЙСЕЗ КАРДИГАН

Мондый кардиган тегәргә күптән кызыга идек. Ниһаять, ярашлы тукымасы да, оста тегүчесе дә табылды. Өстәвенә, көннәр дә суытып җибәрде, инде җылы киемсез булмый хәзер. Кулына энә тотып карамаган кеше дә булдырып чыга алган бу кардиганны тегәргә безне Гөлназ ГЫЙБАДУЛЛИНА өйрәтә. Гөлназ кебек тегүчеләр хакында халыкта бик матур сүз бар: «Коя да куя», диләр. Яшьтәшләре курчак белән уйнаганда, ул әнисенең тегү машинасы белән уйнаган. «Әни күрмәгәндә аның матур күлмәкләрен бозып, үземә берәр нәрсә тегә торган идем», – ди ул. Менә бу кардиганны да әңгәмә барышында ук, «ә» дигәнче текте дә куйды. Көзге гардеробыгызны яңартырга теләсәгез, бу мастер-класс нәкъ сезнең өчен.




Мастер-классны Гөлназ ГЫЙБАДУЛЛИНА үткәрә.


Кирәк:


(44-46 нчы үлчәмнәр өчен)

- трикотаж тукыма. Аның иңе – 140 см, буе – кардиган озынлыгына бәрабәр. (Кардиганны кем ничек тели, шул озынлыкта тегә ала. Без исә 85 см иттек);
- тукыма төсендәге кәтүк җебе;
- үткен кайчы.









Эш барышы:

■ кардиган тегү өчен иң элек түбәндәге үлчәмнәрне алырга кирәк:
1) арка киңлеге (бер култык астыннан икенчесенә кадәрге ара);
2) кардиганның озынлыгы (муенның иңбашына тоташкан җиреннән күкрәкнең иң биек ноктасы аша үзегез теләгән озынлык үлчәп алына);
3) беләк әйләнәсе (кулбашыннан – беләкнең иң юан төшеннән үлчәнә);
4) беләк озынлыгы (кулбаш сөягеннән беләзеккә кадәрге араны үлчиләр).

■ Сул ягын тышка калдырып, тукыманы урталай бөклибез. Буй юнәлеш буенча кардиган озынлыгын үлчәп, тукымага акбур яки сабын кисәге белән аркылы эз төшерәбез. Шушы эз буенча тукыманы кисәбез. (Кискәннән артып калган өлешен ерак алып куймагыз, ул җиң булачак.)


■ Киселгән тукымага җиң урынын билгеләргә кирәк. Моның өчен аны урталай бөклибез һәм өске яктан 10 см төшеп, тамга салабыз.
Шул тамгадан эчке якка таба арка киңлегенең яртысын билгелибез. (Безнең очракта арка киңлеге – 36 см, аның яртысы – 18 см.)
Бу – җиң уемының өске ягы була.

■ Шушы ноктадан аска таба 15 см үлчәп сызабыз. Бу сызыктан 7 см эчкәрәк кереп, тагын бер параллель сызык сызабыз. Өске һәм аскы ягы – 7 см, ике кыры 15 см булган турыпочмаклык килеп чыкты. Аның дүрт почмагын да бераз түгәрәкләндеребрәк сызып, акбур эзеннән тукыманың ике катын да бергә тотып кисәбез. Кискәндә тукыманың аскы каты эздән читкәрәк авышмасын өчен, аны чукмарбашлы энәләр белән чәнчибез.

■ Калган тукымадан ике җиң кисәбез. Моның өчен аны шулай ук урталайга бөкләп, сул ягы белән өстәл өстенә салабыз. Җиң өлгесе бик гади ясала, шуңа да без аны турыдан-туры тукымага гына сызабыз. Моның өчен безгә, әйткәнемчә, беләк юанлыгы һәм беләк озынлыгын гына белергә кирәк.

■ Тукыманың иң өске чите буйлап, беләк әйләнәсен салабыз. Аны икегә бүлеп, урта ноктаны табабыз. Шушы ноктадан аска таба беләк озынлыгын сызабыз. Бу сызыкның иң өске ноктасыннан аска таба 18 см үлчәп алып, аркылы сызык, ягъни беләк озынлыгын билгеләгән сызыкка перпендикуляр үткәрәбез. Безнең очракта беләк әйләнәсе – 30 см. Аны икегә бүлгәч, перпендикулярның бер ягында – 15 см, икенче ягында тагын 15 см була. Беләк озынлыгын белдергән сызыкның өске ноктасы белән перпендикулярның ике очын тоташтырабыз. Өчпочмак хасил булды. Өчпочмакның ике кырый кабыргасын үлчәп, аларны да урталай бүләбез, аны нокта белән тамгалыйбыз. Инде хәзер аларының да урталарын табып тамгалыйк. Аскы тамгалардан уртага таба 1,5 см кереп, берәр нокта куябыз. Өске яктагы тамгалардан, киресенчә, кырыйга таба 1 см чыгып тамгалыйбыз. Һәрбер ноктаны дулкынлы сызык белән тоташтырабыз. Җиң читен аска таба ике яктан да 2 см тарайтабыз. Сүздә аңлашылмаса, рәсемдә ныграк аңлашылыр ул. Кырый-кырыйдан, өстән – 1 см, ә җиң очында исә 2 см тегү өлеше калдырып, җиңне кисәбез.

PRESSA.RU








■ Инде кардиганны тегеп кенә куясы калды. Җиңне, сул ягын өстә калдырып, урталай бөклибез дә, машина җөе белән тегеп тоташтырабыз. Хәзерге машиналарның күбесендә трикотаж җөе бар. Андый җөй булмаса, зигзаг яки гади җөй белән генә дә тегеп була. Гади җөй белән теккәндә тукыманы бераз тарттырыбрак тегәргә кирәк булачак. Трикотаж тукымаларның уңай ягы бар, аларның чите сыпылмый. Без дә тукыма кырыйларын шул килеш калдырабыз.

■ Әзер җиңне уң ягына әйләндереп, чукмарбашлы энәләр белән җиң уемына беркетәбез. Игътибарлы булыгыз: җиң белән кардиган берберсенә уң яклары белән ята: уңгауң, диләр бу очракны. Башта җиңнең дә, җиң уемының да өске яктагы кыл уртасын табып, энә белән беркетәбез. Аннары җиңнең җөе белән җиң уемының аскы ноктасын туры китерәбез. Машина белән бастырганда җиң үзе аскы якта калсын. Шулай иткәндә ул тигез, матур булып утыра. Машинага зыян салмасын өчен, тегү барышында чукмарбашлы энәләрне берәм-берәм ала барабыз.

■ Җиңне утырткач, җиң очын ике тапкыр 1 см бөкләп, машина җөе белән тегәбез. Кардиганның читчитләрен шул килеш кенә калдырсаң да була. Без исә, киемгә төгәлләнгән рәвеш бирү өчен, аны ике тапкыр 0,5 см бөкләп, машина белән бастырдык. Кыйгач тасма (косая бейка) белән читләргә дә мөмкин.

«ИГЕЛЕКЛЕ» УЕНЧЫКЛАР



Бүгенге мастер-классыбыз башкару өчен җиңел генә булса да, максаты белән гадәти түгел. Казандагы «Рональд Макдональд Йорты» директоры Юлия МАРКОВА үткәргән бу мастер-класс белән без сезне игелек акциясенә кушылырга өндибез. Сез ясап җибәргән уенчыкларны алар Яңа ел алды ярминкәсендә сатып, җыелган акчаны шушы Йортны яшәтүгә тотар иде. «Тамчыдан күл җыела», диләр бит: берәр генә уенчык ясап җибәрсәгез дә, каты авыру белән көрәшүче балаларга зур ярдәм булыр иде.

Кирәк:

- 40х30 см булган флис тукыма;
- 10х15 см зурлыгындагы – ак, 4х4 см зурлыгындагы кызыл флис кисәге;
- көрән төстәге һәм тукыма төсендәге кәтүк җебе;
- синтепон.

Эш барышы:

■ Ачык төстәге флисны урталай бөкләп, өлгене тукымага төшерәбез. Тегәр өчен кырыйлардан 0,5 см калдырып, тукыманы кисәбез.

■ Күзләрне тегү өчен ак төстәге флистан ике овал кисәбез. Бу очракта тегү өлеше калдырылмый. Овалның буе – 4,5 см, иңе – 3,5 см.


■ Уенчыкның күзләрен белендерми генә тегәбез. Флис астына бер чеметем синтепон тыгып калдырабыз.

■ Энәгә көрән төстәге җеп саплап, уенчыкның керфекләрен, күз карасын, мыекларын, борынын, авызын, кендеген чигәбез.

■ Кызыл флистан йөрәк кисеп, аның да җөен белендерми генә кызыл җеп белән тегәбез.

■ Алгы һәм арткы якны машина җөе белән тегеп тоташтырабыз. Аскы якта кыска гына бер араны текми калдырабыз. Уенчыкны уң ягына әйләндереп, эченә синтепон тутырабыз. Ачык калган аралыкны белендерми генә тегеп куябыз.

■ Игелекле акциябезгә сезнең дә кушылуны көтеп калабыз. Уенчыкларны ноябрь ахырына кадәр тегеп, редакция адресына җибәрсәгез иде: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. «Сөембикә» журналы редакциясе.



Сайтта мастер-класс тулы вариантта бар.


Кучкар. Тормышыгызны үзгәртергә теләсәгез, хәзер нәкъ вакыты. Яңа эшләр башлар өчен көчегез дә, мөмкинлегегез дә булачак. Уңышка ирешим дисәгез, барысын да яхшылап планлаштырыгыз. Яхшы гына табыш алу ихтималы зур.


Үгезбозау. Тынгысыз ай, ял итү турында онытып торыгыз. Баш-аягыгыз белән эшкә чумарга туры килер. Моның яхшы ягын да тоярсыз – көзге депрессиягә бирелергә сезнең вакытыгыз юк!


Игезәкләр. Тормыш ыгы-зыгысы тәмам бөтереп алыр. Шул ук вакытта күңелле сюрпризларга да юлыгырсыз. Әллә кайчаннан күрешмәгән якын танышыгыз белән очрашу ихтималы килеп чыгар.


Кысла. Бу айда эш турында азрак уйларсыз. Бөтен игътибарыгыз гаиләгезгә юнәләчәк. Көз уртасында мондый үзгәрешләрнең сәбәпчесе – тормыш кыйммәтләрен яңача бәяли башлау.


Арыслан. Үз мәнфәгатьләрегезне онытып торырга туры килмәгәе. Көзге меланхолиягә бирешмәс өчен, көчегезне гаиләгезгә багышлагыз. Эштә бар да яхшы. Моңарчы тотынырга куркып торган эшкә һич шөбһәсез алына аласыз.


Сөмбелә. Тыныч һәм эшлекле ай. Тормышның күп өлкәләрендә гармония хөкем сөрер, үзегезне бәхетле итеп тоярсыз. Тирә-юньдәгеләр алдында абруегызны күтәреп җибәрердәй күркәм гамәл кылырсыз.


Бизмән. Күңелегез күтәренке булыр, рәхәтләнеп ял итү форсаты килеп чыгар. Күптәннән хыялланган нииндидер бер зур әйбер сатып алу ихтималы бар. Гомумән, бу айда сатып алган әйберләрнең куанычы озакка җитәчәк.


Чаян. Тормышыгызга «ревизия» ясар чак җиткән икән бит. Күңелдәге генә түгел, өйдәге иске-москыдан да җиңел генә котылыр өчен, дөрестән дә, бик уңай вакыт. Яңа идеяләрне тормышка ашыру җае чыгып тора.


Укчы. Күңелегез урынында түгел. Моның сәбәбен аңлата да алмыйсыз. Вак-төяк мәшәкатьләр дә кәефегезне кырачак. Иң яхшысы: бу айда зур эшләргә тотынмау, мөмкин кадәр азрак аралашу.


Кәҗәмөгез. Табышлы ай. Моның өчен үзегез дә бик күп көч куярсыз. Гел эш дип торуыгыз гаиләгездә бәхәсләр дә тудырырга мөмкин. Ниятләгәннәрегезне тормышка ашырганда кемнеңдер ярдәмен тоярсыз.


Сукояр. Уңышлы ай. Башкалар көзге депрессиягә каршы көрәшкәндә, сезнең барысы да «җырлап» кына барачак. Яңа эшкә алыну, яңа идеяне тормышка ашыру өчен бик яхшы вакыт.


Балык. Күңелегез һич кенә дә тормыш чынбарлыгы белән килешергә теләмәячәк. Сез әле һаман да җәйге дулкында яшәвегезне дәвам итәсез. Тәмам «уянып» җиткәнче, яңа эшләргә тотынмый торыгыз.

сентябрь дә кабынган йолдызлар

Татарстан


Әлфия Заһидуллина (7.09.1936–2004) – **җырчы, педагог. Татарстанның – халык, Россиянең атказанган артисты.**

1966 елда Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый. Сәхнә юлын 1963–1976 елларда М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет академия театрында солист буларак башлый. Н. Җиһановның «Түләк һәм Су-Сылу» операсында – Су-Сылу, Җ. Фәйзинең «Башмагым» операсында Сәрвәр партияләрен җырлый. 1976–1988 елларда Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең әдәби-музыкаль лекториендә эшли. 1969 елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр Казан дәүләт консерваториясендә укыта. Аның укучылары арасында – Георгий Ибушев, Зөфәр Хәйретдинов, Илсур Сафин һәм башка җырчылар.

Россия


Лада Дэнс (11.09.1966) – **җырчы.**

Калининградта туа. Кечкенәдән музыка белән шөгыльләнә: музыка мәктәбен һәм музыка училищесын тәмамлый. Студент елларында рестораннарда җырлап акча эшли. Олы сәхнәгә тәүге адымны 1988 елда ясый: «Юрмала-88» фестивалендә катнаша. Бу аңа җиңү китермәсә дә, эстрадага юл ача. Алар, өч җырчы – Лада Дэнс, Светлана Лазарева һәм Алина Витебская «Женсовет» төркеме оештырып, шактый зур уңыш казана. Төркем таркалганнан соң, Ф. Киркоровта бэк-вокалда җырлый. 1993 елда «Ночной альбом» дип аталган тәүге альбомын яздыра. 2000 нче еллардан үзен кинода сыный: «Испанский вояж Степаныча» фильмында, «Территория любви», «Бальзаковский возраст или Все мужики сво...» сериалларында уйный.

Чит илләр


Кассандра Петерсон (17.09.1951) – **киноактриса.**

Манхэттенда туа. Яшьтәшләре Барби курчагы белән уйнаганда, ул төрле убыр, җен-пәриләр белән мавыга. Яшүсмер вакытында барда биюче була. Мәктәпне тәмамлагач та бу һөнәрен ташламый. Аның биюен Элвис Пресли күреп, кызны «Бриллианты навсегда» фильмында катнашырга чакыра. 70 нче елларда Италиянең «I Latins Ochanats» рок-группасында җырлый. Анда озак тоткарланмый, кабат Америкага кайта, бию белән шөгыльләнүен дәвам итә. 1979 елдан Лос-Анджелеста «The Groundlings» труппасында эшли. Россия тамашачысына «Повелительница тьмы» фильмында Эльвира роле аша таныш.

PRESSA.RU





КИНДЕРЛӘРДӘ – ДӘРЬЯЛАР...

Әкүңелендә – һинд фәлсәфәсе. Алар еш кына урыннары белән алмашалар. Көннәрдән бер көн киндердәге сурәтләрдә Һиндстан яме урын ала да күңелендәге хатирәләр дәрья булып түгелеп китә: «Тетрәнүем шулкадәр көчле иде, мин, моңа кадәр шаян сүзле шук егет, ярты ел буе, көлү түгел, елмая да алмадым. 23 яшьтә кичерелгән клиник үлем вакытында җаным Күккә ашты, аннары кабат Җиргә индерелеп, терелдем. 27 яшьтә тагын бер клиник үлем кичердем. Барысы да яңабаштан кабатланды. Шуннан соң миңа тавышын ишетеп кенә дә кешенең нindирәк бәндә икәнлеген таный алу сәләте бирелде. Җирдәге тормышка карата мөнәсәбәтем тамырдан үзгәрде: мин бик җитдиләндем. 26 яшьтә СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы итеп кабул ителдем». Бар гомере һәм һәр көне өчен бермәбер арткан җаваплылык Озад Гариф улы Хәбибуллинны бүгенге көндә илнең иң танылган монументаль-декоратив сынлы сәнгать остасы иткән дә инде. 35 яшендә үк сынчы Ташкент метрополитенында урнаштырылган «Айбек» горельефы өчен СССР Рәссамнар берлегенең «Елның иң яхшы сынлы сәнгать әсәре» премиясен алган. Ул – «Мәскәүнең тынычлык фонды» Бөтендөнья оешмасының «Файда, намус һәм дан» ордены иясе, исеме Татар энциклопедиясенә (2014) кертелгән.

Хәтер дәрьясы кирегә ташый: студент елларында, инде тарихта ук онытылып баручы, юеш штукатуркага аффреско алымы белән язуны өйрәнү гаять кызыклы булган икән аңа! Фәнгә дикъкать тә елдан-ел арткан. Алматы һәм Навои шәһәрләре мәчетләрен төзекләндерү өчен Озад Гариф улы ачык фирүзә төсендәге искиткеч буяуны яңадан ачкан. Бу төс – Бохараның иң борынгы шаны! ЮНЕСКО җуелган буяу рецептына хәзер дә Халыкара бәйге игълан итә. Рәссам әлеге фирүзә буяуны фарфорга кушып, реставрация эшләрен башкарып чыгарга җөрьәт иткән. Гомеренең тагын биш елы Миасста термофосфатлы, ачык Галәм тирәлеге шартларына да чыдамлы буяулар белән меңнәрчә җитди тикшеренүләр үткәрүдә узган. Иҗатчының Казан метрополитенын бизәве – үз язмышына үзгәреш кертүгә тагы бер мисал. Үзбәкстанның халык рәссамы Озад Хәбибуллин 2008 елны Казанга күчеп кайтуга ук, эшкә чумган. Бүген ул Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының монументаль сәнгать бүлеге профессоры.

Күренекле рәссам картиналар язып та талантын раслый. 40 яшьтән соң Һиндстан һәм Непал буйлап бер елга якын сәяхәт итү нәтиҗәсендә туган әсәрләре, күргәзмә тәмамлануга ук, тулысы белән Италиядәге тупланма өчен сатып алынганнар. Аның күп кенә эшләрендә – «салкын» алымлы сюрреалистик символизм юнәлеше. Җәйхун белән Сәйхунның газамәтле тирәнлекләрен дә, Галәм чиксезлегенең илаһи күренешләрен дә ул зәңгәр төстәге балавызлы буяулар аша тәкъдим итә. «Җирдә яшәү – нинди бәхет! Алда язылачак хезмәтләремне күзаллыйм, – ди Озад Гариф улы. – Казан – ул рәссамнар өчен рухи көч, илһам чыганагы. Әбием – чыгышы белән Нурлаттан, замананда Урта Азиядә совет власте урнаштырып йөргән, шунда яшәп калган. Ә миңа менә, киресенчә, бирегә кайтырга насыйп булды.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА







ОЗАД ХӘБИБУЛЛИН

PRESSA.RU



ИГЪТИБАР!
«Сөембикә» журналының индексы үзгәрде



«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ П2204

13–23 октябрь көннәрендә «Почта России»ның барлык почта бүлекләрендә «Абунәче декадасы» узачак. Ташламалар булганда, журналыбызга язылып калырга ашыгыгыз.

Өлкәннәр көненә бүләк эзләгәндә «Сөембикә»не сайлагыз!



Татарстаннан читтә яшәүчеләр «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар: 73002

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) яки безнең сайтыбызның онлайн язылу бүлегендә дә язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. **iPad** һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.

Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (**www.syuyumbike.ru**).

16+